Министерство науки и высшего образования Российской Федерации

Казанский федеральный университет

Институт филологии и межкультурной коммуникации

Высшая школа национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая

Россия Федерациясе фән һәм югары белем министрлыгы

Казан федераль университеты

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Габдулла Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе

Ministry of Science and Higher Education of the Russian Federation

Kazan Federal University

Philology and Intercultural Communication

Gabdulla Tukay Higher School of National Culture and Education

ТАТАРСКОЕ ЯЗЫКОЗНАНИЕ В КОНТЕКСТЕ ЕВРАЗИЙСКОЙ ГУМАНИТАРНОЙ НАУКИ

Материалы IV Международной научно-практической конференции

Казань, 15–17 декабря 2023 г.

ЕВРАЗИЯ ГУМАНИТАР ФӘННӘРЕ КОНТЕКСТЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ БЕЛЕМЕ

IV Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары

Казан, 15–17 декабрь, 2023 ел

TATAR LINGUISTICS IN THE CONTEXT OF EURASIAN HUMANITIES

Materials of the IV International Research and Practice Conference

Kazan, December 15–17, 2023

КАЗАНЬ–КАЗАН–KAZAN
2024

УДК 811.512.145
ББК 81.2Тат
Т23

Под общей редакцией
доктора филологических наук, профессора **Г.Р. Галиуллиной**

Редколлегия:
кандидат филологических наук, доцент **Р.К. Сагдиева**;
кандидат филологических наук, доцент **Г.К. Хадиева**;
кандидат педагогических наук, доцент **Г.Р. Шакирова**;
доктор филологических наук, доцент **А.Ф. Юсупов**

Under the general editorship of
Doctor of philology, Professor **G.R. Galiullina**

Editorial board:
Candidate of Philology, Associate Professor **R.K. Sagdieva**;
Candidate of Philology, Associate Professor **G.K. Khadieva**;
Candidate of Pedagogical Sciences, Associate Professor **G.R. Shakirova**;
Doctor of Philology, Associate Professor **A.F. Yusupov**

Т23 **Татарское языкознание в контексте Евразийской гуманитарной науки** [Электронный ресурс]: материалы IV Международной научно-практической конференции (Казань, 15–17 декабря 2023 г.) / под ред. Г.Р. Галиуллиной. – Электронные текстовые данные (1 файл: 10 Мб). – Казань: Издательство Казанского университета, 2024. – 200 с. – Системные требования: Adobe Acrobat Reader. – URL:https://kpfu.ru/portal/docs/F_2085295817/EVRAZIYa.GUMANITAR.FANNARE.pdf. – Загл. с титул. экрана.

Евразия гуманитар фәннәре контекстында татар теле белеме: IV Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (Казан, 15–17 декабрь, 2023 ел) / мөх.: Г.Р. Галиуллина. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2024. – 200 б.

Tatar Linguistics in the Context of Eurasian Humanities: Materials of IV International Research and Practice Conference (Kazan, December 15–17, 2023) / ed.: G.R. Galiullina. – Kazan: Publishing House of the Kazan University, 2024. – 200 p.

ISBN 978-5-00130-796-9

Ответственность за аутентичность и точность цитат, имен, названий и иных сведений, а также за соблюдение законов об интеллектуальной собственности несут авторы публикуемых материалов. Материалы публикуются в авторской редакции.з

УДК 811.512.415
ББК 81.2Тат

ISBN 978-5-00130-796-9

© Издательство Казанского университета, 2024
© Казан университеты нәшрияты, 2024
© Publishing House of the Kazan University, 2024

УДК 372.881.1

Александрова Алсу Исмагиловна,
МБОУ «СОШ № 27» НМР РТ

Күпмәдәниятле яшь буын тәрбияләүдә музейларның роле

күпмәдәниятле, толерант, шәхес, мәдәният, музей, тәрбия

Бүгенге көндә күпмилләтле Татарстан мәктәпләрендә дәүләт һәм туган телләрне үстерү, милли үзаң һәм патриотизм хисе тәрбияләү мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора.

Балалар, бигрәк тә яшүсмерләр мохитендә агрессия, мәрхәмәтсезлек, усаллык киң таралган. Мәктәп бусагасын атлап кергән беренче көннән үк укучыларда толерантлык культурасы тәрбияләү зарурлыгы барлыкка килә.

Тотрыклы (толерант) шәхес тәрбияләү ул – укучыларда башка милләт кешеләренә, аларның мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт булдыру дигән сүз.

«Этник толерантлыкул – мәдәни юнәлеш, тынычлыкта һәм татулыкта, илдә, гаиләдә, мәктәптә, сыйныфта яшәүче шәхес мөнәсәбәтләре. Димәк, бу һәркемдә җаваплылык, игелеклелек, тыйнаклык, толерантлык кебек кешелек сыйфатлары булуын күздә тота. Кызганычка каршы, башка мәдәнияткә, яшәү рәвешенә, ышануларга, гадәтләргә карата түземсезлек рухы җәмгыятьтә яшәвен дәвам итә. Мәктәп тә искәрмә түгел» [Пчелинцева 2003].

Без, укытучылар, балаларны толерантлык рухында, башка кешеләрнең хокукларын һәм иреген хөрмәт итәргә өйрәтүче нәтиҗәле тәрбия механизмнарын эзлибез. Дәрес һәмдәрестән тыш эшчәнлек бүгенге көндә иң актуаль, иң кискен проблемаларны хәл итәргә: башка милләт вәкилләренә, аларның теленә, мәдәниятенә, тарихына, гореф-гадәтләренә яхшы мөнәсәбәт, гуманлылык кебек кешелек сыйфатлары тәрбияләүгә юнәлдерелгән.

Балаларда үз халкыбызга, үз илебезгә мәхәббәт тәрбияләү белән генә чикләнмичә, кайда яшәүләренә һәм нинди милләт кешеләре булуга карамастан, барлык халыкларны, аларның мәдәниятен, гореф-гадәт, традицияләрен хөрмәт итәргә, табигатьне яратырга өйрәтәбез, гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштырабыз.

Әгәр дә шәхес башка тугандаш халыкларның милли казанышлары белән кызыксынып, аларны өйрәнеп, үзенә кабул итә икән, ул үз халкының мәдәни кыйммәтләренә дә ныграк төшенә дигән сүз.

Толерантлы шәхес тәрбияләүдә, төрле милләт балаларының аралашу культурасын формалаштыруда музейларның роле бик зур.

«Музей – сәнгать әсәрләрен, техник, тарихи, фәнни-табигый экспонатларны һ.б. җыеп саклый һәм күргәзмәгә куеп тота торган учреждение» [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге 1979].

В. Старцев «Музей педагогикасы турында» дигән китабында язганча, «Музей – кешелек, халык, милләт хәтере генә түгел, ә музейга килүчеләргә педагогик йогынты ясау чарасы да» [Старцев 1999].

XIX гасырда музей фәнни үзәк кенә булып саналса, бүгенге көндә ул әхлакый кыйммәтләрне, мәдәни гореф-гадәтләрне саклау, формалаштыру һәм күпмәдәниятле яшь буын тәрбияләүүзәге булып тора.

Күпмәдәниятле тәрбия төрле милләт халыкларының мәдәни һәм тәрбия мәнфәгатьләрен исәпкә алуны күздә тота.

Төрле мәдәни кыйммәтләргә яраклашу, төрле традицияле кешеләр арасында үзара бәйләнеш, башка милләтләргә һәм халыкларга карата мәдәни-мәгариф монополиясеннән баш тарту – күпмәдәниятле тәрбиянең нигезе.

Мәктәбебездә «Мәдәниятләр диалогы» дип аталган музей эшли. Музей эшчәнлегенең максаты – гражданлык хисләренә ия булган, үзен һәм үзенең милли мәдәниятен, сәнгатен һәм тарихын хөрмәтләүче, башка халыкларны да якын итүче һәм аңлаучы шәхес тәрбияләү. «Мәдәниятләр диалогы» музее «Төбәк тарихы», «Төбәк һөнәрләре һәм һөнәрчеләре», «Бердәмлектә – көч», «Батырларга – дан!» дип аталган бүлекләрдән тора. Дәрестән тыш эшчәнлек вакытында тупланган барлык хезмәтләр, фәнни эшләр, экспонатлар, стенд һәм газеталар музейның тиешле бүлегендә сакланып бара.

Музейда эш «Мәдәниятләр диалогы» дәрестән тыш эшчәнлеге нигезендә алып барыла.

Бүгенге көндә музей эшчәнлеге төрле юнәлешләрне үз эченә ала:

– мәгърифәти эшчәнлек (экскурсияләр, музей дәресләре, интегральләштерелгән дәресләр, конкурслар, викториналар уздыру, укучылар иҗаты күргәзмәләрен оештыру);

– фәнни-тикшеренү эшчәнлеге (музейларда сакланучы әйберләрнең тарихын өйрәнү; фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашу);

– эзләнү эшчәнлеге (фондны баету, алышынучы экспонатлар һәм күргәзмәләр, музей архивы белән эшләү, инвентарьләштерү китабын тутыру, китапханәләр һәм интернет-ресурслар белән эшләү);

– бизәү эшчәнлеге (балалар иҗаты күргәзмәләрен оештыру).

Музейның тәрбия бирү процессында массакүләм-экскурсион эшчәнлек төп урынны алып тора. Мәктәп укучылары гына түгел, читтән килгән кунаклар да музей белән якыннан танышалар.

Гадәти музей белән беррәттән виртуаль музейда эшләп килә. Ул аның Интернет күчермәсе. Виртуаль музейда киң җәмәгатьчелек, ягъни укучылар, әти-әниләр, укытучылар, андагы материаллар, дипломнар, хезмәтләр, экспонатларның фотосурәтләре белән таныша алалар.

Түбән Кама шәһәре җирлегендә кырыктан артык милләт вәкиле яшәсә, үзебезнең мәктәптә унике төрле милләт вәкиле белем ала. Бер бинада, төрле милли төркемнәрдә белем алучы балаларның уртак проектларда, уртак чараларда катнашуы укучылар арасындагы дустанә мөнәсәбәтне тагы да арттыра, теге яки бу милләт мәдәниятен аңларга, аны хөрмәт итәргә өйрәтә.

Димәк, музейлар укучылар өчен уңайлы белем бирү мәйданы булудан тыш, күпмәдәниятле шәхеснең үсешен тәэмин итүче үзәк булып тора.

ӘДӘБИЯТ

Пчелинцева И. Толерантность и школьник. – М.: МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2003.

Старцев В.И. Педагогика и культурология музейной деятельности // В.И. Старцев, Г.Н. Ионин. – СПб.: ЭКБСОН, 1999.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1979.

УДК 811.512

Алишина Ханиса Чайдатовна,
Тюменский государственный университет
Джунгурова Валери Николаевна,
Калмыцкий государственный университет им. Б.Б. Городовикова
Трофимова Светлана Менкеновна,
Калмыцкий государственный университет им. Б.Б. Городовикова

Лексикографические материалы по верблюдоводству в тюркских и монгольских языках*

верблюд, тюркские и монгольские языки, эпос, дастан, «Идегей»

Казанская учёная Р. Муллаянова в 2007 г. написала статью «Без тарихта эзлебез. Галим дөя кебек булырга тиеш» (Наша история. Учёный должен быть подобен верблюду). Эта метафора как нельзя лучше характеризует человека, занимающегося наукой. Его образ символизирует силу духа, физическую силу, большую выносливость, терпение, самоотдачу, самопожертвование ради того будущего, что еле маячит в миражах научной «пустыни».

На самом деле, научных исследований о лексике верблюдоводства, можно сказать, нет. Скотоводство хорошо развито у монгольских и тюркских народов, для которых типичными объектами являются пять видов: корова, овца, лошадь, коза, верблюд.

Изучая лексику, в том числе связанную со скотоводством, казанские тюркологи Ф.Ш. Нуриева, М.М. Петрова, М.М. Сунгатуллина в статье «Лексикографический материал в тюрко-латинской грамматике Иеронима Мегизера «Institutionumlinguaeturcicaelibriquator» показали средневековые материалы, датированные 1612 г. В их исследовании содержатся наименования 5 групп домашних животных: *ath* ‘лошадь, конь’, *begür* ‘кобыла’, *sigur* ‘корова’, *busak* ‘телёнок’, *tseger* ‘корова’, *tossun* ‘бык’, *vku* ‘бык’, *inek* ‘корова’, *coin* ‘овца’, *kusi* ‘ягненок, агнец’, *oglak* ‘козёл’, *tcheluk* ‘козёл’, *deve* ‘верблюд’. Лингвистические изыскания авторов показали, что «наибольшая вариативность наблюдается в наименованиях животных, играющих важную роль в хозяйстве: sigur ~ inek ~ tseger ‘корова’; tossun ~ vku ‘бык’ и другие» [Тюркские 2022: 114].

Одним из первых в России «скотоводческую» диссертацию «Термины животноводства в карачаево-балкарском языке» под руководством К.М. Мусаева защитил М.З. Улаков. На высоком научном уровне проанализированы термины, связанные с крупным рогатым скотом, мелким рогатым скотом, ослом, мулом, лошадью. Внимательным образом отслежены названия овец по десяти возрастным группам. Но, к сожалению, нет упоминаний о верблюдоводстве. З.Ф. Миргалимова в Казани защитила работу «Названия млекопитающих в татарском литературном языке», в которой о верблюде ни слова не сказано. Р.Б. Кулиева защитила диссертацию «Животноводческая лексика Хновского говора рутульского языка», в которой есть одно упоминание верблюда ‘деве’.

Общераспространённым названием верблюда в тюркских языках является: дөя (тат.) төя (сиб.-тат.), тюе (кумык), тэбе (тоф.), дәвә (кр.-тат.), dəvə (аз.) и др.

В словаре «Отраслевая лексика кумыкского языка» даны слова ‘верблюжонок’ – *бота*, *тайлак*, *тюе* – ‘верблюд’. Половая дифференциация в кумыкском языке проявляется описательным способом: *эркек тюе* ‘верблюд’, *тиши тюе* ‘верблюдица’ [Отраслевая 2020: 203].

В калмыцком языке термину *темэн* соответствует перевод ‘верблюд’, *атн* – ‘кастрированный верблюд’, *ботхн* – ‘верблюжонок до года’, *буур* – ‘верблюд-производитель’, *иңгн* – ‘верблюдица’ [Хальмг келн: 93-94].

Многолетние исследования В.И. Рассадина позволили ему сделать вывод о том, что вся верблюдоводческая лексика калмыков заимствована из тюркских языков. Одной из интереснейших его работ является «Тофаларско-русский словарь», который отражает лексемы верблюдоводства в живом речевом потоке, в составе крылатых выражений, пословиц, поговорок, народных песен, в этнографических деталях быта миноритарного языка Саяно-Алтайского нагорья. Например, «*Қырған тэбе тоғлаар шэян, қырған киши ойнаар шэян*» (*посл.*) – И старый верблюд резвится, и старый человек играет [Рассадин 2014: 345]. *Чоғдур саъһал* – ‘козлиная борода’ [Рассадин 2014: 431] и др. От внимания выдающегося учёного В.И. Рассадина не ускользнуло и то, что «тюркским же по происхождению следует считать и сам возглас «Сөг! Сөг!» (староп.-монг. *sökü*), при помощи которого монголы заставляют верблюда опуститься на колени [Рассадин Скотоводческая]. В свою очередь, у сибирских татар с. Чечкино Ярковского района нами тоже зафиксирован аналогичный возглас «*чүк, чүк*» по отношению к коровам у односельчанина, родившегося в Тобольском районе. Этот возглас вызывал смех у местной ребятни, т.к. для коров в этой деревне используется слово «Әүгә!».

Вместе с тем, благодаря современному исследователю турецкого языка З.Н. Экба, мы ещё раз обратили пристальное внимание на лексический состав языка сибирских татар. Вопрос был такой: «Не встречалось ли вам обозначение верблюда у сибирских татар словом «нар»? «Как же, встречалось. Например, *наргычы* – погонщик верблюдов». В монографии «Ономастикон сибирских татар» собрана и проанализирована уникальная картотека – 19651 имя собственное, в том числе микро-

топоним «Наргычы» недалеко от татарской деревни Чикча в Тюменском районе [Алишина 1999: 233].

Сибирские земли по Иртышу и Тоболу раньше входили в состав Ногайской орды, в которой правил хан Идегей (1352-1419). Известные казанские учёные, выходцы из Тюменской области, Хамит Ярми, Флора Урманче называли Сибирь страной дастанов. Фольклорным наследием сибирских татар принято считать историко-эпический дастан «Идегей», который был записан В.В. Радловым в конце XIX в. Более полная версия найдена в 1919 г. в д. Еланлы Тарского района Омской области и записана от сказителя Ситдика Зайнутдинова. Методом фронтальной выборки мы выявили комплекс верблюдоводческой лексики в дастане «Идегей»:

Атан – печелгән дөя ‘кастрированнный верблюд’. Унбиш батыр арталмас, Унике атан тарталмас [Идегәй дастаны 2004: 306].

Бузлау – сыктау ‘реветь’ – дөягә карата әйтү сакланган [Идегәй дастаны 2004: 306].

Бура – ата дөя ‘верблюд-самец’ Заманым минем кагылды. Кагылмаса ни кылды. Коршаулы бура чыгып, каршы карап чабынды [Идегәй дастаны 2004: 518].

Дәвә – дөя ‘верблюд’ [Идегәй дастаны 2004: 522].

Мөхфә –дөя өстенә куелган урын ‘сиденье, которое ставили на верблюда’ [Идегәй дастаны: 478].

Мөхфә – дөя өстенә куела торган урын, ятак ‘сиденье, лежанка на верблюде’ [Идегәй дастаны: 639].

Нар – бер өркечле дөя ‘Одногорбый верблюд’. Карыгынча көч булган кары нардан аерылдым [Идегәй дастаны 2004: 353].

Нар – бер өркәчле ата дөя, көч символы ‘символ силы – одногорбый верблюд’. Кырыгы бердәй батыр, нар идее [Идегәй дастаны 2004: 519].

Нар – бер өркечле ата дөя. Төрки дастаннарда көч символы буларак йөри. – «Верблюд используется в дастанах как символ силы». Ак көймәгә нар йигеп, ак йаулыкларын йил алып, киленчәкләр күчәр яз көне – «Весной невестки в развевающихся белых платках переедут на верблюдах, сидя в белых повозках» [Идегәй дастаны 2004: 408].

Нар – бер өркечле ата дөя ‘одногорбый верблюд’. Йануар Бус аргымагым, алган идем мин сине сатуда, ике тугыз мал биреп, йитмәгәнгә нар биреп, колымдан кара кол биреп. – «Аргамак мой Януар Бус, купил я

тебя, уплатив две девятки скота, добавив в придачу одногорбого верблюда и одного раба» [Идегәй дастаны 2004: 415].

Пуда–дөя баласы ‘верблюжонок’. Ул ике дөя менгән кешене бер пуда куалап килә. – «За человеком с двумя верблюдами бежит верблюжонок» [Идегәй дастаны 2004: 340].

Тәвә–дөя ‘верблюд’. Аер өркәч(е) май баскан Тәвәләр йәйләү тартыр яз көне. Кузыларын кудырып, куйлар мәңрәй инәр яз көне. – «Весной упитанные двугорбые верблюды пройдут на джайляу, блеющие овцы тоже весной выйдут» [Идегәй дастаны 2004: 408].

Таким образом, в ходе исследования на основе источниковедческих данных, к числу которых относятся двуязычные и толковые словари, материалы полевых экспедиций, разработки в области татарских дастанов, было доказано, что в фольклоре сибирских татар активно функционировал термин «нар» по отношению к верблюду и показано дальнейшее развитие его значения в топонимике юга Тюменской области. В настоящее время данное слово практически забыто. Это языковое явление требует дальнейшего изучения.

Исследование выполнено за счет гранта Российского научного фонда № 22-18-00060 «Исследование тюркской и монгольской лексики материальной культуры, связанной с традиционным скотоводством: сравнительно-исторический аспект».

ЛИТЕРАТУРА

Алишина Х.Ч. Ономастикон сибирских татар: (на материале Тюменской области): монография: [в 2 ч.] / Х.Ч. Алишина; науч. ред.: Г.Ф. Саттаров, Н.К. Фролов. – Тюмень: Изд-во Тюмен. гос. ун-та, 1999. – 240 с.

Ахметова-Урманче Ф.В. Татар эпосы. Дастаннар. (Татарский эпос. Дастаны. На татарском языке. – Казань: Раннур, 2004. – 639 с.

Кулиева Р.Б. Животноводческая лексика Хновского говора рутульского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – М., 2008. – 23 с.

Миргалимова З.Ф. Названия млекопитающих в татарском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2007.

Муллаянова Р. Без тарихта эзлебез. Галим дөя кебек булырга тиеш // Ватаным Татарстан. 2007. 2 ноябрь. № 223-224.

Рассадин В.И. Скотоводческая лексика калмыцкого языка в сравнении с турецко-месхетинской // Вестник Бурятского госуниверситета. – 2011. – № 8. – С. 83-90.

Рассадин В.И. Тофаларско-русский словарь. – Элиста: Изд-во КалмГУ, 2014. – 536 с.

Таймасханова Т.Г., Абдуллабекова У.Б. Словарь отраслевой лексики кумыкского языка. – Махачкала: АЛЕФ; ИЯЛИ ДФИЦ РАН, 2020. – 236 с.

Тюркские языки и литературы в исторической перспективе. Коллективная монография. Отв. ред. Е.А. Оганова. – М.: ИСАА МГУ им. М.В. Ломоносова, 2022. – 414 с.

Улаков М.З. Термины животноводства в современном карачаево-балкарском языке. Дис. ... канд. филол. наук. М., 1983. – 152 с.

Хальмг келн. Калмыцкий язык. – Элиста: Изд-во Калм. ун-та, 2020. – Ч. 2. – 124 с. – на калм. яз.

УДК 811.512.145

Бәйрәмова Фәүзия Әүхәдиевна,
ТР Язучылар союзы

Мөхетдин Корбангалиев һәм репрессияләр

М. Корбангалиев, методист, имля, дәреслек, сүзлек

Бер караганда, тел галиме, КДУ профессоры Мөхетдин Корбангалиевка утызынчы еллардагы репрессияләр кагылмаган кебек, әмма ул алай түгел. Аның үзенә кагылмыйлар, ә менә кызын сөргенгә сөрәләр, аның ирен атып үтерәләр, оныкларын тартып алалар. Карт галимнең җитмеше дә тулмыйча йөрәге ярылып үлүенең бер сәбәбе бәлки шулдыр да...

Ул чорда галимнең үзен берничә сәбәп белән кулга алмаганнар, дип уйлыйм. Беренчедән, биографиясе бәйләнерлек түгел, аның ата-бабалары алпавыт Тәфкилевләрнең крепостной крестьяннары булган, бу факт документлар белән раслана. «Татар тарихында крепостнойлык – сирәк булган күренеш, – дип яза галимнәр. – ...Нәтиҗәдә, 9 татар авылының – Тирсә, Наҗар, Тоба, Чишмә, Биектау, Мордывый, Балтач, Татар Шаршадысы һәм хәзерге Удмуртиягә керә торган Бакыр Заводы (Варзино-Алексеевск) авылының җирләре һәм Иж елгасының ике ягындагы шактый урман-болыннар Тәфкилевләр һәм алар токымыннан булган алпавытлар биләмәсенә кергән. 1858 елда Тәфкилевләр токымының бу төбәктә барлыгы 2850 крепостной крестьяны булган». [Мәрданов 2003: 18]. Мөхетдин Корбангалиев шушы крепостной авылларның берсендә – Биектауда (Биктово) туган, аның да ата-бабалары Тәфкилевләрнең крепостнойлары булган. «Мөхетдин Корбангалиев 1873 елның 9 нчы декабрендә крепостной крестьян гаиләсендә туа. Аның атасы Хафиз шундагы җирләрне биләүче Тәфкилевләрнең крепостной крестьяны була», – дип яза җирле төбәк тарихчысы [Сибгатова 2021: 149].

1939 елны, золым корбаны булган кызын коткару өчен, Лаврентий Бериягә язган хатында Мөхетдин Корбангалиев үзе дә крепостной крестьян баласы булуын раслый. «Я сам в прошлом сын крепостного крестьянина, который вместе с моей матерью, со старшими моими сестрами и братьями все свое детство продолжал работать помещику на выкуп. Родители мои со слезами на глазах рассказывали мне о своей крепостной жизни, рассказывали и объясняли мне, почему такие-то вековые деревья по дороге в такой-то деревне не трогаются крестьянами до сих пор и считаются священными (они служили виселицами)» [Сафиуллина 2008: 37].

Мөхетдин Корбангалиевны кулга алмауларының икенче зур сәбәбе: милли мәгариф өлкәсендә ул алыштыргысыз белгеч була. Ул чорда татарларда ике тапкыр хәреф алышына, гарәп хәрефләре белән дәреслекләр яза башлаган Мөхетдин Корбангалиев аларны латин имлясына күчерергә яки шул хәрефләр белән яңаларын язарга тиеш була. Инде анысына ияләнеп беткәндә, латинны ашыгыч рәвештә кирилл хәрефләренә алыштыралар, тагы яңа дәреслекләр, уку китаплары, әлифбалар, сүзлекләр, методик кулланмалар кирәк була. Көне-төне эшли торган Мөхетдин Корбангалиев яңа власть өчен дә кирәк, чөнки иске белгечләрнең кайсылары инде төрмәдә утыра яки атып үтерелгән, кайсылары чит илләргә качкан. Бу елларда ул, автордаш (соавтор) буларак, татарларга – рус телен, русларга – татар телен өйрәтү буенча дистәләгән дәреслек, методик кулланмалар яза, сүзлекләр төзи, аның шундый йөздән артык хезмәте билгеле. Мәгърифәтче галимнең ул чордагы фидакарь эшчәнлеге турында бүгенге галимнәр менә нәрсә язалар: «Профессор М. Курбангалиев совершенствует учебники по татарскому языку для не татар: только в 1933 году были изданы еще 2 учебника. (Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен. – Казан: Татгосиздат, 1933. – 270 б.; Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен. V уку елы. – Казан: Татгосиздат, 1933. – 184 б.). В 1934 году увидело свет новое издание этой книги (Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен. {Техникум, рабфак, вуз һәм втузлар өчен}. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 252 б.). Эти издания были рекомендованы и для техникумов, и для вузов, и для курсов обучения татарскому языку» [Сафиуллина 2008: 16].

Моңа өстәп, Мөхетдин Корбангалиевның утызынчы елларда баш күтәрми сүзлекләр өстендә эшләве дә билгеле, хәтта бу мөһим хезмәт

өчен университетта аны өстәмә эшләрдән дә азат итәләр, бары тик укытуны һәм кафедра белән җитәкчелек итүне генә калдыралар [Сафиуллина 2008: 16-17]. Фидакарь галимне хәтта авырый башлагач та эшеннән җибәрмиләр. 1931 елның 10 июлендә КГУ ректорына язган хатында Мөхетдин Корбангалиев, авыруы сәбәпле, үзен татар теле һәм әдәбияты кафедрасы белән җитәкчелек итүдән азат итүне сорый, әмма ул шул хәтле кирәкле белгеч була ки, аны барыбер азат итмиләр.

Ул чорда Мөхетдин Корбангалиевны юк итмәүнең тагы бер сәбәбе бар: ул – халык мәхәббәте. Әле 1921 елда ук аңа яшь Татарстан хөкүмәте «Хезмәт Батыры» («Герой Труда») дигән мактаулы исем бирә, 1925 елда Мөхетдин Корбангалиевның утыз еллык хезмәтенә багышланган китап басыла, анда Галимҗан Ибраһимов, Гали Рәхим, Габдрахман Сәгъди мәгърифәтче галим турында зур фикерләр әйтәләр. 1926 елны Мөхетдин Корбангалиевның фәнни-педагогик эшчәнлегенә утыз ел тулуны Татарстан хөкүмәте үзе билгеләп үтә, Казан урамнарының берсенә аның исемен бирү турында карар чыгаралар, әмма ул үтәлмичә кала. 1932 елда аның исеме галимнәрнең һәм атказанган фән эшлеклеләренең Бөтенсоюз мактау тактасына кертелә. 1933-1935 елларда Мөхетдин Корбангалиев, дәреслекләр төзегән өчен, Казан дәүләт университетының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Ә инде 1940 елда аңа ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, дигән мактаулы исем бирелә, һәм ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә [Сафиуллина 2008: 18-19]. Мөхетдин Корбангалиевның йөзләгән, хәтта меңләгән укучылары, шәкертләре, студентлары була. Һәм халык арасында шундый зур абруе булган кешегә кул күтәрергә батырчылык итмиләр. Моның өстенә, Мөхетдин Корбангалиев бу елларда баш күтәрми бик җитди һәм бик кирәкле хезмәт өстендә эшли һәм 1938 елны, латин хәрефләре белән, 667 битлек «Русча-татарча сүзлек» басылып чыга. 1939 елда аның катнашында «Русско-татарский сельскохозяйственный терминологический словарь», шул ук елны «Русско-татарский словарь для начальных школ» сүзлеге дөнья күрә.

Шулай итеп, гаять кирәкле белгеч булган карт профессорның үзенә тимәсәләр дә, аның 34 яшьлек газиз кызын кулга алалар. Мөкәррәмә ул вакытта Республика туберкулез диспансерында врач-рентгенолог булып эшли, үпкә чирләре буенча зур белгеч була. Синтетик каучук заводында шартлау булгач, 1936 елның ахырында аның ире Шиһап Сәйфине, инженер буларак диверсиядә гаепләп, кулга алалар һәм бөтен сменалары

белән атып үтерәләр. Мөкәррәмәне исә 1938 елның 19 гыйнварында кулга алалар, балалары 8 яшьлек Энҗе белән биш яшь ярымлык Ирек тә чиркәү төрмәсенә ябыла.

«В январе 1938 года к нам домой приехали из НКВД, чтобы арестовать мою маму. Это было ночью. Мама тихо плакала, одевала нас. Нас посадили в чёрную машину. Мама продолжала плакать, я спросила: «Куда мы едем, мама?». Она сказала: «В гости». «А зачем ты тогда плачешь?». «Я не хочу туда ехать». Мне было 8 лет, брату Иреку 5,5 лет. Нас с братом доставили в детский приёмник и там оставили на лавке. Мама последний раз на нас посмотрела в щелочку и больше мы её не видели. А маму отправили в Карагандинские лагеря, в Акмолинск, в Казахстан. Она была там 3,5 года». (Писала дочь – Курбангалеева Энже Шигабовна, 27 марта 1999 года.) (Мөкәррәмәнең кызы – Корбангалиева Энҗе Шиһап кызының көндәлегеннән. Бу көндәлек Энҗенең кызы, Мөхетдин Корбангалиевның оныкчыгы Регина Сәйфи- Сираҗетдинованың шәхси архивында саклана).

Әлбәттә, бу шомлы хәбәр Мөхетдин Корбангалиевка тиз килеп ирешә, һәм ул кызын һәм оныкларын коткарырга ташлана. Оныкларын ул палачлар тырнагыннан тартып ала ала, ә менә кызын башка күрми инде. Мөкәррәмәне коткару өчен, кайларга гына язмый ул: Сталинга, СССР Эчке эшләр халык комиссары Лаврентий Берияга, СССР прокуроры Панкратовка, хәрби прокурор Райхлинга, Казан һәм Мәскәү түрәләренә яза. 1939 елның 5 мартында Берияга адресланган хатында карт галим кызы өчен бик борчылуын, кулга алынганнан бирле аннан бер хәбәре дә булмавын, НКВДның Караганда лагерьларына җибәрелүен ишеткәнен, анда әйберләр һәм ризыклар белән өч посылка, өч хат, ике тапкыр акча җибәреп каравын, әмма кызыннан бернинди җавап та алмавын өзгәләнеп яза. Мөхетдин Корбангалиевның 1940 елны Сталинга язган хатында инде өч имза тора, аннан тыш, ике баласы да кул куйган – «Профессор-орденоносец Казанского государственного университета М.Х. Курбангалиев; ассисент 2 Ленинградского медицинского института С.М. Курбангалиев; доцент Казанского государственного университета, кандидат ВКП (б) Х.М. Курбангалиева» [Сафиуллина 2008: 44].

Шунысын да әйтергә кирәк: Мөхетдин Корбангалиевның олы улы Салих, Казандагы эзәрлекләүләрдән качып, Ленинградка күчәргә мәҗбүр була. Югыйсә, ул да Казанда бик танылган шәхес була бит: Татарстан Җөмһүриятенең Сәламәтлек саклау комиссариаты (министр-

лыгы) җитәкчесе, атаклы табиб, Казан дәүләт медицина институтының беренче ректоры. Хирург буларак, ул сугышның башыннан ахырына кадәр катнаша, сугыштан соң фәнгә килә, медицина буенча докторлык диссертациясе яклый, туганнары белән араны беркайчан да өзми, аларга ата урынында була. Шунысын да әйтергә кирәк: Казанда Салих Корбангалиев исемендәге урам бар, ә аның атасы Мөхетдин Корбангалиев исемендәге урам юк.

Бәлки шул язуларның да файдасы булгандыр, Мөкәррәмә концлагерьда ярты срогын гына утыра, ул авыру хәлдә, 1941 елның 6 июнендә Казанга кайтып егыла. Әмма ул кайтканда, өч көн элек кенә әтисе үлгән була, 1941 елның 3 июнендә Мөхетдин Корбангалиевның йөрәге, йоклаганда, мәңгегә тибүдән туктый. Ата белән кыз бу дөньяда башка күрешә алмыйлар... Халык дошманы, дип, Мөкәррәмәгә Казанда калырга рөхсәт бирмиләр, ул балаларын алып, Минзәлә шәһәренә китәргә мәҗбүр була, анда больницада рентгенолог булып эшли, үпкә чирле яралы сугышчыларны дәвалый. Сөргендә күргән газаплары аркасында, ул үзе дә рак белән авырый башлый һәм 1949 елда, 45 яшендә, Казан хастаханәсендә бакыйлыкка күчә...

Күргәнебезчә, тел галиме Мөхетдин Корбангалиев гаять катлаулы чорда, хакимият кенә түгел, әлифбалар гына түгел, идеологияләр алышынган чорда иҗат итә. Әмма ул патша заманында да, совет хакимияте вакытында да бары тик үз халкына, фәнгә һәм хакыйкатькә хезмәт итә. Ул золым корбаннары булган фикердәшләре Галимҗан Ибраһимов, Гали Рәхим, дистәләгән татар язучылары, галимнәре өчен дә эшли, кызы Мөкәррәмәне аклау өчен дә соңгы көчен куя. Ата белән кыз бу дөньяда инде кабат күрешә алмыйлар, әмма Казанның Яңа Татар зиратында алар янәшә яталар... Тукай белән Хөсәен Ямашев янында, милли каберлекнең түрендә... Рухлары шат булсын!

ӘДӘБИЯТ

Мәрданов Р. Әгерҗе төбәге тарихы / Р. Мәрданов, И. Һадиев. – Казан: Тамга, 2003. – 175 б.

Сафиуллина Ф.С. Герой Труда Татарстана профессор М.Х. Курбангалиев / Ф.С. Сафиуллина, Х.М. Курбангалиева. – Казань: Изд-во Казан. гос. ун-та, 2008. – 57 с.

Сибгатова Э. Бөек Себер юлында Биектау. – Әгерҗе, 2021. – 149 б.

УДК 372.881.1

Байындыр Толга,
Международный казахско-турецкий университет
имени Ходжи Ахмеда Ясави

Альфа-поколение и цифровые инструменты в преподавании языка

язык, образование, цифровизация, материал

Язык и человек продолжают свое существование вместе как два субъекта параллельной истории. Они элементы, которые не рассматриваются и не анализируются отдельно друг от друга. Конечно, понятие «язык», обозначающее основные коммуникативные потребности человека и составляющее внутри себя огромный ряд социальных элементов, является постоянно меняющимся и развивающимся существом. В современном мире в основе средств коммуникации, выражающих короткие расстояния, лежит тоже явление языка. Технологии и развивающиеся устройства, связанные с ними, хоть немного положат конец пограничной концепции современного мира. Особенно компьютерные технологии, которые стали широко использоваться в нашей жизни в начале 2000-х годов, демонстрируют быстрый импульс роста. Возможность быстрого и легкого получения информации, предоставляемая интернетом, также повлияла на структуру образовательных систем, которые мы сегодня называем классическими. В течение двадцати лет, в промежуток времени, который можно считать коротким, информационные технологии выходят из наших домов и становятся достаточно функциональными, чтобы поместиться в наших карманах. В то время как мир с удивлением наблюдает за этими ситуациями каждый день, неожиданные события в современном мире начинают радикальные изменения во всех сферах жизни, в том числе и в сфере образования. С марта 2020 года началась «Глобальная Эпидемия» (Covid-19), которая в течение малого времени успела распространяться во весь мир, также вынуждал компьютерные технологии и системы образования объединиться неразрывно. «*Технология всегда играла центральную роль в использовании дистанционного обучения как альтернатива к обучению лицом к лицу или в качестве средства для неблагоприятных ситуаций. С этой точки*

зрения кажется, что технологические достижения периодически приводят к дистанционному образованию» [Шенгюль 2021: 176]. Система, так называемая «Дистанционное обучение» или же «Онлайн обучение», использованная только в качестве эксперимента до указанного здесь времени, внезапно входит в жизнь практически любой семьи. В связи с этим, такие понятия как «школа», «класс», «кабинет», совсем скоро станут не совсем актуальными.

Исследования, проведенные с лицами, изучающих или предоставляющих языковые образования [Шенгюль 2021, Исмаилоглу 2019, Гюнгор 2020] получили негативные результаты по поводу влияния дистанционного обучения в учебно-воспитательный процесс. Но эти результаты со временем меняются, что связано с такими причинами, как сокращение времени занятий в школах и университетах, отсутствие достаточного количества материалов для занятия и др. Несмотря на то, что не во всем наблюдается позитивное развитие, такие факторы, как увеличение участия в дистанционном обучении, в связи с обеспечением удобства места и экономия времени, гарантируют, что процесс будет устойчивым. Технологические возможности опосредуют применение языкового образования более гибким, экономичным и функциональным способом. Конечно, учителям, которые сами были воспитаны классическими видами образования, нужно время, чтобы привыкнуть к этой новой системе. Однако «Поколение Z», не чуждое информационным инструментам, намного быстрее адаптировалось. Кроме того, для «Альфа поколения», родившегося в широко распространенном мире средств связи и полностью рассматривающего модель дистанционного обучения, ситуация является вполне обыкновенной. Для детей, которые уже взаимодействуют с виртуальными сайтами обмена (Youtube, Dailymotion и т.д.), состояние дистанционного обучения не чуждо. При повышении квалификации учителей, использование виртуальных ресурсов, (видео, аудиозапись, игры и т.д.) по назначению, стало еще проще. Благодаря переносу учебников (Z book) на работоспособную виртуальную среду, все виды уроков стали проходить в определенном порядке. Конечно, изучение второго языка – сложная и целостная работа, требующая долгих усилий. Для этой цели было разработано множество методов: «Метод преподавания иностранных языков определяет теоретические основы преподавания. Поэтому необходимо хорошо знать основные принципы, границы, ограничения, формы и особенности применения используемых методов»

[Мемиш 2013: 299]. С преодолением методических трудностей, главная задача в новом процессе станет разработка концептуальных материалов. Заметное объяснение Думана на эту тему таково: «Подготовка материалов урока требует отдельное мастерство. С другой стороны, каждый учитель должен знать принципы подготовки материалов и при необходимости иметь возможность готовить свои материалы в соответствии с этими принципами. Выбор и использование материалов на месте влияет на успех учителя. Поэтому необходимо также обратить внимание на выбор материала и своевременное использование материалов» [Думан 2013: 1].

В Европейском языковом портфеле изложена важность подготовки необходимых материалов для преподавания языка в рамках межкультурного взаимодействия / диалога. В настоящее время, необходимо интегрировать разрабатываемые материалы в систему дистанционного образования. Потому что важна целевая сообразительность лекционного материала. Лекции, которые будут проводиться в соответствии с потребностями целевой аудитории, желающей изучать язык, служат для достижения поставленной цели. Технологические, экономические, научные или культурные потребности общества в разные периоды воспитывают людей со своей системой мышления. Понятие «поколение» используется для лиц с общими кодами, обусловленными разницей периодического восприятия. Демирель, который сделал перевод от Макриндла и Вольфингера про «Альфа-поколение», которое было предметом нашего исследования, говорит, что «Алфа-поколение» включает в себя людей, родившихся после 2010 года [Демирель 2021: 1799]. Но определение понятия *поколение* только по году рождения – не очень правильный подход. Общий знаменатель мышления, слуха, образа жизни и опыта людей, представляющих один период и одну эпоху, также важен для концепции поколения. Учитывая подобные критерии, можно перечислить нынешние поколения следующим образом: «Безмолвное поколение, поколение Бэби-бумеров, поколение Х, поколение У, поколение Z и поколение Альфа» [Демирель 2021: 1802].

Исследования особенностей этого поколения, которое будет руководить миром примерно через 15-20 лет, с обширной точки зрения важно для планирования общего образования, а в частном, важно для планирования преподавания языка. Метод интуиции, применяемый в течение около десяти лет частично продолжается и сегодня. «В методе

интуиции уделяется внимание не запоминанию абстрактных правил языка, а улучшению языковых и умственных способностей ученика. Основное внимание уделяется к изучению языковых правил с помощью экспериментальных мероприятий, таких как научная информация, а не передаче устной информации» [Гюнеш 2013: 71]. Тем не менее, «Альфа-поколение» – это поколение, в прямом значении слово, рожденное в середине технологической инфраструктуры и познающее мир в основном через социальные сети. Это поколение, способное грамотно использовать информационные технологии, обладает компетенцией в получении и обработке информации. Они лучше всех понимают язык «Экранного мира» и используют этот язык во всех сферах общения. Они используют компьютерные игры, кино, электронные книги, короткие и плавные видеоролики, вкратце, все возможности цифрового мира и живут в основном в «онлайн» мире. Это самый важный стимул, определяющий их уровень жизни. «В период появления этого поколения, технологические и цифровые разработки наблюдаются в большом количестве, и почти в центре общественной жизни лежат электронные приборы, социальные сети, визуальные и цифровые технологии. Поколение Альфа обычно использует компьютер/планшет/мобильный телефон в качестве игрушек, проводит онлайн просмотр лекций/видео из социальных сетей и имеет возможность получить неограниченный доступ к новой информации. В образовательной жизни в будущем их ждет обучение искусственному интеллекту, роботизированным технологиям и технологиям, связанным с 3D-принтерами. Отмечается, что эта ситуация отражается и на воспитательной среде детей» [Исмаилоглу 2019: 107]. Они являются представителями поколения, переходящего с улицы в дом, из дома в виртуальный мир. С этой точки зрения, нам необходимы исследования поведения альфа-поколения в области образования, работы и в общественной жизни. Потому что способность предвидеть их поведение важна для планирования вида преподавания языка. Проведенные исследования выявили следующие признаки альфа-поколения:

- Они ненавидят совместное использование, хотят быть единственным владельцем всего.
- Они очень подвижны и активны. Но они не шумят.
- Конфиденциальность для них не важна. Они не стесняются делиться с миром своими опытами.
- Им не нравятся правила. Они даже не признают правил.

- Им не нравятся какие-либо ограничения и установленные границы на их территории.
- Они очень заинтересованы в носимых устройствах.
- Они обладают предпринимательским духом благодаря своей способности к доступу.
- Они очень доверяют и верят в социальные сети. Они познают мир именно через социальные сети.
- Даже если они общаются через социальные сети, они всегда предпочитают быть наедине. Они могут быть самодостаточными.
- Они предпочитают совершать покупки в интернете онлайн.
- Во время общения с людьми они практически не совершают физического контакта.
- Они обладают высоким уровнем навыков, способных преодолевать огромных трудностей.
- Они повторно делают то, что им нравится и могут просмотреть один и тот же фильм, прослушать одну и ту же музыку сотни раз.
- Они занимаются экологическими и социальными проблемами.
- Для них важно только настоящее время, будущее или прошлое их не интересует.
- Они хотят, чтобы все было сразу и поэтому они быстрые [Демирель 2021:1810-1811].

Знание этих характеристических особенностей альфа-поколения важно для понимания их и планирования системы образования, которая будет создана для них. Например, обучения, получаемые в классах и кабинетах и дисциплины, через что проходили поколения до них, кажутся не очень подходящими для альфа-поколения. Кроме того, методы преподавания языка, которые продолжаются с помощью классических книжных практик, также устарели для них. Вместо этого было бы уместно использовать гораздо более короткие визуальные и звуковые видеозаписи, разные виртуальные игры. Скорость доступа и обработки информации делает это поколение более предприимчивым. Они принимают интернет в качестве первого источника, к которому они будут обращаться для любых нужд. Это неизбежно закладывает основу для передачи языкового образования через интернет и соцсети. Как политическая, так и экономическая, и коммерческая деятельность, возможно, что и преподавание языка в ближайшее время в значительной степени перейдет в виртуальную среду. И в настоящее время почти все страны,

заботящаяся о преподавании языка, быстро начали предпринимать необходимые шаги в этом вопросе. В Турции институт Юнуса Эмре с помощью ресурсов и методов, разработанных в период эпидемии, делают все возможное, чтобы удовлетворить требования новой эры. Благодаря таким средствам, как видеоуроки, электронные книги, живые виртуальные классы, удалось охватить много учеников, изучающих язык и быстро увеличить это количество. Но не стоит вводить в заблуждение, что на данный момент процесс идет совершенно гладко. Хотя дистанционное обучение – это система, которая экономит время и плату за обучение, все же оно сталкивается с проблемами подключения, проблемами с устройствами и проблемами дисциплины. Но в конце концов, учитывая сегодняшние условия, для учащихся более эффективно проводить языковое обучение в интерактивном режиме в классной комнате.

ЛИТЕРАТУРА

Демирель З.Х. Источник Человечество в Исследовательской Жизни: Альфа Поколение // Журнал Исследований Международного Сообщества. – 2021. – № 11. – Т. 18. Специальный выпуск управления и организации (июль). – С. 1796-1827.

Думан Г.Б. Разработка материалов и эффективное использование материалов в преподавании турецкого языка как иностранного // Журнал «Образование на родном языке». – 2013. – № 1(2). – С. 1-8.

Гюнеш Ф. Новые подходы к преподаванию языка // Журнал языка и литературы. – 2013. – № 2(7). – С. 71-92.

Гюнгер Х. Взгляды учеников и преподавателей на дистанционное преподавание турецкого языка как иностранного / Х. Гюнгер, О. Чангал, Т. Демир // Журнал факультета образования Университета Гази. – 2020. – № 40(3). – С. 1163-1191.

Исмаилоглу С. Использование технологий в классах детей Альфа-Поколения. / С. Исмаилоглу, Й. Хилал. – Стамбул, 2019.

Мамиш. Методы, особенности использования и критика, применяемые при преподавании иностранных языков / Мамиш, Р. Мухаммед, Д.Э. Мехмет // Turkish Studies – International Periodical For The Languages, Literature and History of Turkishor Turkic. – Анкара, 2013. – Vol. 8/9. – P. 297-318.

Шенгюль К. Преподавание турецкого языка как иностранного в процессе дистанционного обучения // Журнал исследований языка и литературы РумелиДЕ. – 2021. – № (24). – С. 174-222. DOI: 10.29000/rumelide.995482.

УДК 811.512.157

Борисова Надежда Марковна,
Северо-Восточный федеральный университет
имени Максима Кировича Аммосова

О некоторых лингвостилистических особенностях якутских газетных жанров

газетная публицистика, литературный язык, книжная речь, разговорная речь, фольклорно-ораторская речь

«В любом полиэтническом регионе глобализация по-разному влияет на этнокультуру и ее органическую часть – медиасистему» [Якимов 2012: 100]. В частности, особенности трансформации якутской газетной публицистики в условиях глобализации и развития этнических медиа служат механизмом включения этнической группы в процесс нациоглобализации. В связи с этим процессы соотношения (расслоения) и взаимодействия, а также синтеза стилей речи определяют характер функционирования и развития якутской газетной публицистики.

Еще в 1968 году Е.И. Убрятова отмечала, что у народа саха «высоко развито ораторское искусство с его особыми оборотами и специальной лексикой, придающими речи элемент торжественности» [Убрятова1968: 309]. Вероятно, именно поэтому лингвостилистическая система якутской газетной публицистики имеет национально-самобытный характер, но ее становление было невозможно без учета влияния русской книжно-письменной речи. Соответственно, в якутской газетной публицистике социальные потребности сформировали определенные стили.

Таким образом, стили речи являются формой реального существования газетной публицистики, которая усложняет картину ее функционирования и развития. В результате языковое и стилевое влияние якутской газетной публицистики на литературный язык имело место на определенных этапах его развития. В частности, роль новой революционной и созидательной лексики, введенной в литературный язык, была значительной в период его становления. Кроме того, грамматические формы и синтаксические сочетания, внесенные газетной публицистикой, стали достоянием литературного языка саха.

В настоящее время в якутской газетной публицистике сформировались наиболее контрастные средства выражения стилистических потенциалов, максимальная разность которых достигается за счет обращения к разговорной и фольклорно-ораторской речи, противопоставляемой книжным стилям. Процессы соотношения и взаимодействия этих стилей речи открывает широкие возможности в области стилевого творчества. В целом газетная публицистика, выполняя информативно-воздействующую функцию, имеет своеобразные стилевые черты в каждом из своих жанров.

ЛИТЕРАТУРА

Убрятова Е.А. О понимании стиля и о стилях в якутском языке // Развитие стилистических систем литературных языков народов СССР. – Ашхабад: Ылым, 1968. — С. 307-309.

Якимов О.Д. Трансформация медиасистемы Республики Саха (Якутия) в условиях глобализации // Вестник Северо-Восточного федерального университета им. М.К. Аммосова. 2012. Т. 9. № 2. – С. 99-104.

УДК 811.512.145

Булатова Әлфия Кәрим кызы,
Хөсәинова Алинә Җәмил кызы,
Татарстан Фәннәр Академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Татар теленең көнбатыш диалектында фин-угор алынмалар

татарский язык, мордовские языки, диалектология, западный диалект татарского языка, лямбирский говор, финно-угорские заимствования

Көнбатыш (мишәр) диалекты – татар теленең мишәр субэтник төркеменең сөйләшләре җыелмасы. Көнбатыш диалекты цылаштыручы һәм чылаштыручы сөйләшләргә аерыла. Әлеге мәкаләдә татар теленең көнбатыш диалекты чылаштыручы сөйләшләренә караган ләмбрә сөйләшендә урын алган фин-угор, башлыча мордва теленнән кергән алынмалар өйрәнелә. Диалекталь лексик берәмлекләр безнең тарафтан Мордовия Республикасының Ләмбрә һәм Ромодановский районнарына комплекслы фәнни экспедиция барышында теркәлде.

Мордва һәм татар халыклары арасындагы мәдәни-икътисади бәйләнешләр күптәннән килә. Татарлар элек-электән мордвалар яшәгән җирләрдә гомер кичергән. Мәсәлән, Мордовия Республикасында бүгенге көндә якынча 80 татар торак пункты бар. Мордваларның мордва-каратай этник төркеме шулай ук аерым игътибарга лаек.

Татар һәм мордва телләре күп кенә охшаш күренешләр белән характерланырга мөмкин, бу исә Урал-Алтай берлеге һәм төркиләрнең фин-угорлар белән Идел-Кама бергәлеге чикләрендә бәйләнешмөнәсәбәтләренә бәйле рәвештә аңлатылырга мөмкин. Әлеге этносларның озак вакытлар дәвамында күршелектә һәм хезмәттәшлектә яшәүләре нәтиҗәсендә, татар теле мордва телләреннән кергән аерым алынмалар хисабына да баетыла. Беренче чиратта, әлеге алынмалар мордва-каратайлар телендә яшәп килә [Насипов 2009: 115], диалектолог галимнәр тарафыннан утызга якын шундый алынма көнбатыш һәм урта диалектларның сөйләшләрендә урын алган дип исәпләнә [Махмутова 1976: 153; Насипов 2009: 117; Рогачев 2019: 120].

Р.Г. Әхмәтьянов билгеләвенчә: «Телләрнең үзара тәэсир итешүе һәм бер-берсенә йогынты ясаулары лексикадан башлана, төрле телләрне белүчеләр арасындагы озак вакытларга сузылган бәйләнешэлемтәләр иң элек алынмаларга, шуннан соң инде таныш сүзләрне кулланунның мәгънәләре һәм формалары структурасын калькалаштыруга, ягъни грамматиканы үзара яраштыруга, аннары – төбәкләрне характерлый торган фонетик үзенчәлекләрнең таралуына китерә» (*тәрҗемә безнеке*) [Ахметьянов 1993: 3].

Әлеге хезмәтебезнең төп максаты – Мордовиядә яшәүче татарлар сөйләшендә урын алган лексик диалектизмнарны килеп-чыгышлары ягыннан тикшерү. Эштә куелган максат һәм бурычлардан чыгып тикшерү методлары булып түбәндәгеләр сайланды: лингвистик тасвирлау методы, материалларны җыю, эшкәртү һәм интерпретацияләү кулланылды, диалектология һәм тел белеме буенча хезмәтләр өйрәнелде, кыр тикшеренүләрендә информаторларны сораштыруметод-алымнарыннан файдаланылды. Тикшеренү материаллары булып татар теленең ләмбрә сөйләшендәге мордва алынмалары хезмәт итте. Лексемаларның мәгънәләрен шәрехләү «Сүзлекләрнең электрон фонды»нан алынды (https://suzlek.antat.ru/index.php [дата обращения 17.11.2023]).

2023 елның җәендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Мордовия Республикасының Ләмбрә һәм

Ромодановский районнарының татар торак пунктларына комплекслы фәнни экспедиция оештырылды. Кыр тикшеренүләре барышында җирле халыкның тел үзенчәлекләре, халык иҗаты, музыкаль һәм декоратив-гамәли сәнгате, эпиграфика, археография үзенчәлекләре өйрәнелде.

Мордовия Республикасының без тикшергән торак пунктларында татар теленең көнбатыш диалекты ләмбрә сөйләше таралган [Татар халык сөйләшләре 2018: 195]. Гомумән алганда, сөйләшнең лексик составы татар теленең көнбатыш диалектына хас диалектизмнардан гыйбарәт. Шул ук вакытта локаль үзенчәлекләр дә бар. Кыр тикшеренүләре барышында безнең тарафтан теркәлгән мордва телләреннән кергән кайбер алынмаларны тикшерәбез.

Нәркәмәс [närkämä́s] – ‘оешма чәчәклеләр семьялыгыннан, бик көчле әчкелтем исле ярымкуак үсемлек (медицинада дару буларак кулланыла)’, әдәби телдә – *әрем*: *Нәркәмәс үскән монда*. (Сырка авылы). Әлеге лексема барлык торак пункларда да язылып алынды, шулай ук көнбатыш диалектның кузнецк, темников, карсун, хвалын сөйләшләрендә дә актив кулланылуын билгеләргә мөмкин [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге 2009: 495; Әхмәтьянов 2015: 64]. Сүз мордва телләреннән алынган булса кирәк, эрзя телендә әрем – *нартемкс* (эрзя теленең диалектында – *нартенсть*) һәм мукшыларда – *нярьхкамаз* [Вершинин 2005: 23].

Татар телендә ‘рубус ыругыннан, розачәчәклеләр семьялыгыннан, тамырлары күпьеллык, ә өске сабак өлеше икееллык ярымкуакчыл үсемлек һәм аның җимеше’ мәгънәсенә *кураҗиләк* (*кура җиләге*) сүзе туры килә. Күп кенә торак пункларда әлеге мәгънәне (Ләмбрә, Пензятка, Ширбак, Милцәпә, Сүәрби, Чиремиш) *малина́* [malina] сүзе бирә, рус теленең *мали́на* берәмлегеннән аермалы басым соңгы иҗеккә төшә. Шулай ук кайбер торак пунктларда *курләк* (< кура + йеләк (җиләк)) [kurläk] (Кырви, Сырка) лексемасы да теркәлде. Әлеге диалекталь вариант шулай ук татар теленең көнбатыш диалектының кузнец, сергач, чүпрәле сөйләшләрендә дә очрый. Татар Тавласы авылында безнең тарафтан *энези / энеҗи* [enezi/eneji] диалектизмы язып алынды. Әлеге лексеманы фин-угор халыклары белән турыдан-туры контактта яшәү нәтиҗәсе булган алынма дип карарга мөмкин: кура җиләге мукшы һәм эрзя телләрендә *инези* и *инзей* сүзләре белән бирелә [Русско-мокшанский словарь; Словарь русский-эрзя].

Без өйрәнгән торак пунктларда *пангы* [pangɤ] сүзе актив кулланышта. Әлеге сүз фин-угор алынмасы буларак кабул ителә һәм ‘түбән төзелешле үсемлекләр классыннан чәчәге, яфрагы булмаган, споралар ярдәмендә үрчи торган организм’ мәгънәсенә ия (татар әдәби телендә – *гөмбә*), лексема шулай ук татар теленең көнбатыш диалектының күп кенә сөйләшләрендә файдаланыла: *Бер косяк пангы йыйдык агацлыкта* (Татар Тавласы). Ул югарыда күрсәтелгән мәгънәгә ия һәм мукшы теленең *панга* һәм эрзя теленең *панго* сүзләренә кайтып кала [Вершинин 2005: 333].

Татар әдәби телендәге *миләш* (әлеге лексема шулай ук фин-угор алынмасы [Насипов 1995: 59]) урынына көнбатыш диалектының ләмбрә, темников һәм карсун сөйләшләрендә *пизел* [pizel] сүзе кулланыла. Ул ‘гөлчәчәклеләр семьялыгыннан аерчалы яки парсыз каурыйсыман яфраклы, калкансыман ак чәчәк төркемле һәм тәлгәшләрдәге түгәрәк саргылт кызыл ачы җимешле агач; шул агачның җимеше’ семасында килә. Сүз шулай ук мари теленең төньяк-көнчыгыш диалектында *пизли/пызли* [Рогачев 2019: 122] вариантында очрый. Мукшы телендә *пизел* ‘миләш агачы һәм аның җимешләре’ [Русско-мокшанский словарь], эрзяларда *пизёл* ‘миләш агачының җимеше’ [Словарь русский-эрзя] мәгънәләрендә кулланылган. Галимнәр *пизел* сүзе татар теленә чагыштырмача соңрак кергән дип исәпли [Насипов 2009: 122]. Татар теленең «Татарча-русча сүзлег»ендә *пизел* сүзе ‘урман-дала өлкәләрендә үсә торган балан төре’ һәм диалекталь вариант билгесе белән ‘балан (гади)’ дигән ботаник термин буларак күрсәтелә [Татарча-русча сүзлек 2007: 143]. Әмма моңа кадәр чыккан сүзлекләрдә һәм диалектологларның хезмәтләрендә әлеге мәгънәгә туры килгән сылтамаларны тапмадык.

Информатлар белән сөйләшү барышында, шулай *пукыл* [pukɤl] сүзе язылып алынды, әлеге сүз шулай ук мордва телләреннән кергән алынма буларак карала ала. Ул ‘нинди дә булса каты әйбернең формасыз зур кисәге, кантар’мәгънәсенә ия. Диалекталь сүзлекләрдә сүзнең шулай ук ‘бөтеннән кисеп алынган бер өлеш, кисәк’ лексик-семантик варианты да теркәлгән. Әлеге мәгънәдә сүз ләмбрә сөйләшендә кулланыла дип күрсәтелгән [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге 2009: 541]. Экспедиция барышында без өйрәнгән торак пунктларда әлеге мәгънә теркәлмәде.

Күргәнебезчә, Мордовия Республикасының Ләмбрә һәм Ромодановский районнарында яшәүче татарларның диалекталь сөйләмендә ки-

леп чыгышлары буенча мордва алынмалары булган лексик берәмлекләр бар. Алар чагыштырмача аз, безнең тарафтан нибары биш шундый берәмлек теркәлде. Әлеге лексик берәмлекләр татар теленә җайлашкан һәм татар теленең көнбатыш диалектында ләмбрә сөйләше вәкилләренең көнкүреш сөйләмендә актив кулланыла. Әлеге берәмлекләр татарларның мордва халкы белән тел бәйләнешен дәлилли.

ӘДӘБИЯТ

Ахметьянов Р.Г. Татарский язык в Волго-Камском языковом союзе: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 1993. – 36 с.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – Т. 1. – 543 б; Т. 2. – 567 б.

Вершинин В.И. Этимологический словарь мордовских (эрзянского и мокшанского) языков. В 4-х томах. – Т. III. – Йошкар-Ола, 2005. – 356 с.

Махмутова Л.Т. Некоторые наблюдения над лексикой мишарских говоров (к мишарско-мордовским заимствованиям) // Вопросы лексикологии и лексикографии татарского языка. – Казань, 1976. – С. 152–159.

Насипов И.С. Опыт систематизации финно-угорских заимствований в татарском языке. – Казань, 2009. – 236 с.

Рогачев В.И. Идел буендагы мордва-татар тел багланышлары турында / В.И. Рогачев, Ф.С. Баязитова, Р.Т. Сәфәров. // Фәнни Татарстан. – 2019. – №2. – Б. 115-123.

Русско-мокшанский словарь https://paevo.ru/mordva/mokshen-kyal/russko-mokshanskij-slovar [дата обращения 17.11.2023].

Словарь русский-эрзя // https://ru.glosbe.com/ru/myv [дата обращения 16.11.2023].

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. 2 нче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 463 б.

Татарско-русский словарь: в 2-х томах. – Т. 2 (М-Я). – Казань: Магариф, 2007. – 726 с.

УДК 811.512.145

Булатова Миннира Рахимовна,
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ

Именные части речи в кузнецком говоре татарского языка (на материале научной экспедиции)

татарский язык, ареальная лингвистика, диалектология, западный диалект татарского языка, кузнецкий говор, морфология

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ каждый год проводит комплексные экспедиции в районы Татарстана и за пределами республики, т.е. места компактного проживания татарского народа. В 2019 году институтом была организована очередная комплексная экспедиция в Неверкинский, Кузнецкий и Сосновоборский районы Пензенской области, в состав которой вошли не только диалектологи, но и археографы, фольклористы, специалисты по истории музыки и искусства. Собрать духовное и национально-культурное богатство татар, изучить его, ввести в научный оборот, передать последующим поколениям – одна из основных задач, стоящих перед нашими учеными.

В ходе поездки (с 27 мая по 7 июня 2019 г.) было обследовано 18 татарских населенных пунктов: Алеево, Сарбай (Сулеймановка), Карновар, Мансуровка, Бигеево, Бикмосеевка, Исикеево, Джалилова, Мазарлы (Октябрьское), Дёмино Неверкинского района; Бестянка, Татарская Пенделка, Ялгаш (Большой Труев), Татар Кынадысы, Дәхтәрни (Малый Труев) Кузнецкого района; Индерка, Альмяшевка, Татарский Сыромяс Сосновоборского района. Жители указанных деревень являются носителями кузнецкого говора западного (мишарского) диалекта татарского языка. Отметим, что данный говор распространен также в Шемышейском, Спасском, Пачелмском, Белинском, Каменском и Лопатинском районах Пензенской области. Известно, что западный диалект делится на две группы говоров – *ч*-окающую и *ц*-окающую. Кузнецкий говор относится к *ч*-окающей группе.

Кузнецкий говор в 1958-1960 гг. впервые исследован языковедом Л.Т. Махмутовой [Махмутова 1962, 1978], в 1985 г. – диалектологом Ф.С. Баязитовой [Татар 2008, II: 42-53]. Богатая лексика и другие языковые особенности татар Пензенской области отражены в таких трудах, как «Диалектологический словарь татарского языка» (три выпуска – 1969, 1993, 2009), «Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья» (1989), «Атлас татарских народных говоров» (2015), «Татарские народные говоры» (2008, на тат.) и др.

Во время экспедиции нами были изучены фонетические, морфологические, лексические особенности кузнецкого говора; также собраны материалы, отражающие материальную и духовную культуру татар, и

устное народное творчество. Сквозь призму лексики местного говора рассмотрены обычаи и нравы татар области.

По составу, характеру функционирования грамматических категорий частей речи кузнецкий говор западного диалекта татарского языка проявляет общность с татарским литературным языком, вместе с тем, в них обнаруживаются и отличительные моменты.

Имя существительное. При склонении имен существительных с аффиксом принадлежности I и II л. ед. ч. в винительном падеже иногда может употребляться огузский тип аффиксов (аффиксы *-ы/-е* вместо *-ны/-не*): *дусларымы* – лит. дусларымны ‘моих друзей’, *чәйеңе* – чәйеңне ‘твой чай’. Например: *Утынымы* (утынымны) *киссәгез, арендага бирәм ызбаны, бер кичкә вичер уздырырга. Камырымы алам, йәйәм табага. Инеш буйына барасын да, битеңе йуасын.* Это явление отмечено и в говорах среднего диалекта.

Употребление двойного аффикса принадлежности III лица единственного числа (*-ы/-сы/-е/-се*), который достаточно широко распространен на территории Татарстана, Мордовии, Пензенской области: *дустысы* – лит. дусты ‛его друг’. *Безнен татар халкысы* (халкы) *ызын йеңле күлмәк кийәләр иде*. *Сөннәт туйысын* (графич. туен) *уздыралар. Ишек алнысы* (ишек алды) *читән иде.*

В говоре грамматический показатель категории принадлежности может отсутствовать, т.е. выражение посредством безаффиксного изафета: *кыз кичә* вместо лит. кыз кичәсе, *карту белен* – лит. бәрәңге белене, *мөшке бәлеш* – мөшке (эремчек) бәлеше, *тирәз төп* – тәрәзә төбе, *айу камыр* – айу камыры –гөлҗимеш. *Тарас бабам утын кисә йереде, тәрәз төпләр* (тәрәзә төпләре) *йасады.* Данная особенность характерна для восточных (сибирско-татарских) диалектов, а также некоторым окраинным говорам среднего и западного диалектов.

Имя числительное. По лексическому составу и образованию числительных говор в основном совпадает с татарским литературным языком. Имеются лишь небольшие расхождения, например, употребление собирательных числительных вместо количественнных: *Без сигезәү олан* (сигез бала) *үстек. Үзе генә тегел, тугызаумы* (тугызмы), *унберәүме* (унберме) *анда.* Это явление характерно и для наречия *күп* ‛много’ в других говорах западного диалекта: *күбәү / көбәү.*

Наречие. Литературные наречия типа *көн буе, төн буе, кыш буе* в кузнецком говоре, как и в других говорах западного диалекта [Булатова

2018: 139], активно употребляются в формах *көн ката, кыш ката*: *Төн ката молотилкада суга идек. Көн ката урамда йереде.*

Наряду с литературными *тапкыр, мәртәбә* используется слово *тынап* (тапкыр, мәртәбә, рус. *раз*): *Кырда көненә ике тынап* (лит. ике тапкыр) *ашаталар. Татар теле ике тынап атнасына укытыла иде.*

Лексические наречия: *карсак* – лит. түбән ‛низко’, *койты* – начар ‛плохо’, *йаз башын* – язын ‛весной’, *йазын* – җәен ‛летом’, *үңгә* – башка ‛иначе ’, *тынасыз* – хәл җыймыйча, *жар* – эссе, *йаңгыз* – ялгыз, *кыңгыр* – кәкре ‛криво’, *тенә* – кичә ‛вчера’, *йурап* – юри ‛нарочно’, *мәңгедән* – электән, бик күптән ‛очень давно’, *сирәк-сайак* – сирәк-мирәк ‛редко’, *иртәгәдән соңга* – берсе көнгә ‛послезавтра’ (Сравни: фонетические варианты данной лексемы распространены у татар Мордовии – *иртә соң/иртә ары*, Нижегородской области – *иртә узгач,* Респ. Башкортостан *иртәгә соңга/иртәдән соңга* [Булатова 2021: 106]) и др.

Местоимения. Как и в лямбирском, мелекесском, карсунском, хвалынском говорах западного диалекта и астраханского говора среднего диалекта, местоимение *берче* употребляется в значениях: 1. ‛всегда, постоянно’: *Кулында китабы, берче укый гына*; 2. ‛сплошь’: *Бу урын берче урман булган*; 3. ‛совсем’: *Кулым арыды берче*; 4. ‛всё, все’: *Килегез берчегез* (барыгыз да), *килегез бире. Берчесе халык урамда. Берчесе йат авылныкылар.*

Указательные местоимения*: выты/вата/вытыка/вытыкай* – <рус. вот – лит. менә, әнә. *Анын выты* (лит. менә) *йеп бәли торган нийесе бар иде. Ватыка мәчетебез безнеке.* Редко: *выныкай / мыни.*

Употребление вопросительного местоимения *нәстә*: *Өлгереш ун´аганда наказ бирәләр нәстә* (лит. нәрсә)*, нишләргә – бийергәме, йырларгамы.Бер куймы, кәзәме – нәстә очрый, шуны чалалар.Деге буткасы булса, анын өстенә йөземэләк, кур´ага, нәстә бар салалар.*

Таковы некоторые наблюдения над именными частями речи в кузнецком говоре западного диалекта татарского языка. Далее приводятся образцы текстов данного говора, записанные на диктофон во время экспедиции, которые обработаны и даются в транскрипции.

Образцы речи

вичерда түгәрәк ун´нар (*уеннар*)/ кыругта йырлау/ бийеп йе^{ә}рү иде// өлгереш дип ат‘а (*әйтә*) идек// сине суга да ремен´ белән/ йә йөслек (*сөлге*) белән/ ыстулга куйа да/ син өлгер алып// өлгермәден/

сине суга/ аннан наказ бирәләр нәстә/ нишләргә – бийергәме/ йырларгамы инде анда/ ни дә булса сүләүме // миңа туры килде күᵉрсәтергә кулыңнан кан ᵀчыгар дигән наказны// ниᵀчек мин кан ᵀчыгарим кулымнан?// ул икән лампага каршы куйарга да/ кызыл күренә// шул кан чыгу була икән// икенче берәүгә/ йыласын, йәшен себерсен// ул икән култасмал (*кулъйаулык*) белән/ тирәсе тирләгән/ тирәсне себерегә (*тәрәзәне сөртергә*) кирәк// йеᵉзек йәшерү дә бар иде//

таwык корбаны дип атәләр бездә// йаңгыр йаумагандабала-тчага чиләкләр алып/ урамда узып барган кешеләр өстенә су сибә// оланнар (*балалар*)таwык корбаны ун´ап бетергәч/ йаңгыр/ йау/ йау/ иләктән/ чиләктән/ пәрәмәчә коймактан/ арыштан/ бодайдан/ без сорыйбыз ходайдан/ дип йеᵉриләр// бала-тчага дҗийыла// аларга нәстә ни булганны чыгарып бирәсен// кас´ы йымырка/ кас´ы конфит/ кас´ы акча/ кас´ы он// аннан инде бер кеше су йанына барып, оннанмы эләкшә (*токмач*) кебекме пешерә/ йымыркамы пешерә// выты шылайга// су теᵉбенә дҗийылалар/ утыралар/ оланнар ашый//

туй йоласы// сондыкка бирнә йыштырасын (*җыясың*)// туйдан алныда китерә сондыкны// туй кенендә китерделәр йәш киленне// ачтылар сондыкны// сондыкнын эчендә кан´ана өᵀчен намазлык иде// тагын ниндидер материалдан падаркалары// сондыкны бушатып, шул йөсләкләрне/ бөтен ниләрне тага иделәр туй кенендә// туй халкы багып торган// йәймә йәйдергән/ салма тапаттырган (*токмач кистергән*) киленнән// йәш килен акча сипкән килгәндә// оланнар йыштыра иделәр// урны-йерне кигезгәндә йырлыйлар/ акмы йастык тышлары/ күкме йастык тышлары?/ севеп (*сөеп*) алган, севеп барган/ шолар оҗмаһ кошлары дип йырлыйлар// кийәү йегетләрен кергезә баралар/ йырлыйлар//

Записано в дер. Большой ТруевКузнецкого района Пензенской области от Ишкуловой Раузы (1940 г.р.).

Записывала М.Р. Булатова. 2019 г.

ташу вакыты// биг зур авыл булган бездә// беркаа да халык китмәгән әмән/ тетелмәгәннәр (*таралмаганнар*)/ эж (*эш*) булган// койты (*начар*) булмаган безнен авыл/ тату торганнар// йаз башы бик күрекле (*матур*) уза иде// су буйларында зур су/ бозлар ага иде биг// ташу әтәбез// мустлар йуг иде элгәре// эшләрне ашыгып-ашыгып бетерәбез дә/ берчебез урамга// халык кичен китә су багарга// гармуннар/ бийүләр/ йырлаулар// култасмал ыргыта иделәр суга/ теләкләр теләп//

те^{е}гели, те^{е}гисез// пижага (*мич башына*) джийылып, ун´ийлар иде// бер кулына куйа чигелдәк (*бавырсак*) өчнеме-дүртнеме// бусы белергә тийеш/ те^{е}гилеме-те^{е}гисезме (*парлымы-парсызмы*)// угадат´ итсә, чигелдәкләрне ала// йанвар айында шу^{о}ндый йола// оланнар азбар (*йорт*) сайын йе^{е}ределәр// пасха да эшли иделәр// бездә дә мәңгедән (*күптән*) йымырка пешерү бар иде суган кабыгына буйап//

Записано в дер. Карновар Неверкинского района Пензенской области от Мансуровой Марьяма (1947 г.р.)

Записывала М.Р. Булатова. 2019 г.

ЛИТЕРАТУРА

Булатова М.Р. Ульяновск өлкәсендәге татар теленең көнбатыш диалекты сөйләшләре һәм халык традицияләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Ульяновск өлкәсе татарлары. – Казан, 2018. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; 19 нчы китап). – Б. 131-192.

Булатова М.Р. Татарские говоры Башкортостана: ареальный аспект. – Казань: ИЯЛИ. 2021. – 136 с.

Махмутова Л.Т. Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области (по материалам экспедиций 1958-1960 гг.) // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. – Казань, 1962. – С. 125-162.

Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. II китап. / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. – Казан: Мәгариф, 2008. – 495 с.

УДК 811.512.145

Галиуллина Гөлшат Рәисовна,
Казан федераль университеты

Татар халык мәкальләрендә ялгызлык исемнәре

ялгызлык иseме, татар теле, мәкаль, прецедент исем

Фольклор текстларында теркәлгән тел элементлары халыкның тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүдә бәяләп бетергесез ярдәм күрсәтә. Һәр тел берәмлеге белгечләр тарафыннан аерым тикшерүгә лаек. Танылган галимә С.Е. Никитина искәртүенчә, әлеге текстлардагы ялгызлык исемнәрен анализламый торып, фольклор текстлары нигезендә дөнья картинасы кыйммәтләрен сурәтләү мөмкин түгел [Никитина 2005: 279-281].

Бу җәһәттән фольклорның кече жанрлары аеруча кызыклы. Фольклор текстларына күзәтү күрсәткәнчә, аларда бик күп санда ялгызлык исемнәре кулланылган, һәм алар милли дөнья картинасын тулаем күзалларга ярдәм итә. Кеше ономастик берәмлекләр аша үз фикерләрен төгәлрәк, эмоциональрәк белдерә, чөнки фольклор текстларындагы ономастик берәмлекләр, икенчел номинациядә килеп, тирән эчтәлекле коннотациягә ия була башлыйлар. Ялгызлык исеменең коннотатив мәгънәсе нәкъ менә контекстта ачыла, чөнки бу төр текстларда исем үзенең төп функцияләреннән булган индивидуальләштерү, конкретлаштыру кебек үзлекләрен югалта һәм сигнификатка ия була башлый.

Анализ өчен без составында ялгызлык исемнәре булган татар мәкальләрен сайладык. Күзәтүләр күрсәткәнчә, мәкаль контекстында ялгызлык исемнәрен куллану кешенең объект яки хикәяләү субъекты турындагы белем күләменә бәйле.

Татар фольклор текстлары авылларда туа. Авыл җирлегендә кешеләр бер-берсен яхшы белә. Шуңа күрә аерым кешенең исеме, торак пункт атамасы шул исемне йөртүче кешегә яки торак пунктка хас сыйфат, үзлекләр белән бергә тотрыклы гыйбарә буларак кулланыла башлый. Бу очракта ялгызлык исеменең төп вазифасы аның җыйнак, төгәл булуында, сөйләүченең предметка яки субъектка карата булган уңай яки тискәре мөнәсәбәтен бөтен нечкәлекләре белән җиткерә алуында күренә. Шуның нәтиҗәсендә, ялгызлык исеме фольклор тексты составында эмоциональ йогынты ясауның көчле чарасы булып тора. Әйтергә кирәк: мәкальләрдә ономастик кырның үзәк элементлары – антропонимнар һәм топонимнар бик актив кулланыла, ә периферия элементлары – зоонимнар һәм космонимнар сирәгрәк очрый.

Фольклор текстлары составында онимнар өлешчә яки тулысынча индивидуальләштерү үзлекләрен югалталар һәм апеллятив лексика сыйфатында яши башлыйлар. Аерым очракларда күмәклек сүзләренең кайбер үзлекләрен кабул итәләр. Икенчел функция башкару барышында ялгызлык исеме эчке формага ия булып кына калмый, халыкның дөньяга карашын да чагылдыра [Галиуллина 2016: 117].

Без, анализлаган материал нигезендә, [Исәнбәт 2010; Галиуллин 2018] аеруча киң таралган түбәндәге үзенчәлекләрне аерып чыгардык:

1. Ономастик лексика экспрессив функция башкара: *Чулпан калыкты – ай батты*; *Әстерханда сыер бер акча, килә-килә мең акча; Ерактан баксам даһи, якыннан баксам тиле Шаһи; Кенәргә кайту Бо-*

харадан кайтудан авыр һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, ялгызлык исемнәре бу очракта капма-каршылыкны көчәйтә.

2. Мәкальләр составында ясалма онимнар, күбрәк антропонимнар, кулланыла: *Әлхәм белән Әбҗәткә без кермибез әҗәткә; Әкеми, сиңа кызлар тәтеми; Әлҗе Бәлҗегә бирә, Бәлҗе йотып җибәрә; Мәмәт ачы алма ашаганга Шәмәтнең теше камашкан.*

3. Аллитерация: *Покрау үтте – кыш җитте; Карга үзенең баласына: «Зариф зирәктән туган», – дип әйтә, ди; Идел каргасы Идел ибенә, Җаек каргасы Җаек җаена очар; Чулманда икән чурагай* һ.б. Билгеле бер тартыкларның кабатлануы мәкаль текстларында шактый киң таралган. Безнеңчә, әлеге алым экспрессияне көчәйтә һәм мәкальне истә калдыруга ярдәм итә.

4. Рифмалаштыру: *Чулманны чуманга утырып кичмиләр; Ахирәттә Әхмәдигә ак тәкә; Бер көн Харис белән, бер көн Барис белән; Бирдек Бибине кияүгә, рәхәтләндек буяуга; Күктә Чулпан булудан суда чуртан булу артык;Әрле Мәликәгә коры тәлинкә* һ.б.

Мәкальләрдә күзгә ташланган бер үзенчәлек – төрле контекстларда аерым исемнәрнең кабатлануы. Аларның бер өлеше прецедент исемнәр булып тора, мәсәлән, Оренбург краенда зур татар мәдәнияте үзәге булган *Каргалы* авылы атамасы. Бу авыл мәчетләре һәм алар каршында эшләүче мәдрәсәләре белән билгеле була. Мәкальләрнең семантикасында да әлеге мәдәни-тарихи мәгълүмат чагылыш таба, мәсәлән, *Арбалыга Каргалы ерак түгел; Оренбур-Каргалы – бар да тимер арбалы; Оренбурда арба күп, Каргалыда мулла күп* һ.б.

Казан шәһәре атамасы да шактый еш очрый: *Алдың – Казан өлгесе, артың – Мәскәү көзгесе, Җиттек, Җәмилә, Казанга, Казанга каенсардан юл туры, Бар да әзер: камыт Казанда, арба базарда* һ.б.

Татар мәкальләре составында Идел елгасының атамасы 72 мәртәбә очрый: *Ерганаклар Идел ясар, аларны Идел ашар, Идел кичмичә аягыңны киптермә, Идел чыкканчы балтасын бирә, Идел чыккач сабын да тоттырмый, Идел суы илле батман, Идел суы илле батман, Идел башыннан болгана, тамагыннан тона* һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, әлеге топоним эчтәлегендә 'зур елга', 'су', 'куркыныч' һ.б. шундый мәгънәләр урын ала.

Алда әйтелгәнчә, мәкальләр озак вакытлар дәвамында формалашкан, алар халыкның рухи мәдәниятен һәм тел традицияләрен чагылдыра. Бу, һичшиксез, ялгызлык исемнәренең кулланылышында да күзгә

ташлана. Мәсәлән, мәкаль текстларында топонимнарның архаик яки пассив формаларын (*Җаек, Ирәмәл, Алат, Хаҗитархан, Өргәнеч, Рум* һ.б.) күрсәк, күп кенә антропонимнар сөйләм теленә хас яңгыраш алганнар (*Гатакай, Гыйбди, Шаһи, Ибрай, Шәйхел* һ.б.).

Татар мәкальләрендә теркәлгән ялгызлык исемнәр арасында рус теленнән кергән онимнар да шактый урын алып тора, аларның бер өлеше тел үзгәрешләренә дучар була: *Аяз-аяз көннәрдә алма җыя Ычтапан* (Степан)*, карлы-бозлы көннәрдә ашлык суга Ычтапан; Элҗен көн* (Ильин день) *яңгыр яуса, илле көн яңгыр явар; Питраудан* (Петров день) *соң кошлар сайравы бетә, үләннең тәме китә; Күзмә* (Кузьма) *күпер суга, Микула* (Никола) *кадак кага; Симән көнне* (день Семиона Столпника) *суга бер кашык суык керә, ди.* Аларның үтеп керүендә күрше фин-угор халыклары белән элемтәләр шактый роль уйнаган, дип уйларга мөмкин. Шулай ук керәшен татарларының да роле бик зур.

Татар халык мәкальләре текстларында фольклор жанры үзенчәлекләренә туры килми торган кеше исемнәр төркеме кулланыла. Аларның эчтәлегендә билгеле бер мәгълүмат сизелмәгәнлектән һәм аларга хас үзенчәлекләрнең киң катлам татарлар өчен таныш булмаганлыктан, без аларны «очраклы исемнәр» дип атадык. Бу исемнәрнең мәкаль составына үтеп керүе, мөгаен, билгеле бер территориядә яки тирәлектә бер шәхеснең популярлыгы белән аңлатыладыр. Шул сәбәпле, беренче карашка «очраклы исем» булып күзалланган антропонимның, мәсәлән, *Әхмәдулланың билбавы булмаса, эче шартлый; юлчыдыр Габбас, беркемгә дә бакмас, кайтса китмәс, китсә кайтмас; Әхмәт абзый ашап тора, Әмир абзый йотып тора; бәтәч, Маннаф, син дә салдыңмени бер әтәч, мин дә салган идем бер әтәч* кулланылышы җиңел аңлатыла.

Мәкалә текстларында мифик геройларның, мөселман дине белән бәйле шәхес исемнәре дә урын ала: *яр итмәгән ярга Локман хаким дә дәрман тапмас; Сөләйман үлде, диюләр котылды; сөңгеле Сөләйман булдың инде; тау Мөхәммәткә килмәсә, Мөхәммәт тауга килә; берәүнең Мәккәсе Мәкәрҗәдә; ялгыз башың, Хозыр юлдашың; минем кулым түгел, Гайшә-Фатыйма кулы* һ.б.

Шулай итеп, татар халык мәкальләре халыкның дөньяга карашын, менталитетын һәм милли үзенчәлеген чагылдыра. Анализ күрсәткәнчә, татар халык мәкальләрендә кулланылган ялгызлык исемнәре фольклор дөнья картинасын репрезентацияләүдә зур роль уйный.

Мәкалә «Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр» фәнни белем бирү үзәге кысаларында язылды.

ӘДӘБИЯТ

Галиуллин К.Р. Татар фольклоры теле: мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, җор сүзләр һәм әйтемнәр: сүзлек = Язык татарского фольклора: пословицы, крылатые выражения, присловья и поговорки: словарь. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 588 б.

Галиуллина Г.Р. Прецедентные имена в современном татарском языке // Ученые записки Крымского федерального университета им. В.И. Вернадского. Филологические науки. – 2(68). – № 3. – Симферополь, 2016. – С. 117-122

Исәнбәт Нәкый. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. – 2 нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.

Никитина С.Е. Собственные имена в жанрах русского религиозногофольклора // Ономастика в кругу гуманитарных наук: Сб. ст. – Екатеринбург: Изд-во Уральского ун-та, 2005. – С. 279-281.

УДК 811.512.145

Гарипова-Хәсәншина Венера Макмуновна,

Россия ислам институты

«Исем» (1899) хезмәтендә XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар антропонимикасының кайбер актуаль мәсьәләләре

антропоним, лексика, исем төзелеше, ислам кануннары, графо-фонетика, татар теле

Антропонимика – традиция һәм чор таләпләренә шактый сизгер лексик катламнарның берсе. Төрки-татар дөньясындагы рухи-мәдәни, иҗтимагый-тарихи үзгәрешләр исемнәр системасына да сизелерлек йогынты ясый. Татар антропонимикасы үсешендә шундый әһәмиятле этапларның берсе – ислам дине кабул ителү.

Мөселман кеше исемнәре, гасырлар дәвамында торган саен киңрәк таралыш алып, XX гасыр антропонимиконында үз урынын тәмам ныгыта [Галиуллина 2007; Галиуллина 2009; Хаҗиева-Демирбаш 2018]. Бу шул чорга нисбәтле язма чыганаклар тарафыннан да раслана. Мисал өчен, исем кушуның практик мәсьәләләрен күздә тотып язылган шундый хезмәтләрнең берсе – «Исем». «Исем», 1899 нчы елда Санкт-Петербург

цензурасыннан рөхсәт алынып, Казанда, Б.Л. Домбровский типографиясендә басылып чыга. Хезмәтнең титул битендәге кулдан өстәлгән мәгълүматка караганда, төзүчесе (авторы) – Габделхак Нигъмәй улы әл-Чуаши. Әлеге китап, автор ассызыклавынча, «балага күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кыйлурга муафыйк китаб» [Исем 1899: 1] буларак төзелгән. Алдан ук шуны әйтергә кирәк: күләме ягыннан зур булмаган «Исем» ниндидер зур фәнни ачышларга, тирән лингвистик анализга дәгъва кылмый. Ул, иң беренче чиратта, гамәли максатларны күздә тота. Китап авторы исем кушуда татар антропонимиконында гасырлар чигендәге, ягъни үз чоры өчен актуаль булган төп юнәлешләрне билгеләргә һәм күрсәтергә тырыша. Ул, беренче чиратта, шуның белән әһәмиятле дә. Икенче яктан, хезмәт XX гасыр башы татар антропонимиясенең графо-фонетик, исем ясалыш үзенчәлекләрен чагылдыру нисбәтеннән дә игътибарга лаек. «Исем»дә шул чорның антропонимик традициясенә хас төп принциплар чагылыш таба, ислам кануннары нигезендә балага исем кушу, исем сайлау кагыйдәләре билгеләнә. Әлеге китап XX йөз башы татар кеше исемнәренә кагылышлы әнә шул сорауларга берникадәр ачыклык кертергә ярдәм итә.

Алда әйтелгәнчә, авторның төп максаты – үз чоры өчен актуаль булган кеше исемнәренә күзәтү ясау һәм ислам дине кысаларында гамәли киңәшләр бирү. Хезмәттә атаның баласы алдында җаваплылыгы «күркәм исем бирмәк» дип күрсәтелә [Исем 1899: 1]. Күркәм исем, аның карашынча, шәригать кануннарына туры китереп сайланган антропоним. Автор әлеге фикерне ассызыклап кына калмый, ә бәлки фикерен ислам тарихыннан алынган мисаллар белән дә ныгыта: «<…> заман җаһилиятдә куелмыш исемләрне күркәм исемгә алыштурдыкы риваять идүб диерләр ки, нәбиинә салаллаһу галәйһи вәссәламнең хозурына бер ир кәлде, Асрам исемле ирде, Зургә исеменә алуштырды. Дәхи Музтәҗег исемле кемсәне Мутбәгескә, Гомәр разый Аллаһу гәнһүнең кызы Гасыйә исемле улуб, Җәмилә исеменә алыштырды» [Исем 1899: 3]. Мисал өчен, әлеге өзектә искә алынган «гөнаһлы» [Махмудов 1965: 86] мәгънәсенә ия Гасыя исеменең нигезендә «матур, гүзәл, күркәм» [Махмудов 1965: 775] төшенчәләре яткан Җәмиләгә алыштырылу сәбәбе ачык аңлашыла.

Исемнәргә гомуми анализ-күзәтү ясаганда, автор төп ике принципны нигез итеп ала: антропонимнарның структурасы һәм аларның семантикасы. Семантика ягыннан фикер йөрткәндә, хезмәттә исемнәр «мәгънәсе шәригать кануннарына туры килгән» һәм «мәгънәсе яхшы

булмаган» дигән төркемнәргә аерып карала. Мәгънәсе яхшы булмаган антропонимик берәмлекләргә бер компоненты *рәшит, әмин, хәким* булган кушма исемнәр дә кертелә: «Биргән исемләр Аллаһы Тәгалә исеме улуб, вә һәм пәйгамбәремез салаллаһу галәйһи вәссәламнең исеме һәм күнйәсе берлә Мөхәммәд Әблкасыйм димәк кеби һәм дә рәшид, әмин, хәким кеби <…> исемләре дә куймайалым» [Исем 1899: 3].

Хезмәттә, структур яктан караганда, шәригать кануннарына туры китереп сайланган исемнәрнең «кыска бер кәлимәләр улса, бик муафыйк» икәнлеге искәртелә, ә кушма антропонимнарның «изафәсе җаиз, ягъни ике кәлимә мәгънәләре буенча берсе берсенә кушылуб, Габделрахман, Габдулла исеменә охшаган» булырга тиешлегенә басым ясала [Исем 1899: 4]. Автор уйлавынча, ике компонентлы исем куелган очракта, һәр ике лексема да мәгънә ягыннан бер-берсенә туры килеп, аларның семантик суммасы, ягъни кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән гомуми мәгънәсе шәригать кануннарына каршы килмәве төп шарт булып тора.

Китапта «Күркәм исемләр» (اسملرکورکم) баш астында структур яктан тамыр һәм кушма исемнәр карала. Бер тамырга нисбәтле гади, ягъни «мәгънәсе яхшы, шәригатькә муафыйк, язарга һәм эндәшергә еңел булган, бер кәлимә генә булган исемләр»гә мисал буларак, Шәкиб (شکیب), Сәһел (سهل), Вәрка (ورقه), Рагыйб (راعب), Госман (عثمان) кебек антропонимнар китерелә [Исем 1899: 5-6]. Икенче төркемдә «ике кәлимәле улуб, мәгънә җәһәтендән изафәсе җаиз, шәригатьчә күркәм» [Исем 1899: 7] исемнәр бирелә. Монда күрсәтелгән антропонимнар, автор фикеренчә, Аллаһы Тәгалә исемнәренең берсенә изафә булып тора. Бу төркемдә структур яктан ике тамырлы, «عبد» (кол) лексемасыннан башланган кырыктан артык исем урын алган: Габделгалләм (عبدالعلام), Габделгани (عبدالغنی), Габделразак (عبدالرزاق), Габделрахман (عبدالرحمن) һ.б. Шушы ук төркемгә «قلی» (колый) компонентлы ике исем дә кертелгән: Рахманколый (قلیرحمان), Ходаколый (خداقلی) [Исем 1899: 7]. Әлеге конструкциядән тыш, ике составлы исемнәрнең тагын бер төркеме буларак «الدين» компонентлы антропонимнар китерелә: Шәмсетдин (شمسالدين), Гыйбасетдин (غباثالدين), Нуретдин (نورالدين), Хисанетдин (حسنالدين) һ.б. Автор карашынча, составында «لدين», «عبد» булган кушма исемнәр, шәригать күзлегеннән караганда, исем кушар өчен иң кулай һәм дөрес дип табылган вариантлардан санала.

Югарыда сүз барган ике компонентлы антропонимнарның шәригать тарафыннан хупланучы исемнәр булуын күрсәтү белән бергә, автор структурасы һәм мәгънәсе җәһәтеннән уңышсыз антропонимик берәмлекләр очравын да искәртә: «Нәбиинә салаллаһу галәйһи вәссәламнең заман сәгадәтләрендә булмайуб, мең еллар уздыкдан соңра, <…> таифәләрдә шөһрәтләгән ике исемне бер кеби кыйлуб бирә торган исемләр – Әхмәткарый, Әхмәтсадыйк, Мөхәммәдхан кебиләр тәркиб изафы, тәркиб тәүсыфы улурга салих улмаюб, изафәнең шартлары булынмадыкдан, мәхмел вә мәгънәсез булуб каладыр, шәригать исламияча күркәм улан исемләр юкарыда яздыкымыз Салих, Муса, Ибраһим вә гайри әнбияи вә сәхабә вә салифләр исемләредер» [Исем 1899: 9].

Автор тарафыннан уңышсыз дип билгеләнгән исемнәрнең тагын бер төркеме – «карый» лексемасы ярдәмендә ясалган антропонимнар: «Болгар ханлары заманында хан ругларындан бер кемсә Карый карьясындан зоһур итдеке мөнәсәбәте берлә угылны Хаҗикарый диб тәсмия кылдыкындан соң, балалары, сөннәт күреб, исемләренең ахырына *карый* кушуб, шуңа иярүб, әхәдисе нас Сәедкарый кеби исемләр бирә калмышлар. Бу исә, Бәгләбәк исеме кеби мәгънәсез мәхмелкылдыкы ичүн күркәм булмады» [Исем 1899: 9].

Алга таба автор исемнәрне группаларга төркемләүдә лексик-семантик бүленешне нигез итеп ала. Бу бүленештә дә берничә группа аерып карала: 1) Адәм галәйһи вәссәламнән Мөхәммәд пәйгамбәргә кадәр булган мәшһүр исемнәр. 2) Мөхәммәд салаллаһу галәйһи вәссәламнән соңгы мәшһүр дин вәкилләре исемнәре. 3) Кызлар өчен яхшы исемнәр. Беренче төркемгә «Хәзрәт Адәм галәйһи вәссәламдән нәбиинә салаллаһу галәйһи вәссәлам заманынача улган исемләрнең мәшһүрләрне күркезәлем» җөмләсе баш астында Лаваз (زولا), Багур (باعور), Габер (عابر), Фәридун (فريدون), Ләмек (لمك), ә «Нәбиинә салаллаһу галәйһи вәссәламдән соң гарәб исламнарының мәшһүр исемләре» өлешендә исә Мәһди (مهدى), Әлмонтасыйрбилла (المنتصربالله), Әлмөктәфибилла (المكتفىبالله), Таегбилла (طايعبالله) кебек антропонимнар китерелә [Исем 1899: 10-11].

Кушарга яхшы булмаган исемнәргә аерым тукталып, автор: «Мәнсаб вә гонван исемләре берлә тәсмия итмәк йа бер маэсүр булган исемне кечкенә санаб, *мулла* дигән кәлимәгә дәхи бер исем кушуб исемләү кебиләр мәхкәмәи исламия тарфыңдан 99 нчы ел 13 нче мартда

бундай исемләрне бирмәсүнләр дию тәнбия вә нәсихәт иделмешдер. Җөмләмез җәдәл вә тәгассыбларымызы ташлаб инсафа киләлем», – дип яза [Исем 1899: 12]. Мәргуб булмаган (сыйфатсыз, яхшы булмаган) исемнәр, автор карашынча, түбәндәгеләр: Варис (وارث), Мулланур (ملانور), Дәүләтхан (دولتخان), Хәсәньяр (حسنيار) [Исем 1899: 12].

Түбәндәге лексик берәмлекләр мөстәкыйль рәвештә дә, исем компоненты буларак та тәкъдим ителмиләр. «Бу исемләрне куймак муафыйк түгелдер. <…> Бу ләфызларны бер исемгә кушуб һәм кушмый исем бирмәк тиеш дәгелдер»: Иш (ايش), Бай (باى), Әм (ام), Әбү (ابو), Зузый (ذوذى), Шәмшамый (شاهشاهى), Бик (بيك) [Исем 1899: 12]. Моннан тыш, титул атамалары булып йөргән *солтан, хан* кебек лексик берәмлекләр ярдәмендә ясалган антропонимнар да уңышлы дип табылмый [Исем 1899: 15].

«Кыз балаларга куярга күркәм исемләр» бүлекчәсендә бер компонентлы һәм кушма булган йөздән артык антропоним урын алган: (آمنة) Әминә, Рәхилә (راحله), Шәмсия (شمسيه), Заһирә (ظاهره), Назима (ناظمه), Вәлидә (والده) һ.б. [Исем 1899: 13-14]. Кушма исемнәргә килгәндә, аларның гомуми мәгънәсе яхшы, изафәсе дөрес булганын сайлауга басым ясала.

Шул рәвешчә, автор исем кушуда игътибарга алынырга тиешле төп принцип буларак, беренче чиратта, антропонимның семантикасы шәригать кануннарына туры килергә тиешлеген күрсәтә. Исем нигезендә Аллаһы Тәгалә һәм пәйгамбәргә тиңләштерү, кешене бөекләштерү, аны бар нәрсәдән өстен кую мәгънәләре ятарга тиеш түгеллеген, исемнәрнең яңгырашына, структурасына да игътибар итү кирәклеген ассызыклый.

ЛИТЕРАТУРА

Галиуллина Г.Р. Восточные лингвокультурные традиции в антропонимической картине мира татар // Ученые записки Казанского государственного университета. Т. 149. Кн. 4. – Казань, 2007. – С. 64-69.

Галиуллина Г.Р.Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. – 349 с.

Исем. – Казан: Б.Л. Домбровский типографиясе, 1899. – 15 б.

Махмутов М.М.Арабско-татарско-русский словарь заимствований / М.М. Махмутов, Г.Ш. Сайфуллин, К.З. Хамзин. – Казань: Татар. кн изд-во, 1965. – 793 с.

Хаҗиева-Демирбаш Г.С. Татар антропонимик системасының үсеш тенденцияләре. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 220 б.

УДК 372.881.1

Гыйлаҗетдинова Энҗе Илһам кызы,
Казан федераль университеты

Урта сыйныфларда коммуникатив компетенция формалаштыру чарасы буларак аксиологик һәм этик темалар буенча әңгәмә (Р.К. Сәгъдиева дәреслекләре мисалында)

коммуникатив компетенция, татар теле, дәреслек, этик әңгәмә, аксиология

Бүгенге көндә мәктәпнең мөһим бурычларының берсе буларак укучыларның коммуникатив күнекмәләрен, сәләтен, коммуникатив процессны нәтиҗәле кора белүне күздә тоткан коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру, камилләштерү билгеләнә. Шулай итеп, татар теле дәресләренең коммуникатив компетенция формалаштыру куәтен нәтиҗәле файдалану проблемасы да килеп баса. Дәресләрдә туган телдә әңгәмә оештыруның коммуникатив компетенция формалаштыруның үтемле чарасы булуы шик тудырмый.

Дәресләрдә оештырыла торган әңгәмәнең үзенчәлекле ягы буларак галим һәм белгечләр түбәндәгене атыйлар: «диалогик аралашуның башка төрләреннән аермалы буларак, әңгәмә вакытында укытучы әңгәмәдәшләренең (укучыларның) фикерләрен тыңлый, исәпкә ала, алар белән мөнәсәбәтне тигезлек һәм хезмәттәшлек принципларына нигезләнеп кора» [Авдеева 2017: 64]. Рус мәктәпләренең татар төркемнәрендә укучыларга атап төзелгән дәреслекләрдә (авторлары Р.К. Сәгъдиева һ.б.) мондый әңгәмә өчен тема, юнәлеш бирә торган сораулар еш тәкъдим ителә. Кайбер мисалларны карыйк.

Алтынчы сыйныфта «Исемнәрнең ясалышы» темасын өйрәнү дәресләрендә дәреслек авторлары Фәнис Яруллинның «Сорау һәм җавап» шигырен тәкъдим итәләр. Шигырь тирән мәгънәле, биредә әхлакый кыйммәтләр турында сүз бара. Текст укылганнан соң, укучылар, теоретик белемнәрен ныгыту максаты белән, шигырьдәге горурлык, юмартлык, тирәнлек, бердәмлек, кыюлык кебек сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен аерып тикшерәләр. «Өстәмә бирем» рубрикасы аксиологик әңгәмә өчен сорау тәкъдим итә: «Кешегә тагын нинди сыйфатлар кирәк?» [Сәгъдиева 2017: 32]. Әңгәмә вакытында укучылар төрле сый-

фатларны атый алалар, кайбер очракларда бәхәсле мизгелләргә дә урын калдырырга мөмкин. Әйтик, бер укучы тыйнаклыкның кешене бизәгәнлеген әйтсә, икенче укучы бүгенге көндә бу сыйфатның актуальлеген шик астына куя ала, киресенчә, үз «Мин»еңне алгы планга чыгару, үзеңне, тормышыңны башкалар алдында күрсәтү тенденциясе социаль челтәрләрдә киң таралыш алу хакында әйтергә мөмкин. Укытучының бурычы – һәр укучыга үз фикерен үтемле, кызыклы, төгәл, дөрес итеп җиткерү мөмкинлекләрен бирү. Этик нәтиҗә исә укучылар тарафыннан әңгәмә ахырында ясала.

«Өстәмә бирем» рубрикасында тәкъдим ителгән сораулар этик яки аксиологик юнәлешле әңгәмәдә тәнкыйди фикерләүне актуальләштерүне дә күздә тоталар. Җиденче сыйныф укучыларына тәкъдим ителгән шундый сорауны карыйк:«Китаплар ни өчен кирәк? Хәзерге көндә Интернет китапны алмаштыра аламы? Һәркайсының уңай һәм тискәре якларын әйтегез» [Сәгъдиева 2017: 11].

Аңлашылганча, биредә укучылар китапның да, Интернетның да уңай һәм тискәре якларына тукталырга тиеш булалар. Биремне башкарганчыга кадәр, укучыларга Б. Рәхмәтнең «Китап» шигырен укырга туры килә. Биредә китап белем бирә торган ресурс буларак тасвирлана. Әлбәттә, укучылар китап ярдәмендә белемгә ихтыяҗны канәгатьләндерү мөмкинлеген дә әйтәләр. Мондый очракта Интернет чыганакларының мөмкинлекләренә дә тукталырга тиеш булалар. Алга таба китапның һәм Интернетның күңел ачу чарасы буларак вазифалары, тәрбияви-этик вазифалары һ.б. да ачыклана, һәр очракта укучы тәнкыйть күзлеге аша карап җавап бирә. Укытучы укучыларның сөйләме дөрес корылуга да игътибар итә, әңгәмә барышында каршылыклык, конфликтка нигез була алган шартларда укучыларның үз-үзләрен тотышларына игътибар итә һәм, кирәк очракта, коррекция кертә. Мондый эш коммуникатив компетенция формалашуга, һичшиксез, уңай йогынты ясый.

Җиденче сыйныфта укучыларга «Әдәпле булу ни өчен кирәк?» дигән текст тәкъдим ителә [Сәгъдиева 2017: 85-86]. Биредә әдәплелек төшенчәсенең эчтәлеге шактый киң ачыла: аралаша белү, башкаларга игътибарлы булу, ныклы режим белән яшәү һәм якыннарны кайгыртып яшәү сыйфаты буларак тасвирлама бирелә. Әмма текст башында куелган сорауга төгәл җавап юк, моны укучылар үзләре эшләргә тиеш. Әлбәттә, биредә укучылар каршылыклы фикерләргә килә алалар, һәм бу табигый да. Әйтик, кайбер укучы, әдәплелек – кешенең тышкы ягын

гына күрсәтә торган сыйфат, әдәпле кешеләр арасында да асылда тотнаксыз, шәфкатьсез булучылар барлыгын ассызыклый ала. Безнең фикеребезчә, аралашу, әңгәмә дәвамында якынча мондый нәтиҗә ясала ала: чынлап та, тышкы әдәплелек, этика кануннарын белү кешенең эчке ягын төгәл күрсәтә алмый. Әмма кешелек цивилизациясе барлыкка килү белән үк, әдәплелек кануннары да эшләнә. Әдәплелек кануннары ярдәмендә кеше башка кешене якыннан аралашу даирәсенә кертүкертмәү хакында нәтиҗә ясый. Кеше әдәпле, тыйнак, башкалар сүзенә игътибарлылык күрсәтә икән, аның белән куркынычсыз, аның белән эшлекле, шәхси мөнәсәбәләр корып була, дип уйлый кеше. Әдәплелек кануннарын үтәми икән, кеше турында тотнаксызлык, артык эмоциональлек, үз-үзен тотышының эмоциональ халәтенә артык бәйле, дигән нәтиҗә ясала. Мондый кеше белән якын мөнәсәбәтләр кору куркыныч була ала. Шулай итеп, якыннан аралашу өчен кешеләрне сайлауның беренче этабы үтелә. Һәм бары шуннан соң кеше әңгәмәдәшенең тышкы әдәплелек саклавының битлек булу-булмавын тикшерә, шәхес буларак асыл сыйфатларын аңларга тырыша. Шулай итеп, әңгәмә дәвамында әдәплелекнең әһәмияте әдәпле, зыялы аралашу даирәсен киңәйтү мөмкинлеге, әдәпле һәм зыялы аралашу дәвамында үзүсешкә ирешү мөмкинлеген бирү кебек нәтиҗәләр ясала.

Дәреслектәге темаларга бәйле мондый әңгәмәләр аралашуның төрле формаларына мөрәҗәгатьне күздә тоталар. Укучы үз фикерен монолог рәвешендә җиткерә ала, бу бигрәк тә сочинение язу кебек эш алдында еш очрый. Бу очракта бала аралашуда катнашучыларның (аудиториянең) тыңлавын оештырырга өйрәнә, үз сөйләмен сөйләм культурасы нормаларына ярашлы рәвештә төзергә тырыша, интонация, образлы сөйләм мөмкинлекләреннән дә файдалана. Диалог төзү процессында коммуникантлар үзара тәэсир итешәләр, үзара активлык күрсәтәләр. Балалар бер-берсен тыңларга, башкаларның фикерен аңларга, аны расларга, инкяр итәргә, аңлашылып җитмәгән очракта, сораулар бирергә өйрәнәләр. Мондый әңгәмәләрнең диалог яки полилог рәвешендә оештырылуының файдасы исә аралашу темасына ярашлы гына кабул ителә алмый. Мондый әңгәмәләр аралашуда да, ягъни коммуникацияне тормышка ашыруда да аксиологик якын килү, икенче төрле итеп әйткәндә, әңгәмәне ике яклы ихтирам, хөрмәт, чын кызыксынуга нигезләп оештыру үрнәген күрсәтәләр.

Шулай итеп, урта сыйныфларда укучыларның коммуникатив компетенция үсешен тәэмин итү чарасы буларак этик һәм аксиологик әңгәмәләрнең әһәмиятен атарга кирәк. Алар әхлак-әдәп сыйфатларын тәрбиялиләр, коммуникацияне нәтиҗәле оештыру, алып бару күнекмәләрен үстерәләр.

ӘДӘБИЯТ

Авдеева М.А. Методы формирования готовности школьников к аксиологическому общению // Поволжский педагогический вестник. – 2017. – Т. 5. –№1(14). – С. 63-68.

Сәгъдиева Р.К. Татар теле. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 6 нчы с-ф. / Р.К. Сәгъдиева, Р.М. Гарәпшина, Г.И. Хәйруллина. – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2017. – 191 б.

Сәгъдиева Р.К. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 8 нче с-ф. / Р.К. Сәгъдиева, Г.Ф. Харисова, Л.К. Сабирҗанова, М.Ә. Нуриева. – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2017. – 215 б.

УДК 81-23

Денмөхәммәтова Эльвира Николай кызы,
Казан федераль университеты

Ф. Сафиуллинаның мәгънәдәш сүзләрне өйрәнү юнәлешендә эшчәнлеге

Ф.С. Сафиуллина, синоним, татар теле, лексикология, лингвометодика, синонимнар сүзлеге

Ф.С. Сафиуллина тел белеменең төрле өлкәләрендә эшләүче галимә буларак билгеле. Ул – татар теле синтаксисы, лексикологиясе һәм лексикографиясе, фразеологиясе, татар теленә өйрәтү методикасы юнәлешендә берничә дистәдән артык хезмәт язган шәхес. Кайсы гына юнәлештә эшләмәсен, Флера Садрый кызы нәзари мәгълүматларның гамәли әһәмиятен аңлатырга һәм сөйләмдә куллану юлларын күрсәтергә тырыша. Бу аның татар тел белемен өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә синонимнарның урынын билгеләүдә, теоретик һәм практик әһәмиятләрен күрсәтергә тырышуында да күренә. Галимә тел беле-

мендәге мәгънәдәшлекне лексик берәмлекләр арасындагы синонимлык буларак та, грамматик, стилистик синонимлык рәвешендә дә өйрәнә, сүз ясалышында булган синонимлык күренешләренә мисал-дәлилләр күрсәтеп, бу өлкәдә дә мәгънәдәшлек барлыгын тикшереп раслый. Болар барысы да аның фәнни хезмәтләрендә, мәктәп укучылары һәм югары уку йорты студентлары өчен язган дәреслекләрендә чагылыш таба.

Ф.С. Сафиуллина хезмәтләрендә «синонимнар – якын мәгънәле, ягъни мәгънәдәш сүзләр»буларак биреләләр. Алар чынбарлыкның «*бер үк күренешен атыйлар, ләкин аны төрле яктан, төрле күзлектән тасвирлыйлар*», дип аңлатылалар [Сафиуллина 2002: 38]. Шул рәвешле галимә лексик синонимиягә билгеләмә бирә һәм мәгънәдәшлеккә хас күренешләрне традицион характерда тикшерә: синонимик рәт турында аңлата, доминанта сүз турында мәгълүмат бирә, синонимик ояга хас үзенчәлекләрне күрсәтә, стилистик синонимлык, сүзъясалышында мәгънәдәшлек күренешен тасвирлый. Татар телендә синонимнар барлыкка килүнең 7 юлын билгеләп үтә, соңыннан бу мәгълүматлар «Татар лексикологиясе» хезмәтендә дә тәкъдим ителәләр [Татар лексикологиясе 2015: 163].

Флера Сафиуллинаның тел белеменең синонимия өлкәсендә башкарган хезмәтләренең иң зурысы – Шифа Ханбикова белән берлектә төзелгән «Синонимнар сүзлеге». Сүзлекнең беренче басмасы 1999 елда «Хәтер» нәшриятында дөнья күрә [Ханбикова 1999]. Шифа Ханбикованың моңа кадәр дә мәгънәдәш сүзләрне өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләре, ике сүзлеге барлыгы мәгълүм. Әмма телне барлык нечкәлекләре белән камил белгән ике галимә тарафыннан төзелгәнгәме, бу сүзлек, теоретик һәм гамәли материалның аеруча уңышлы үрнәге булып тора. Шифа Ханбикованың элеккеге сүзлекләрендә чорына күрә татар телендә активлашкан рус-европа алынмаларының татар сүзләре белән мәгънәдәшлегенә күбрәк игътибар бирелә, ә кайбер очракта хәтта татар сүзләренә караганда алынма берәмлекләрнең кулланылыш дәрәҗәсе күбрәк булулары, ешрак кулланылуларына басым ясалса, яңа сүзлеккә үткән гасырның 90 нчы елларында телгә кире кайтарылган «онытылган берәмлекләр» дә теркәлүе күренә. 25 меңгә якын синонимик берәмлек берләштерелгән сүзлектә 4500 дән артык синонимик оя тәкъдим ителә. «Синонимнар сүзлеге» басылып чыгуга ук, киң җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә, аның хакында вакытлы матбугат битләрендә мәкалә-рецензияләр басыла. Хәзерге вакытта

гамәлдә йөри торган икенче басма 2014 елда Татарстан китап нәшриятында басыла һәм бүгенге көнгә фән һәм мәгариф өлкәсендә эшләүчеләргә ярдәмче вазыйфасын үти. «Синонимнар сүзлеге»нә ихтыяҗ зур. Гыйльми хезмәтләрдә, фәнни тикшеренү эшләре вакытында аңа сылтамалар еш бирелә. Бу исә сүзлекнең кирәклеген һәм файдалы булуын кабат раслый. Андагы берәмлекләрнең рус теленә тәрҗемәләре дә бирелү файдаланучыга уңайлык тудыра. Галимнәр әйтүенчә, татар телендә синонимик оялар 15 меңнән дә артып китә. Бу сүзлеккә аларның барысы да теркәлмәсә дә, зур күпчелеге һәм иң активлары җыйнап бирелгән. «Синонимнар сүзлеге»нә тупланган мисалларның да үткән гасырның 90 нчы елларында көндәлек сөйләмебездә сирәк кулланып, язма әдәбиятта гына очрый торганнары шактый теркәлә, термин буларак кулланылышка кереп киткәннәре дә тәкъдим ителә.

Галимәнең төрле юнәлешләргә караган дистәдән артык лексикографик хезмәтләре барлыгы мәгълүм. Ул бу басмаларда да төшенчәләрнең, терминнарның телдә кулланылышта йөргән синоним берәмлекләрен күрсәтеп барырга тырыша. Мәсәлән, Флера Сафиуллинаның 2003 нче елда басылып чыккан «Татарча-русча, русча-татарча антонимнар сүзлеге»ндә «*Акыллы*» *тиле (ахмак, тинтәк) – умный – дурак*»; «*Бай – ярлы (фәкыйрь) – богатый (богач, состоятельный) – бедный (убогий, нищий)*» һ.б. рәвешендә ике телдә тәкъдим ителгән капма-каршы мәгънәле сүзләр һәм аларның мәгънәдәш вариантлары теркәлгән. 2001 нче елда дөнья күргән «Татарча-русча фразеологик сүзлек»тә дә тотрыклы сүзтезмәләрнең мәгънәдәш вариантларын, рус телендәге эквивалентлары белән бергә күрергә мөмкин. Мәсәлән, «*Җай чыгу/ уңай килү/ мач килү – ловить момент/ улучшить момент/ при удобном случае/ выдаться удобному случаю/ если будет возможность*», *зәмһәрир суыклар/ көчле суык/ чатнама суык/ зәһәр суык/ зыкы салкыннар/ раштуа суыклары/ үзәккә үтә торган суык/ чытырдап торган суык/ шыкырдап торган суык – рождественские морозы/ крещенские морозы/ трескучие морозы/ собачий холод*»; «*кот очты/ котым ботыма җитте – душа ушла в пятки/ подилки трясутся/ мороз по коже дерет/ мурашки по спине бегают/ волосы становятся дыбом/ кровь стынет в жилах / сердце падает/ небо с овчинку показалось*» һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, тәкъдим ителгән үрнәкләр татар телендә кулланышта булган тотрыклы сүзтезмәләр мәгънәдәшлеген ачыкларга да, рус фразеологизмнары арасындагы синонимлыкны билгеләргә дә ярдәм

итә. Бүгенге ике- яки күптелле дөньяда тәрҗемә эшләре белән шөгыльләнгәндә дә, мондый төр үрнәкләрнең ярдәме зур.

Флера Сафиуллина лексикология буенча язылган хезмәтләрендә генә түгел, татар теленең грамматик төзелешен чагылдырганнарында да морфологик һәм синтаксик синонимнарга игътибар итә. Үзе морфология белгече булмаса да, «Хәзерге татар әдәби теле. Күнегүләр җыентыгы» хезмәтендә һәм студентлар өчен тәкъдим ителгән «Тел гыйлеменә кереш. Күнегүләр җыентыгы» хезмәтләрендә бу төргә караган күнегүләре бар. Мәсәлән, «*Фигыльнең төрле мәгънә төсмерләренә синонимнар языгыз. Үрнәк: барырга тели – барасы килә*»; «*Затны һәм предметны тасвирлый торган сыйфатларның синонимнарын табыгыз*»; «*Тәкъдим ителгән берәмлекләрне синонимнары белән алыштырып әйтегез*», «*Алмашлыклар һәм алар алыштырып килгән сүзләр арасындагы мәгънәдәшлекне билгеләгез, мәгънәләрен аңлатыгыз*», «*Төрле теллләрдән кергән берәмлекләрнең мәгънә төсмерләрен ачыклагыз, кулланылыш үзенчәлекләрен аңлатыгыз*» һ.б. [Сафиуллина 2002].

Галимә синтаксис өлкәсендә белгеч буларак, татар сөйләме төзелеше, җөмлә төрләре, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен ачыклау, кушма җөмлә синтаксисын үз хезмәтләрендә җентекләп аңлата. Укучылар, студентлар өчен тәкъдим иткән дәреслекләрендә синтаксик синонимиягә караган күнегүләрне дә еш тәкъдим итә, чөнки телнең гамәли кулланылышы аның өчен иң мөһим мәсьәләләрдән санала. Ф. Сафиуллина хезмәтләрендә иярчен җөмләләрнең аналитик һәм синтетик төрләре арасында синонимлык, җөмлә һәм җөмлә кисәкләренең бәйләүче чаралары арасында синонимлыкны ачыклауга караган күнегүләрне еш очратырга мөмкин. Мәсәлән, «*Мәгънәне саклаган хәлдә, җөмләләрне башкача әйтегез*», «*Аналитик иярчен җөмләләрне синтетик төрләре белән алыштырыгыз*», «*Мәгънәдәш иярчен җөмләләре булган күп иярченле катлаулы кушма җөмләләргә мисаллар китерегез*», «*Диалогны үзгәртеп укыгыз. Җөмләләр арасындагы мәгънәдәшлекне билгеләгез*» һ.б.

Алынган теоретик белемнәрне гамәли куллана белүгә Ф. Сафиуллина аеруча зур игътибар бирә. Күп еллар дәвамында Казан университетының «Чит аудиториядә татар теленә өйрәтү» кафедрасы мөдире булып эшләү дәверендә, ул студентларга, чит ил вәкилләренә күп дәресләр бирә, дистәдән артык дәреслекләр, методик әсбаплар яза. Бу хезмәтләргә күз салган очракта да, аларда телнең кулланылыш

даирәсенә бәйле рәвештә, бер үк фикерне төрле лексик-грамматик юллар белән әйтү мөмкинлекләре күрсәтелә, тавтологиядән качу өчен, әдәби тел мөмкинлекләрен аңлап куллануга басым ясала. Галимә телгә өйрәтү вакытында ук, аз-азлап синоним берәмлекләр белән таныштырып баруны, аларның стилистик үзенчәлекләрен аңлатуны кирәк саный.

Гомумиләштереп, шуны әйтергә мөмкин: тел белеменең кайсы гына тармагын өйрәнмәсен, Флера Сафиуллина һәрвакыт теоретик мәгълүматларның гамәли яңгырашын бирүгә зур игътибар итә. Телне камил белү, өйрәнү өчен, аның барлык мөмкинлекләрен дә аңларга, куллана белергә кирәклегенә басым ясый, үзе дә һәрвакыт шуны өйрәтергә тырыша. Бу исә телдәге мәгънәдәшлекне аңлау аша да башкарыла. Остазыбыз – үз туган телен ихлас яраткан, аңа тугры хезмәт иткән олпат шәхес.

Мәкалә «Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр» фәнни белем бирү үзәге кысаларында язылды.

ӘДӘБИЯТ

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле / Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2002.– 320 б.

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Күнегүләр җыентыгы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 276 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т. I. – 352 б.

Ханбикова Ш.Х., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге / Ш.Х. Ханбикова, Ф.С. Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 2014. –263 б.

УДК 81.511’373.6

Душенкова Татьяна Рудольфовна,
Удмуртский федеральный исследовательский
центр УрО РАН

Фитоним *чертополох* в удмуртской этнокультуре

фитоним, удмуртский язык, лингвокультурология

Чертополох является символом Шотландии. Он считался священным растением шотландских кланов и стал официальной эмблемой страны, и даже чеканился на монетах XV в. В начале XVIII в. Он появил-

ся на британском гербе вместе с девизом: «Никто не тронет меня, не поранившись».

Чертополох – широко распространенное растение. В природе растет более 120 видов чертополоха, и все имеют похожие черты. В народе его также именуют *репейником, бодяком, татарником*; лекарственный вид известен как *расторопша*. Отличительная черта чертополоха – колючки на листьях и плодах. Некоторые исследователи считают, что колючие растения связаны с демонической силой. Шипы обозначают границу миров и, таким образом, становятся апотропейными, служат средством перехода и прохождения через «границу» в обоих направлениях [Зайковская 1997: 53]. Например, колючки послужили основой номинации в русских диалектах (*колюха, колюшки*) и др. славянских языках. Фитоним *чертополох* отражают представления о том, что растение может отогнать нечистую силу: по этой же модели образованы *чертогон, чертопугальники* др. Охранительная традиция этого растения уходит далеко в глубь: со времен античности считалось, что он может разрушать злые знаки и изгонять демонические силы. В римской мифологии Церера, богиня жатвы, покровительница плодородия, зажигала факел из сухого чертополоха.

В удмуртском языке название чертополоха – *кыйбоды* букв. ʽзмея-палка, змеиная палка’, но никакого внешнего сходства оно с пресмыкающимся не имеет. По-видимому, когнитивная стратегия номинации данного растения связана с прагматическим фактором и использована непрямая номинация растения. Колючесть растения может наносить боль при контакте с ним, и, по-видимому, ассоциируется со змеёй, т.е. с ее укусом семантически. В других финно-угорских языках картина очень схожа. Колючесть растения в вепском языке обозначена как *ogahhiin* ʽчертополох’, где *ogah* ʽшип’ и *hiin* ʽтрава’. Растение относится к оберегам. В Иванов день (день летнего солнцестояния, праздник Ивана Купалы. Отмечается с 6 июля (23 июня по ст. стилю) на 7 июля (24 июня по ст. стилю)) приносили чертополох и втыкали его за косяки дверей, чтобы никакая зараза не пришла. Есть и другие названия, где компонентом является слово *raud* ʽжелезо’: *raudikhiin* ʽжелезо+трава’, *raudikod* (букв. ʽжелезняки’) *raudicim* (Пондала) [Зайцева 1972: 465]. В финском языке также есть фитонимы с компонентом *raut a*ʽжелезо’, которое указывает на разные признаки растения: *rautapoltikkaine* ʽкрапива жгучая’ (букв. ʽжелезная крапива’ – указывает на жгучесть); *rautakalastikas* ʽвейник

наземный’ букв. ‛железный вейник’ (твердость стебля), *rautaleht* ‛подорожник’ – букв. ‛лист раны от железа’. Железо в народной традиции является универсальным апотропеем. Можно предположить, что функциональное сходство между чертополохом и железом по признаку *оберег* обусловило появление таких названий [Винокурова 2015: 285].

В диалектах удмуртского языка встречается еще две лексемы *леконь, шайтанбоды* [Соколов 1994: 138]. *Леконь* ‛злой, сердитый’. Второе слово – *шайтанбоды* букв. ‛палка шайтана’ – соотносимо с башкирским названием фитонима *шайтантаяҡ* ‛чертополох’ (букв. ‛палка шайтана’ [Хисамитдинова 2010: 359]), возможно даже калька с башкирского. В русском языке название растения *чертополох* представляет собой сложное слово, первая часть которого *чёрт*, вторая – от глагола *полоха́ть* ‘пугать, переполохаться, испугаться’.

Тем не менее, в удмуртском литературном языке закрепилось название чертополоха, связанное с образом змеи – *кыйбоды* букв. ‛змея-палка, змеиная палка’. С компонентом *кый* ‛змея’ в удмуртском языке образовано еще несколько фитонимов. Некоторые из них связаны с местом обитания пресмыкающегося: диалектное *кыйгуби* букв. ‛змеиный гриб’, *кыйӝуй* букв. ‛змеиный мох’, *кыйкуар* ‛мать-и-мачеха’ – букв. ‛змеиный лист’. Другая группа предполагает некое внешнее сходство с головой змеи – *кыййыр* ‛1. синяк 2. змееголовник’; глазом змеи – *кыйсин*‛1. анютины глазки 2. иван-да-марья’; *кыйсинсяська* (букв. ‛цветок змеиный глаз’) или *кыйсинтурын* (букв. ‛трава змеиный глаз’) – два последних обозначают растение *медвежье ухо*; а также с языком змеи – *кыйкыл* ‛гусиный лук’ (букв. ‛змеиный язык’). Одно из диалектных названий колодца *кыйву* букв ‛змеиная вода’ или *кыйгу* букв. ‛змеиная яма’. Название фурункула – *кыйсин* букв. ‛змеиный глаз’ [УРС 2008: 369].

Образ чертополоха нашёл своё отражение в сравнениях: *Кыйбоды!* ‛Чертополох!’ – говорят о коварном/подлом человеке [УФ 1987: 235]. Пословицы и поговорки с данным компонентом также отражают характер человека: *Кыйбодыез гольык киын кутыны* букв. ‛Брать чертополох голыми руками’, т.е. подлые, низкие люди тоже вверх лезут [Дзюина 1996: 61; УФ 1987: 155]; *Кыйбодыез гольык киын уд куты* ‛Чертополох голыми руками не возмёшь’ – раскрыть намерения подлого человека; *Кыйбоды но улыг интыез уг яраты* букв. ‛И чертополох не любит низину’ – и подлые, низкие люди тоже вверх лезут; *Кыйбоды кизьытэк но потэ* ‛Чертополох и без сева всходит / растёт’.

Актуализируется колючесть растения: *Кыйбоды но легезьпу – эшъёс* 'Чертополох и шиповник – друзья' [УФ 1987: 76]; *Кыйбодылэн венез бышкан понна* 'Иголки чертополоха – чтобы колоться' [УФ 1987: 155]. Особая форма ругательства-проклятия, где на первый план выходят апотропейные, обережные функции растения: *Синмад-пеляд – сьӧд коӵыш, тыбыр кузяд – кыйбоды!* 'В глаза-уши – черную кошку, вдоль спины – чертополох!' [УФ 1987: 252].

Образ чертополоха встречается и фольклорных песнях: *Сюсь мынё кадь ямщике, /Кыйбоды кадь баринэ* 'Мой ямщик, как восковая кукла, /Мой барин, как чертополох' [Гиппиус 1989: 67]. В удмуртской поэзии он актуализирован у П. Захарова, В. Ар-Серги, но самый яркий запечатлен в творчестве Аллы Кузнецовой. О ее героине много писала удмуртская критика. Она отождествляет себя с цветком чертополоха, подчеркивает свою неприкасаемость и статус изгоя:

Кыйбодылэсь шайтан но палэнске. *Пудо сое уг си.* *Уг мыны со сяська керттэтъёслы.* *Нош кыйбоды такем шусэ* *Тодылытэк вордске.* *Пайме:* *– Малы-о кулэтэм со нокинлы?* *Ӵыж-льӧль сяськаосыз гинэ* *Солэн мӧзмо.* *Шат кыйбоды кадь мон но* *Потӥськем тыныд?* *Малы уд дӥсьтӥськы* *Вӧзам матэктыны?*	От чертополоха даже шайтан сторонится. Скот(ина) его не ест. Не подходит он для букетов/венков. Но чертополох рождается, Не ведая/зная своей некрасивости. Удивляется: – Почему он никому не нужен? Лишь ярко-розовые цветы Его тоскуют. Разве и я, как чертополох, Тебе показалась? Почему не решаешься Подойти поближе?

Чертополох становится символом запустения в стихотворении П. Захарова. Здесь он сопоставим с образом крапивы. Их объединяют колючки и шипы, а также то, что оба растения любят заброшенные места и т.п.

Нош коркаос, кӧня вал коркаос – *Кыйбодыез татын ӧй вал на чик* [Захаров 1991: 65]	А домов, сколько было домов – Чертополоха тогда не было и в помине.

Удмурты приписывали оберегающие, магические свойства рябине (*палэзьпу*), можжевельнику (*сусыпу*), татарнику (*кыйбоды*), чесноку, луку

(*сугон*), чертополоху (*йӧны*), полыни (*вожпот*), шиповнику (*легезьпу*), щавелю конскому (*чуньыбыж*) [Верещагин 1995: 76]. Эти растения подкладывали в колыбель ребенка; беременные женщины и дети носили с собой; рябиновыми, можжевеловыми, шиповниковыми ветками ограждали жилые помещения от нечистой силы; чеснок, лук брали с собой в дальнюю дорогу и т.д. [Верещагин 1998: 56]. Растительный амулет, согласно народным верованиям, – надежная защита от нечистой силы, от колдунов и ведьм, всякой напасти и вражды [Никитина 2003: 94].

В удмуртском языке фитоним *чертополох – кыйбоды* 'змеиная палка, палка-змея', *шайтанбоды* 'палка Шайтана'*, леконь* 'сердитый, злой' – имеет три названия. Все они семантически связаны с негативной коннотацией, которые затем переходят на представления о свойствах растения. Образ чертополоха нашел отражение в удмуртском языке, фольклоре и литературе. В пословицах и поговорках с ним связаны негативные качества человека. Растение использовалось как оберег, отпугивающий нечистую силу.

ЛИТЕРАТУРА

Верещагин Г.Е. Собр. Соч.: В 6 т. Т. 1: Вотяки Сосновского / Отв. за выпуск Никитина Г.А. – Ижевск, 1995 (Памятники культуры)

Верещагин Г.Е. Собр. Соч.: В 6 т. Т. 3. Кн. 1: Этнографические очерки / Отв. за выпуск Г.К. Шкляев. – Ижевск, 1998 (Памятники культуры)

Винокурова И.Ю. Мифология вепсов: энциклопедия. – Петрозаводск: Изд-во ПетрГУ, 2015. – 524 с.

Гиппиус Е. Удмуртские народные песни: Тексты и исследования / Е. Гиппиус, З. Эвальд. – Ижевск,1989. – 79 с.

Дзюина К.И. Средства образного выражения в удмуртском языке. – Ижевск: Удмуртия, 1996. – 144 с.

Зайковский В., Зайковская Т., Роль колючих и жгучих растений в духовной культуре юго-восточной Сербии на балкано-славянском фоне // Етно-културолошки зборник за проучавање културе источне Србије и суседних области / Главни и одговорни уредник Сретен Петровић. Уредник Недељко Богдановић. – Књига III. – Сврљиг: Етно-културолошка Радионица, 1997. –С. 53–58. (на сербском)

Зайцева М.И. Словарь вепсского языка / М.И. Зайцева, М.И. Муллонен. – М., 1972.

Кузнецова А. Кыйбоды // Удмурт литературая антология: 8-11-тӥ классъёсын дышетскисьёслы лыдӟет/ Текстъёсты бырйиз но дасяз В.Л. Шибанов. – Ижкар: РАН-лэн Уральской люкетаз пырись Удмурт история, кылъя но литературая институтэз, 2001. – 197 б.

Никитина Г.А. Мифологические представления в народной медицине удмуртов // Удмуртская мифология / Под ред. В.Е. Владыкина. – Ижевск, 2003. – С. 84-96.

Соколов С.В., Туганаев В.В. Словарь биологических терминов. – Ижевск: Удмуртия, 1994. – 144 с.
Удмурт фольклор. Пословицы, афоризмы и поговорки / сост. Перевозчикова Т.Г. – Ижевск: Удмуртия, 1987. – 76 с.
УРС – Удмуртско-русский словарь / РАН. УрО. Удм. ин-т ИЯЛ. – Ижевск, 2008. – 925 с.

УДК 82.01/.09

Зәйдуллин Баязит Ркаилович,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Туфан Миңнулин әсәрләрендә туган җир мотивы

Т. Миңнуллин, татар драматургиясе, туган җир, мотив, татар авылы

Туфан Миңнуллин – XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башы татар драматургиясенең сәнгать эзләнүләрен үстерү юнәлешен билгеләүчеләренең берсе [Әхмәдуллин 2018: 3]. Аның иҗаты, һичшиксез, татар драматургиясе тарихында аерым бер чор булып тора.

А.Р. Салихова фикеренчә, драматургның хезмәтләрендә тирән милли нигез, традицион крестьян фәлсәфәсе чагыла. Бу фәлсәфәдә, бер яктан, ике төпле акыл һәм рациональлек, икенче яктан, поэтик, сентименталь рәвештә югары кыйммәтләргә омтылу, көндәлек чынбарлыкны ямьләндереп җибәрү теләге гаҗәеп рәвештә бергә үрелә [Салихова 2016: 210].

«Туфан Миңнуллин татар сәхнә әдәбиятын үзенчәлекле тематика, оригиналь мотивлар, кабатланмас образлар, яңа сәнгать алымнары белән баета. Драматургның бөтен иҗаты милләтнең моң-зарлары һәм өметләре белән сугарылган», – дип яза А.Г. Әхмәдуллин [Әхмәдуллин 2012: 442].

Туфан Миңнуллин иҗатының төп һәм игътибарга лаек мотивларының берсе – туган җир мотивы.

Авторның иҗатында бу «кече» һәм «олы» Ватанны каршы куюда да (мәсәлән, «Без бит авыл малае» пьесасында), шулай ук әсәрләрдә күзәтелә торган, татар халкының аутентик, авыл тормышын югалту темасын яктыртуда да чагыла. Драматургның милли гореф-гадәтләрне

һәм традицияләрне югалту сәбәпле сызлануы исә «Мулла», «Нигез ташлары», «Монда тудык, монда үстек» кебек әсәрләрдә дә урын таба.

Туфан Миңнуллин пьесаларының исемнәре дә укучыда геройларның туган җире турында күзаллау тудыру өчен кулланыла: «Без бит авыл малае», «Кырларым-тугайларым», «Нигез ташлары», «Монда тудык, монда үстек», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Безнең авыл кешеләре». Әлеге исемнәрне күрү белән үк, укучы аңында төп герой һәм аның туган-үскән җире белән бәйләнеш барлыкка килә.

Мәсәлән, «Без бит авыл малае» дигән пьесаның исеме әсәрнең төп идеясен чагылдыра. Иртуган исемле герой тарафыннан күп тапкыр кабатланган бу гыйбарәдә үз чыгышың, үз нәселең һәм, гомумән, халкың өчен горурлану хисе сизелә. Бу Туфан Миңнуллинның үзенә дә хас. Әдип тә, әсәренең төп герое кебек үк, үзен чын авыл кешесе дип саный: намуслы, тырыш, туры һәм сүзендә торучы шәхес. Авторның үз тамырларына һәм үз халкына чиксез тугрылыгы тирә-юньдәгеләрне шаккатырган. «Мин бөтен галәм хозурлана алырлык чәчәк түгелмен, ә бары тик авылым капкасы төбендә үсеп утыручы бер үләнмен...», – дип язган үзе турында драматург [Габәши-Сәлихова 2010: 4].

Авторның иҗатын анализлаганда, автор өчен «туган җир» ул һәркемгә таныш һәм якын авыл икәне аңлашыла. Туфан ага да – үз әсәрләренең күп кенә геройлары кебек үк, милли рухта тәрбияләнгән авыл кешесе. Туган җирнең кыйммәтлегенә багышланган әсәрләр язучының библиографиясендә тулы бер цикл тәшкил итә.

Туфан Миңнуллин үзен һәрвакыт авыл кешесе итеп хис итсә дә, ул татар авылы һәм күп гасырлык яшәү рәвеше алдында торган каршылыкларны аңлаган һәм кабул иткән, милләттәшләре җиңеп чыгарга тиешле проблемаларны да күз алдыннан үткәргән. Урлашу һәм эчкечелек гадәти күренешләргә әйләнеп бара, ә кешеләр битараф һәм ваемсызга әверелә – туган җирендәге мондый үзгәрешләрнең кайтавазы авторның йөрәгендә ачы сызлану хисләре булып яңгырый [Закирҗанов 2018: 10-11].

Туган җир милли мәдәниятнең төп төшенчәләре санына керә, дини, этик, эмоциональ, әхлакый өлкәләрдә мөһим урын алып тора. «Җир» сүзе тел иясенең дөньяга карашын һәм тормыш тәҗрибәсен чагылдырган гыйбарәләр составына керә.

Татар халкының тарихына күз салсак, аның бихисап сынаулар аша үткәнен күрәбез. Күп кенә әдипләрнең, шул исәптән Туфан Миннуллинның иҗатында да, үз илең, туган җирең өчен кайгыру урын алган.

XIX гасыр тарихчысы В.О. Ключевский фикеренчә, бөек халыкларның аермалы сыйфатларының берсе – егылуга карамастан, кире аякка баса алу сәләте. Туфан Миңнуллинның әсәрләрендә исә татар халкының нәкъ шундый булуы раслана.

Димәк, бөек халыкның бу билгеләмәсе татар халкы өчен дә хаклы. Халыкның, шул исәптән Т. Миңнуллин кебек шәхесләрнең, үз Ватанына карата чиксез мәхәббәте һәм чыдамлыгы аркасында милләтебез үзенчәлеген һәм мәдәниятен югалтуга каршы тора алды.

«Ул татар милләтенең нигезләре, яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, йолалары сагында тора, үз сәләтенең көче белән милли менталитетның асылында тырышлык, өлкәннәрне хөрмәт итү, буыннар арасында рухи бәйләнешне саклау һәм элемтәләрне ныгыту, гасырлар буенча формалашып килгән әхлакый кануннарга тугрылык, туган җиргә мәхәббәт кебек сыйфатлар ята дигән фикерне яклый», – дип яза Туфан Миңнуллин шәхесе турында Ә. Закирҗанов [Закирҗанов 2019: 195].

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: XX гасыр – XXI гасыр башы дөнья мәдәниятендә дә «мәхәббәт» һәм «ватан» төшенчәләрен үз эченә алган «йорт» архетибы әхлакый-фәлсәфи аспекты булган төп кыйммәтләрнең берсе булып тора [Шәрипов 2021: 139]. Бу күренеш традицион кыйммәтләргә йөз тоту, күп гасырлык гореф-гадәтләрне саклау темаларында урын ала.

Әлеге юнәлеш, аеруча, Туфан Миңнуллин иҗаты өчен актуаль, чөнки татарның яшәү урыны, аның төп нигезе – авыл. Авылның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында уйланулар, ата-бабалар алдындагы бурычларны үтәү, аларның мирасын саклау һәм яшь буынга тапшыру, авылның кеше рухына уңай тәэсире – болар барысы да авторның әсәрләрендә чагылыш тапкан.

Мәсәлән, «Мулла» драмасында без әсәрнең төп антагонисты – Вәлиәхмәтне күрәбез. Ул – репрессияләнгән мулланың оныгы. Герой ата-бабалары яшәгән җиргә кайтып, авылдашларын начарлыкка өнди, эчкечелеккә этәрә, мыскыл итә башлый. Шулай итеп, ул авыл халкыннан сөргенгә җибәрелгән бабасы өчен үч ала. Ләкин хәлиткеч мизгелләрдә Вәлиәхмәт дөрес һәм намуслы гамәл кыла. Ул яшь мулла Әсфәндиярны бу авылдан качудан туктата, калырга өнди. Шулай итеп, тискәре герой үзенең туган авылына рухи яктан яңарыш кичерергә һәм бабасы алдында гаебен йоларга мөмкинлек бирә. Үз чиратында, бәлки, авыл да

Вәлиәхмәткә рухи яктан чистарынырга һәм, ниһаять, үз «җанын» табарга көч бирер.

Авылның, туган җирнең кешенең физик һәм психологик сәламәтлегенә уңай тәэсире идеясен шулай ук «Ир-егетләр» һәм «Без бит авыл малае» пьесаларында да күрергә мөмкин.

Беренче пьесада бергә фронтта булган ике дус каршы куела. Берсе – бу тормышта үз урынын тапкан, тату гаиләсе һәм яраткан эше белән шөгыльләнгән Мәрвән, икенчесе – кайчандыр сәләтле архитектор булган, ләкин үз кыйбласын югалткан, гаиләсеннән аерылган һәм эчкечелеккә сабышкан Әхтәм. Дустына ярдәм йөзеннән, Мәрван аны үз авылына алып кайта. Авылның уңай тәэсире Әхтәмгә үз асылын табарга ярдәм итә. Сюжеттан шуны күрәбез: авылча яшәү рәвеше кешенең шәхесен нурландыра, аңа үз тормышында яңа мәгънә табарга ярдәм итә. Әхтәм рухи көч табу, үзен җәмгыятьнең аерылгысыз һәм мөһим бер өлеше итеп тою, шәхесенең асылына төшенү мизгеллләрен нәкъ менә авылда кичерә.

«Без бит авыл малае» пьесасында да, 25 ел дәвамында бөтен Советлар Союзы буйлап йөргән һәм шулай да үз бәхетен таба алмаган Галимҗан, туган авылына кайткач кына күңел тынычлыгына ия була. Нәтиҗәдә, автор тагын бер кат шуны раслый: тормыш сине үз нәселеңнән аерып, төрле сынауларга дучар итсә дә, рухи яктан чистарыныр өчен, һәрвакыт туган йортка кайту мөмкинлеге бар.

Т. Миңнуллин иҗатында авыл, туган җир кешенең рухына уңай тәэсир итә торган урын буларак тасвирлана. Автор туган авылының язмышы өчен шәхси җаваплылык тоя һәм үз әсәрләре аша татар авылының киләчәге һәм татар халкы язмышы арасында охшашлыкны параллель үткәрә. Аның күп кенә геройлары үзләренең нәсел тамырлары белән өзелмәс бәйләнеш сизәләр, бу образларда авторның шәхси-эмоциональ һәм фәлсәфи, гомумкешелек кыйммәтләре чагыла.

Туфан Миңнуллин иҗатында туган җир мотивы мөһим роль уйный: ул татар халкының үзенчәлеген саклау темасын гына түгел, ә геройларның, образларның, халыкның психологиясен тасвирлау өчен дә хезмәт итә. Бу геройлар өчен туган җир ул – үз кыйблаңны табарга мөмкинлек бирә һәм дөрес юлдан тайпылырга ирек бирми торган рухи көч чыганагы.

ӘДӘБИЯТ

Ахмадуллин А.Г. Татарская драматургия: истоки и проблемы. – Казань: Тат. кн. изд-во, 2012. – 511 с.

Әхмәдуллин А.Г. Яңарыш юлында: фәнни мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 204 с.

Закирзянов А.М. Модель татарской деревни в творчестве Т. Миннуллина // Социокультурное пространство российской провинции: историческая память и национальная идентичность: Сборник научных материалов IX Международных Стахеевских чтений. – Елабуга, 2019. – С. 194-198.

Закирҗанов Ә.М. Туфан Миңнуллин драматургиясе: монография. – Казан: ТӘһСИ, 2022. – 252 б.

Ключевский В.О. Значение преподобного Сергия для русского народа и государства // Развитие личности. – 2014. – С. 60-79.

Габәши-Салихова А. Иҗатында – ил гаме // Миңнуллин Т. Пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 5–13.

Салихова А.Р. Особенности формирования и развития татарского сценического искусства. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – 360 с.

Шарипова А.С. Идейно-эстетические особенности татарской советской драматургии 1960-х годов (на примере пьес Ш. Хусаинова и Т. Миннуллина) // Russian Linguistic Bulletin. – 2021. – С. 138-141.

Шарипова А.С. Татарская драматургия XX–начала XXI в.: Инвариант и его исторические трансформации: дис. ... д-р филол. наук: 10.01.02. – Казань, 2022. – 322 с.

УДК 81'373. 222

Искендерова Елизавета Камалатдиновна,
Нукусский государственный педагогический
институт им. Ажинияза

Зоонимические сравнения

сравнение, зооним, популярность, лексический слой, код, лингвокультурология

Можно подчеркнуть, что лингвистическим сравнениям – форме сравнения, которая в языкознании считается логической категорией, уделялось большое внимание ещё со времен Аристотеля. Он дал следующее определение метафоры: «Переносное слово (метафора) – это несвойственное имя, перенесенное с рода на вид, или с вида на род, или с вида на вид, или по аналогии», далее метафора была описана как сокращенное сравнение, особая синтаксическая форма выражения метафоры или любой метод переноса названия. И то, что объединяет метафору, сравнение и фразу основывается на сопоставлении,

характерном для человеческого сознания – сравнении. Поэтому сравнение может быть объектом изучения таких предметов, как логика, литература и языкознание. В психологии операция сравнения признана как одна из ключевых операций, осуществляемых человеком при познании окружающего мира, себя самого и других людей, а также в ситуациях решения разнообразных, в частности, когнитивно-коммуникативных задач.

В словаре О.С. Ахмановой «Словарь лингвистических терминов» дается следующее определение сравнения: «Сравнение (*англ. simile, фр. comparaison, нем. Gleichnis, исп. simil.)* – фигура речи, состоящая в уподоблении одного предмета другому, у которого предполагается наличие признака, общего с первым» [Ахманова 1966]. Так же, как и в метафорах, отличают устойчивые, свободные и индивидуальные сравнения. Л.А. Лебедева указывает, что, в отличие от индивидуальных, устойчивые сравнения «отмечены постоянством лексического состава, обеспечивающим постоянство его образной основы, отличаются относительной простотой и однотипностью грамматического строения» [Лебедева 2011]. По мнению Н. Махмудова, «...суть устойчивых сравнений состоит в том, что в них образ, выраженный в эталоне сравнения, становится устойчивым, такие сравнения, хотя и используются конкретным человеком или автором, со временем становятся традицией в языке и становясь устойчивыми выражениями успеют занимать место в лексиконе общенародного языка. Такие сравнения вводятся в речь, как если бы они были готовыми единицами языка» [Махмудов 2017].

В каракалпакском языке зоонимы продуктивно употребляются в составе пословиц, фазеологизмов, метафор, сравнений, стилистических фигур в целом. В нашем языке особенно продуктивно используются зоонимические сравнения. Сравнения – одна из характерных стилистических фигур языка. В каракалпакском языке П.А. Нажимов специально изучал сравнения, отмечая, что: «Среди предметов сравнения, связанных с растительным и животным миром, природой, можно выделить две группы: одушевленные и неодушевленные, которые укреплялись на протяжении веков» [Нажимов 1994].

Ш. Абдиназимов и Х. Толыбаев, рассматривая образные сравнения в качестве показателей национального менталитета, отмечают, что в сравнениях, связанных с характером и поведением человека, которые встречаются в речи носителей каракалпакского языка, часто используются слова, обозначающие различные виды животных: *ийттей сасық*

(вонючий, как собака), *малдай пәмсиз* (тупой, как животное), *қумырсқадай бийазар* (безобидный, как муравей), *ешектей қайсар* (упрямый, как осел), *өгиздей өкириў* (рычать, как бык), *тасбақадай тарбаңлаў* (ползти, как черапаха), *жыландай жылжыў (*ползти, как змея*),* *бүлбилдей сайраў* (петь, как соловей) [Абдиназимов 2020].

В любом языке зоонимические сравнения используются и в прямом значении, и в переносном. Сравнение человека с животным имеет давние традиции во многих культурах. Зоонимические сравнения напрямую связаны с окружающей средой, природой, местностью и климатом определенного этноса. Поскольку, такие животные, как *страус, жираф, хамелеон, тюлень* и т.д. не обитают в наших краях, почти не встречаются сравнения, связанные с ними. Но названия таких животных, как слон и медведь хоть редко, но все же встречаются в составе сравнений в нашем языке, хотя и эти животные живут в далеких от нас краях.

Сравнение представляет собой сопоставление двух предметов по одному общему признаку, качеству или свойству и т.д.

Зоонимические сравнения являются ярким доказательством формирования и обогащения культуроведческих взглядов каракалпакского народа. Не все слова в языке употребляются в прямом значении. Можно подчеркнуть, что некоторые слова используются в роли сравнений, с компонентами-зоонимами. Такие устойчивые единицы не возникают сами по себе, поскольку в выполнении зоонимами эвфемической, метафорической задач в сравнениях доминирует эмоционально-экспрессивное влияние.

В своей научной работе Ф. Усманов пишет, что «Биоморфный код связан с животными или растениями, он отражен в названиях животных, насекомых, птиц или растений» [Усманов 2020]. В природе его ближайшими соседями являются представители животного и растительного миров. В сравнениях через биоморфный код могут отражаться почти все качества человека, например, храбрость – *бүркиттей* (как сокол), *қаршығадай* (как орёл), сила – *айыўдай* (как медведь), *арысландай* (как лев), *жолбарыстай* (как тигр), *нардай* (как верблюд), *пилдей* (как слон), пахать, как – *ийттей* (собака), *ешектей* (осел), *өгиздей* (бык), *қумырсқадай* (муравей),обвивать, как – *өрмекшидей* (паук), *жыландай* (как змея) [Махмудов 2017].

Происхождение пословиц-поговорок и фраз с компонентом-зоонимом, берет начало с незапамятных времен и их основу составляет такое наследие, как повседневный быт, мудрость, наставления и советы

нашего народа. Поскольку основным родом деятельности наших предков были животноводство и земледелие, в ранние времена количество скота определяло материальное положение народа. Понятие скот предполагает виды животных, считающихся *хадал* (дозволенный исламской религией к употреблению). Например: Сәске ўақытта Байбөритамаша болсын тойым деп, ортаға көкпар таслады, еки жарын болып ылақ ойнады. (Вечером Байбури, чтобы той был интересным, кинул на середину *кокпар*, и стали две стороны играть в *ылак*) («Алпамыс»). Ериксиз тақымыңа бастың, Ылақ қылып алып қаштың. (Невольно зажав под коленом, унес с собой *ылак*) («Алпамыс»). Еки қолын услады, *Көкпар текедей.* (Захватив за обе руки, словно *кокпар – козла)* («Алпамыс»).

Использование туши ягненка в этой национальной игре неслучайно. Так как она (туша ягненка) легкая, всаднику (игроку в кокпар) удобно держать её в руке. Это является признаком ума и глубокого мышления народа. По этой причине в нашем языке прочно осели сравнения с зоонимом *ылақ* (ягненок): *ылактай халы бар* (слабый, как ягненок), *салмагы ылыктын салмагындай* (весит, как ягненок).

В заключение можно сказать, что сравнения с компонентом-зоонимом, тесно связаны с историей и бытовой культурой каракалпакского народа. В зоологических сравнениях показана глубина человеческого сознания, и внешний вид, движения и поведение человека сопоставляются с животным миром. Культура пастбищного животноводства каракалпакского народа нашла свое выражение в языковой культуре народа. Наблюдается формирование эвфемизмов с компонентом-зоонимом посредством сравнения человека с животным миром. Зоонимы в каракалпакском языке имеют эмоционально-экпрессивный характер.

Использование в зоонимических сравнениях единиц, связанных с животноводством, показывает: они занимают весомое место в национальном сознании тюркских народов, в том числе и каракалпакского народа, а также то, что они имеют культурную ценность.

ЛИТЕРАТУРА

Абдиназимов Ш. Лингвокультурология / Ш. Абдиназимов, Х. Толыбаев. – Нөкис: Қарақалпақстан, 2020. – 93 б.

Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. – М: Советская энциклопедия, 1966. – 606 с.

Лебедева Л.А. Устойчивые сравнения русского языка: краткий тематический словарь. – М.: Флинта, 2011. – 300 с.

Маҳмудов Н. Тил тилсими тадқиқи. – Тошкент: Mumtoz so'z, 2017. – 119 б.

Нажимов П.А. Структурно-семантические особенности сравнения в каракалпакском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Нукус, 1994. – 18 с.

Усманов Ф.Ф. Ўзбек тилидаги ўхшатишлернинг лингвомаданий тадқиқи: филол. фан. фалс. д-ри (PhD) … дис. автореф. – Тошкент, 2020. – 19 с.

УДК 811.512.145

Кадирова Энҗе Хәнәфиевна,

ТР ФАнең Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә тиңдәш кисәкләр

татар әдәби теле, язма истәлекләр, Казан ханлыгы, тиңдәш кисәкләр

Татар галимнәренең фәнни хезмәтләрендә тиңдәш кисәкләр турында кызыклы күзәтүләр урын ала. Соңгы елларда тиңдәш кисәкләрнең җөмләдәге кулланылышына да зур игътибар бирелә [Курбатов 2002; Ибраһимов 1989; Гәлләмов 2003, Сәгъдиева 2017]. Х. Курбатов «Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы» китабында сәнгатьле сөйләмдә тиңдәш кисәкләрнең, аларга нигезләнеп төзелгән теземнең кулланылу үзенчәлекләренә туктала [Курбатов, 2002: 139-144]. Ул тиңдәш кисәкләрнең текстта ни рәвешле урнашуы, образлылык тудыруын, мөһим сурәтләү чарасы булуы турында яза. С.М. Ибраһимов шулай ук тиңдәш кисәкләрнең стилистик кулланылышына игътибар итә. Ул «Синтаксик стилистика», «Сандугач теле кирәк» хезмәтләрендә тиңдәш кисәкләрнең стилистик яктан зур роль уйнаганлыгын ассызыклый. С.М. Ибраһимов фикеренчә, «кайбер язучылар, тиңдәш кисәкләрнең симметрияле кулланылышына игътибар биреп, үз әсәрләрендә салмак кына ага торган, киң сулышлы язу алымы барлыкка китерәләр» [Ибраһимов 1989: 83].

XV-XVI гасыр әдипләреннән Өмми Камал үз әсәрләрендә тиңдәш кисәкләрне гаять күп куллана. Аның тиңдәш кисәкләрне санауга корылган аерым шигырьләре бар. Автор Аллаһны олылаганда, Мөхәммәд пәйгамбәрне зурлаганда аларның сыйфатларын санап китә: ***Сурмадан билән, бакмәдән күрән, Сынмадин дутан, атмадин уран, Дыңламадин аңлайан, ишедән*** *Танышыйк сезир вә йалыңуз иш идән* [Фәтхтдинов 2022: 275]; ***Ул сафый илляһ адәм хакы чүн, Дәхи һабил үзрә***

матәм хакы чүн, Корб Шәйс Рәфгать Идрис үчүн, Нәүхә нух дәми җәрҗис үчүн / Хәүф йахи вә әман һавад үчүн Хәбис Йуныс нигъмәи Дауд үчүн/ Йараб Әйүбең бәляйә сабыри үчүн һәм Сөләйманың гатаңа шөкри үчүн /Дәхи Йагъкубың фиракы хәзәни чүн Йосыфың корб висалы хөсени чүн / Җөмлә хәлыкың сәр гайбин күзләйән Колларының дүрлү гайбин гизләйән / Чинар, сәрви, санаубәр, шәкаик, рәйхан, *Кә һәр нигяр кыйлур тапу гөл сәр фиразә* [Фәтхтдинов 2022: 275].

Һөдһөд, әкәйек, кәклик, дораҗ, күгәрчин *Сөбхани хуш аваз илә тәсбих идәр улды* [Фәтхтдинов 2022: 281] мисалларында тиңдәш ияләр урын алса, ***Аг, кызыл, ал, йәшел, күк, сары*** *туни Кяиб тунатуб, һәр бери үзин бизәр улды* [Фәтхтдинов 2022: 272] бәетендә төсләрне санап үтә, ягъни тиңдәш аергычлар була. *Әй Мөнкир, мәхшәр,* ***күзең ач, аңла, йүрак бак, Күр****, шеш җиһаты кем сәрасәр нә габир улды* [Фәтхтдинов, 2022: 272] очрагында хәбәрләр тиңдәшләнеп килә. Тиңдәш хәбәрләр эш, процессның эзлеклелеген күрсәтә. Истәлекләрдә тиңдәш тәмамлыкларга да мисаллар урын ала: *Габдулла әйде:* ***Йирне, күгне, көнне, айны, йолдызларны*** *яратган тәңре бар торур* [Сираҗелкулүб 1903:74].

Ярашмаган тиңдәш кисәкләр дә була. Тавтология булмасын өчен, тиңдәш кисәкләрнең соңгысы гына билгеле бер форма кушымчасын алган очраклар бу чор истәлекләрендә урын ала: ***Дин вә дөнья, йер, күкнең*** *мөфәххәри, – Өнсе җан вә җеннең пәйгамбәри* [Мөхәммәдьяр 1997: 203].

Татар телендә тиңдәш кисәкләрне бер-берсенә бәйләп һәм алар арасында төрле мөнәсәбәтләрне белдереп, теркәгеч чаралар да киләләр [Татар грамматикасы 2017: 186]. Теркәгеч чараларга санау һәм каршылык интонацияләре, җыючы, каршылык һәм бүлүче теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр керә. Мисаллардан күренгәнчә, авторлар тиңдәш кисәкләр арасында теркәгечләрне куллануны бик хуп күрми. Мондый үзенчәлекне Х. Курбатов «шигырь теркәгеч куллануны (аеруча «һәм»не) бик үк яратып бетерми» дип аңлата [Курбатов 1971: 135]. Шулай да Өмми Камал иҗатында теркәгечле очраклар да урын ала. Һәм теркәгече һәр тиңдәш кисәк янында килеп, аларның һәркайсына аеруча басым ясауны тудыра: *Һәм Мөхәммәд гәр тәү* ***колыңдур сәнең, Һәм хәбибең, һәм рәсүлеңдүр сәнең*** [Фәтхтдинов 2022: 317]; *Йүрәгем башлу дорур, һәм кем күзим йәшлә тулудыр, һәм Бу зәхемә ул үрә мөррә, һәм андан-*

дур каму балям [Фәтхтдинов 2022: 272]. Һәм теркәгече урынына илә бәйлеге килгән очраклар да аз түгел: *Суларда йүзәр шад улубән **үрдәк илә каз һәм тависи** кур багчада нә җилвә гәр улды* [Фәтхтдинов 2022: 272]. Илә бәйлеге дә һәр тиңдәш кисәктән соң урнашып, аларның һәрберенә басым ясала:***Гилем илә, хәдис илә, тәфсир илә,** Сөйләшәлүм икебез анда билә* [Кыз хикәяте 2012: 57]; *Кемсә башына чыкмады бу кыз иллә, Нә **гилме илә**, нә худ **коры сүз илә*** [Кыз хикәяте 2012: 56].

Әхмәд, Мәхмүд, Хәмид, Мостафа, Мөҗтәба, вә Мортаза, вә Моктадә [Фәтхтдинов 2022: 317] мисалында без вә теркәгеченең кабатланып килүен рифма таләбе белән аңлатабыз.

«Ни-ни яки нә-нә теркәгече хәзерге әдәби телдә юклык формасы белән бәйләнгән тигез дәрәҗәле тиңдәшләрне бәйли», – дип билгели М. Зәкиев [Татар грамматикасы, 2017: 186]. *Бу гөлстанда **нә** гөлләр калур, **нә** былбыллар, Бу мишә ичрә **нә** каплан калур, **нә** дөлкү шир* [Фәтхтдинов 2022: 268]; *Кемсә башына чыкмады бу кыз иллә, **Нә** гилме илә, **нә** худ коры сүз илә* [Кыз хикәяте 2012: 56].

Ярдәмче сүзләрне, бигрәк тә тиңдәш кисәкләр һәм җөмләләр арасында теркәгечләрне еш кабатлауны, ягъни полисиндетон күренешен шулай ук очратырга була: *Өченче кат йирдә Тәңре тәгалә халыклар яратмыш торыр: **йөзләре адәми йөзләре, тик агызлары эт агызы, тик элләре адәм эле, тик аяклары үңүз аякы, тик түкләре куй түке, тик һәргиз күз йомуб ачкунчә Тәңре тәгаләгә тәгать дин хәле** булмазлар* [Сиражел-кулүб 1903: 7]. Тиңдәш кисәкләрнең һәрберсенә уртак булган бер сүз кабатланып килү аларның һәрберсенә дә ныграк басым ясауны белдерә. «Сираҗ әл-кулуб» авторы тәкый теркәгечен максатчан куллануга тагын бер мисал: *Тәңре газзә вә җәллә **йиде кат күкне, йиде кат йирне, тәкый боларның арасында адәмиләрне, фәрештәләрне, җенләрне, киекләрне, кошкортларны, тагларны, йыгачларны, тәкый йилләрне, тәкый үзгәне** кем бар ирсә, җөмләсене алты көндә яратды* [Сиражел-кулүб 1903: 3]. Бу җөмләдә, мәсәлән, автор тиңдәш кисәкләрне теркәгечсез саный башлый һәм мәгънә мөнәсәбәтендә алардан үзгәрәк торганнарын тәкый теркәгече белән башлап аера, соңыннан басым ясау нияте белән тагын әлеге теркәгечне куя.

Тиңдәш кисәкләргә Өмми Камал иҗатыннан тагын мисаллар китерергә була*: **Карәмәтләр, вилайәтләр, гыйбадәтләр, риазәтләр, / Сәхавәтләр, зиафәтләр** чуг итде вакыт җаенда* [Фәтхтдинов 2022:

290]; *Шу* ***өчләр, йиделәр, кырыклар һәм өч йүзләр һәм гайбләр*** */ Үгүнчә котыб сәрвәр у газиләр алай инде* [Фәтхтдинов 2022: 290]; ***Кәлән кәчәр, кунан күчәр*** *һәмишә /* ***Дирилән тагылур*** *әл хөкме лил-лях* [Фәтхтдинов 2022: 291].

Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр килә. Һәммәсе дә, барысы, бөтенесе, һичнәрсә, һичбере кебек алмашлыклар һәм алмашлык урынындагы сүзләр гомумиләштерүче сүзләр булып, баштагы өчесе – раслаучы җөмләләрдә, калган өчесе инкяр җөмләләрдә кулланылалар, һәм алар барысы да, гадәттә, тиңдәш кисәкләрдән соң куелалар. Тиңдәш кисәкләрдән аңлашылган әйберләр, процесслар, билгеләр керә торган ыру, төр төшенчәсен белдерүче сүзләр дә шул тиңдәш кисәкләрне гомумиләштереп киләләр [Татар грамматикасы 2017: 190]. Мәсәлән, *Каму нәснә диллү диленчә аны тәсбих идәр: Һәр җәмадат, нәбатат, корулар, йашләр* [Фәтхтдинов 2022: 293] бәетендә каму нәснә һәр җәмадат, нәбатат, корулар, йашләр тиңдәш кисәкләрен гомумиләштереп килә. ***Җин, мәлик, бу адәм вә хәйван – һәр бери*** *Диллү диленчә хальни ул хакә раз идәр* [Фәтхтдинов 2022: 426]; ***һөдһөд, комари, күгәрчин, тутый*** *дәрраҗ илә Тутдыйлар бу мәҗлес эчрә* ***һәр бери*** *саут саз* [Фәтхтдинов 2022: 277]; *Камуси зәүкә кәлүб ула валлаһ вә хәйран: Зәһи дәм, зәхи мәхфил, зәһи мәкян, заман* [Фәтхтдинов 2022: 347].

Тиңдәш кисәкләрнең стилистик кулланылышы белән бәйле тезем дигән күренеш бар. «Тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу аркасында, бик нык җәенкеләнгән гади яки кушма җөмләгә тезем диләр» [Татар грамматикасы 2017: 492]. Тиңдәш кисәкләрне яисә тиңдәш җөмләләрне тезеп китү, нигездә, шигъри әсәрләргә хас, шулай ук прозада да булырга мөмкин. Тиңдәш кисәкләр, шул исәптән, тезем дә бик борынгы истәлекләрдә үк кулланылган [Курбатов 2002: 152]. Өмми Камал иҗатында аның матур үрнәкләрен очратырга мөмкин: *Бакың әй җан дил күзин ачанлар / Бәка милки фәна удын сачәнләр/ Кани шул дөньйайә мәгърур уланлар / Кани шул мәнзилә кунуб кичәнләр/ Кани шул илләрә безим дийәнләр / Кани шул йулларә кәлүб кичәнләр/ Кани шул багълары дигүб кидәнләр / Кани шул йирләрә игүб печәнләр / Кани шул кальгәләр бәреҗләр йапанлар / Кани анда дуруб йейеб ичәнләр / Кани шул байларә хөрмәт кыйланлар / Кани йуксуллари йирүб качанлар / Кани шул җәмгъ улуб тиз тагыйланлар / Кани шул шәмгъ улуб йануб учанлар / Кани шул гыйшрәт идүб рәкыс уранлар / Кани шул башларә сачү сәчанләр / Кани шул биш алубән кем сатанлар / Каму хәлыкның хакын белүб печәнләр /*

Камал Өмми сән ул хакдан йиңә кач / Качан куртылур үлүмдән качанлар [Фәтхтдинов 2022: 423-424]. Өмми Камал әсәрләре җыентыгыннан тагын да мисаллар китереп була [Фәтхтдинов 2022: 321-322; 388]. Бу мисалда тиңдәш кисәкләрне ачып җибәрү өлеше юк, ягъни тезем тиңдәшләрнең үзләреннән генә тора. Тиңдәш кисәкләрне ачып җибәрү өлеше дә булган теземнәр дә бар.

XV-XVI гасыр истәлекләре авторлары тиңдәш кисәкләрне актив файдалана. Тиңдәш кисәкләр әйтелгәннәрнең мәгънәсен көчәйтүдә, геройларның төгәлрәк образын булдыруда, хикәяләү динамикасын бирүдә, вакыт һәм урын үзенчәлеген тасвирлауда ярдәм итә.

ӘДӘБИЯТ

Галләмов Ф.Г. Тиңдәш кисәкләрнең һәм гомумиләштерүче сүзләрнең синтаксик вазыйфалары // Милли мәдәният. – Казан. 2003. – Б. 41–46.

Ибраһимов С.М. Синтаксик синонимнар. – Казан: КДУ нәшр., 1989. –150 б.

Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1971. – 192 б.

Курбатов Х. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

Кыз хикәяте / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2012. – 184 б.

Мөхәммәдьяр Нуры содур. Поэмалар, шигырь. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 336 б.

Сәгъдиева Р.К. Татар теле белемендә тиңдәш кисәкләрне өйрәнү тарихыннан // Татарика. – 2017. – № 9. – Б. 32-41.

Сиражел-кулүб. – Казань: Типография Т-го Дома Братьевъ Каримовыхъ, 1903. – 93 б.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘhСИ, 2017. III. т. – 536 б.

Фатхтдинов Ф.К. Өмми Камал китабы. – Казань: ИЯЛИ, 2022. – 648 с.

УДК 82.01/.09

Казахбаев Сарсен,
Нукусский государственный педагогический
институт им. Ажинияза

Источники возникновения и формирования детской литературы, ступени развития и своеобразные особенности

детский фольклор, сказки, легенды, скороговорки, загадки, эпические произведения

Детская литература корнями уходит вглубь к источникам наследия, относящихся к детям, к народным песням о детях – детскому фольклору, сказкам, легендам, скороговоркам, загадкам, пословицам и поговоркам, эпическим произведениям, являющимся образцом устной литературы, созданной нашим народом столетия назад.

Детская литература в европейских государствах начала появляться в XIV-XVI веках. Русский алфавит Ивана Федоровича, изданный в1574 году, считается их первым образцом. В XVII веке в русской детской литературе начинают появляться произведения, присущие поэтическим и прозаическим жанрам, впоследствии в этой отрасли начали создаваться сказки, рассказы, новеллы, сказания, очерки, романы. Первое драматическое произведение, предназначенное для детей, принадлежал перу И.А. Крылова, драма «Қизимга таълим» («Учения для дочери»), созданная в 1707 году [Сетин 1990].

В Европе образцы детской литературы начинают появляться в XVII веке, т.е. французские писатели Джонатан Свифт, Шарль Перро, братья Гримм из Германии, датчанин Ханс Кристиан Андерсен, русские писатели А.С. Пушкин, Н.А. Некрасов, в конце XIX – начале XX веков Л.Н. Толстой, К.И. Чуковский, С.Я. Маршак, В.В. Маяковский посвящают свои произведения детям и создают основу для появления термина «Детская литература».

Она в европейской литературе появилась в качестве специально сформированного литературного вида во второй половине XVIII века. Её развитие и совершенство тесно связано с достижениями патриотических и педагогических идей (Дж. Локк, Ж.Ж. Руссо, И.Г. Песталоцци, Ц.И. Новиков) [http://plr.iling-ran.ru].

Значит, детская литература сначала появилась в экономически развитых странах, затем постепенно стала формироваться в качестве отдельной сети литературы. Большинство ее признаков определились, стали появляться определенные создатели. За период развития детская литература пережила и ускоренные, и замедленные шаги развития. У множества народов стала появляться специальная детская литература и её творцы.

Детская литература не оторвалась от цельного литературного процесса, в её произведениях явно чувствовалось влияние фольклора, литературных течений и методов XVIII-XX веков. Её пропитание

нравственными, дидактическими идеями стало одним из особых признаков детской и подростковой литературы.

XVIII-XIX веках своими сильными гуманными направлениями и реальным жизненным пафосом огромное значение имели произведения, написанные по фольклорным мотивам и посвященные детям сказки (Братья Я. и В. Гримм, В. Хауф), сказки письменной литературы (Ш. Перро, Х.К. Андерсен, Э.Т.А. Гофман, А. Кэррол, С. Лагерлёф), а также, некоторые романы и повести приключенского жанра (Майн Рид, М. Твен, Р. Стивенсон) [http://plr.iling-ran.ru].

Произведения данных авторов сослужили достойную службу в формировании мировой детской литературы. Таким образом, их произведения вошли в ряд произведений классической детской литературы. Каракалпакская детская литература тоже, получая подпитку из родников своих внутренних источников и мировой литературы сформировалась в качестве отдельной литературы.

В каракалпакском литературоведении и фольклороведении по детской литературе, появившейся под влиянием фольклора, выдвинули и классифицировали свои взгляды и концепции Н. Давкараев, К. Айимбетов, И. Курбанбаев, К. Максетов. К примеру, судя по особенностям детских стихотворений, Н. Давкараев утверждает, что эти особенности, в первую очередь, заключаются в их коллективном исполнении, во-вторых, они исполняются во время проведения народных игр, в-третьих, они исполняются в вопросно-ответной форме, они являются разнообразными с тематического аспекта и делит их на виды и жанры. Ученый является исполнителем детской литературы в фольклоре, изучает вопросы её роли в развитии детского мышления. А К. Айимбетов отмечает, что «развлекательные стихи являются детскими играми, когда дети играют в коллективные игры, некоторые игры исполняются в поэтических стихотворных формах».

Известно, что детские стихотворения или другие произведения, предназначенные для детей, находятся в тесной связи с играми. Так как, дети вместе с игрой, во-первых, удовлетворяют физические потребности своего организма, во-вторых, исполняя различные стихотворения или другие произведения, предназначенные для детей, развивают свое мышление, иными словами, удовлетворяют духовные потребности. О гармонии художественного творчества и игры литературные теоретики излагали свои ценные мнения [Казахбаев 2009: 45].

Мыслители XIX-XX веков излагали свои ценнейшие мнения о месте, занимаемом играми в развитии человеческой жизни.

Ф. Шиллер утверждает, что человек вырастет настоящим человеком только в том случае, если он вырос, играя в игры. Й. Хейзенг говорит, что культура человечества формируется через игру. Писатели и ученые (Л. Толстой, Т. Манн, В.Ф. Переверзев) комментируют, что художественное творчество по своему содержанию выросло из игры, оно является одним из видов игры, обладающим отдельной особенностью.

В детском фольклоре по такому генезису смешанных игр, этапам развития, жанровым особенностям многие фольклороведы и литературоведы проводили научно-исследовательские работы. К примеру, в русском фольклороведении Г.С. Виноградов, И.О. Капица, В.П. Аникин, Н.И. Мельинов, татарском фольклороведении Ф. Жахонгиров [Жахонгиров 1975], О. Сафаров [Сафаров 1985], Н. Сафарова [Сафарова 2008], каракалпакском литературоведении такие, как И. Курбанбаев, С. Казахбаев с научной точки зрения изучали зарождение детских стихотворений и игр с генетического аспекта. Самое удивительное в том, что исследователями утверждается, что даже в фольклорах генетически не близких друг другу народов существуют эти вопросы. В качестве яркого примера этому научно доказано то, что песня «Оқ теракми, кўк терак» («Белое дерево или зеленое дерево») предназначено для детей среди русского, узбекского, казахского, таджикского, татарского, каракалпакского народов.

Если Г. Жахангиров и Г. Галиев останавливаясь на историческом генезисе игры «Оқ теракми, кўк терак» («Белое дерево или зеленое дерево») утверждают её связь с древним родоплеменным периодом, то Р. Ячьфаров утверждает, что основные корни игры уходят в древние времена, когда люди преклонялись «дереву». А О. Сафаров, собрав несколько вариантов этой игры, выявляет их похожие друг на друга стороны и называет их «играми-переговорилками».

Н. Сафаров связывает генезис появления стихотворения «Оқ теракми, кўк терак» («Белое дерево или зеленое дерево») с мифологическими взглядами. Утверждает, что в ней отражено то, что наши предки преклонялись перед деревом. По его словам, белое дерево бывает мягкой, а зеленое дерево тверже, во-вторых, для людей белый цвет является символом «счастья и величия», зеленый цвет перешел в

стихотворение в результате восприятия его в качестве символа вечности [Сафаров 1985].

В заключение хочу сказать, что можно наблюдать похожесть песен детского фольклора на игры и песни, исполняемые у русского, татарского, казахского, туркменского, таджикского, дагестанского, грузинского, латынского и других народов. И по этой причине, в современный период явно чувствуется необходимость в сопоставительном изучении типологических схожестей и различий в детских песнях.

ЛИТЕРАТУРА

Курбанбаев И. Қарақалпақ балалар әдебияты. – Нөкис: Билим, 1992. – С. 17.

Жахонгиров Ғ. Ўзбек болалар фольклори. – Тошкент: Ўқитувчи, 1975. – С. 20.

Сафаров А. Жанровый состав и поэтика узбекского детского поэтического фольклора: автореф. дисс. ... доктора филол. наук. – Ташкент, 1985.

Сафарова Н. Ўзбек болалар ўйин фольклори табиати. – Тошкент: Фан, 2008. – 47 с.

Сетин Ф.И. История русской детский литературы. – М.: Просвещение, 1990. –163 с.

Казахбаев С. Автореферат диссер. «Эволюция, жанровый состав и поэтика каракалпакской детской литературы конца XX Назала XXI веков». Нукус-2019. http://plr.iling-ran.ru

УДК 801.6

Каюмова Гөлүсә Фәрит кызы,
Казан федераль университеты

Л. Янсуар шигъриятендә мифологик-орнитологик образлар

Луиза Янсуар, образ-символ, һомай кош, бөркет, ил язмышы

Луиза Янсуар – XXI гасыр татар әдәбиятының яңа дулкын шагыйрәсе, әсәрләрдә ватаныбызның гыйбрәтле язмышы, милләт киләчәге, заман һәм кеше бәйләнышлары, мәхәббәт темасын яктырткан, гади һәм катлаулы метафорик образлар белән уйлаган һәм иҗат иткән әлеге шагыйрә иң актив иҗат итүчеләрнең берсе. Шагыйрә иҗатында орнитологик образларның күп кулланылышы искә алынса да (мәсәлән, Г.С. Сафина аның иҗатында кош һәм канат образларының төрлелеген, катлаулылыгын әйтеп китә [Сафина 2020: 238]), бу образлар артында торган катлаулы һәм тирән мәгънәле фикерләр анализланмый.

Л. Янсуарның «Һомай» шигыре мисалында мифологик-орнитологик образларның бирелеш үзенчәлекләрен күзәтик.

Шигырьдә лирик героиняның дөньяны, чынбарлыкны кабул ителешен кыска, нигездә номинатив җөмләләр ярдәмендә өзек-өзек тасвир ителә. Эпиграф итеп «Повесть Временных лет» әсәреннән алынган өзек кулланыла: «И заключил Владимир мир с болгарами, и клятву дали друг-другу, и сказали болгары: «Тогда не будет между нами мира, когда камень станет плавать, а хмель – тонуть». И вернулся Владимир в Киев» [Янсуар 2022: 5]. Шушы эпиграф лирик геройның хисләре сәбәпчесен аңларга да ярдәм итә. Ә инде шигырьнең буеннан-буена кабатланып килгән һомай кош образы, безнең фикеребезчә, өмет белән өметсезлек чикләрендә калган героиняның киләчәктә юаныч таба алачагына өметле булуын күрсәтә кебек. Эпиграф һәм әсәр сөрешеннән күренгәнчә, әрнү, кайгы хисенең сәбәбе – ил, дәүләтнең, туган телнең каршылыклы халәте:

Беркемгә дә сөйли, сөйли алмам инде
Ватанымда (газиз!) ниләр күргәнемне.
Ишеткәнне ниләр. Йомылмас бу җөйләр.
Чәчемдәге чулпы. Җәйләүдәге елкы.
Хөрлек бәрабәре гомерләрен биргән
Бабамнарның коты. Бабамнарның холкы [Янсуар 2022: 5].

Шигырь аһәңендә юлдаш, фикердәш булмау, авырлык, әрнү алдында ялгыз калу мотивы сизелә, әмма бу ялгызлык төшенкелеккә калдыра торган түгел, чөнки героиняның улы һәм кызы бар. Шунысы кызык: бала тасвирлары бирелгән урында һомай кош образы да пәйда була:

Баш очымда Күк бар. Табанымда – туфрак.
Мәңге шулай иде. Һәм бүген дә шулай.
Җилкәмдәге толым. Җилендәге кулым.
Карындагы улым. Ирек кошы Һомай [Янсуар 2022: 5].

Кыз образы кергән строфа белән чагыштырыйк:

Тамырларым белән тән береккән җирем.
Мәңге шулай иде. Һәм бүген дә шулай.
Кулымдагы кылыч. Җанымдагы корыч.
Бишектәге кызым. Бәхет кошы Һомай [Янсуар 2022: 5].

Аңлашылганча, ил, дәүләт бөтенлеге шул вакытта мөмкин: ил уллары Ирек тәэмин итсәләр. Ул, ир – нәселне дәвам итүче буларак та аңлашыла. Шуңа күрә, безнең уйлавыбызча, угыл образы кергән строфада күп халыклар мифологиясендә һәм шулай ук юнгиан

психологиясендә дә мәхәббәт, мәхәббәт ләззәте символы булган толым образы да урын ала. Кыз исә илнең, гаиләнең бәхетен тәэмин итүче буларак аңлашыла, Һомай да биредә асыл вазифасында – бәхет кошы образы буларак килә. Кызның бәхете куркынычсызлык шартларында гына мөмкин. Шуңа лирик героиня кыз сагында да тора: ана кулында кылыч, җанында корыч булуын ассызыклап китә.

Әмма шартлар авырлыгын искәртеп, текстка бәхет кошыннан кала электән батырлык, җитезлек символы булган бөркет образы килеп керә һәм бабалардан килгән батырлыкның, хөрлекнең бүген булуында шик уята да:

Һавадагы бөркет. Үз-үзеннән өркеп,
Күзләренме чукый? Чукый йөрәгенме?
Беркемгә дә сөйли, сөйли алмам инде
Ватанымда (газиз!)ниләр күргәнемне [Янсуар 2022: 5].

Шигырьнең соңгы юллары укучыда киләчәктәге бәхет-хөрлекнең чын яки иллюзия булуында тагын шик уята, сәбәбе дә бар: шагыйрә эпиграфта искә алынган солыхтагы кире, мәңге булмаячак кебек тоелган вакыйгаларны күрә:

Була алмам бүтән. Ахыргача көтәм.
Күләгәң бер төшәр, төшәр ләса, Һомай?!
Өскә калка ташлар. Өскә калка башлар.
Төпкә бата колмак... Колмак кына бугай [Янсуар 2022: 5].

Әмма игътибарны шуңа да юнәлтү кирәк: халыклар дуслыгы турындагы килешүгә каршы вакыйгалар буларак «ташлар калка, колмак бата» башласа да, шагыйрә һаман Һомай кошка, аның бәхет китерәчәгенә өметен өзми, ул инде Һомайның үзенә дә мөрәҗәгать итә. Шунысы да кызык: М. Кашгарыйның атаклы «Диване лөгат-эт-төрек» сүзлегендә, «Умайга табынса, угыл булыр» мәкалесе дә урын ала. Белгечләр аны, Умайга табынучының баласы булыр дип тә, Умайга табынучының барсы да булыр дип тәрҗемә итәләр [Мамбетова 2017: 162]. А. Бисенбаев хезмәтендә исә төркиләрнең баш алиһәсе Умайның бер символик сурәте буларак бәхет китерүче кош образына тасвирлама бирелә [Бисенбаев 2008: 7]. Болардан, киләчәк бәхеткә ышанып яшәргә, өметсезлеккә бирелмәскә, бабалар хәтерен җуймаска кирәк, дигән нәтиҗә ясала.

Шулай итеп, һомай кошы мифологик-орнитологик образы Л. Янсуар иҗатында милләт, дәүләт язмышы өчен борчылу, аның киләчәк бәхе-

тенә ышану, шул матур киләчәк шартлары буларак ирек һәм халык, милләт бәхетен күрсәтү өчен кулланыла. Әмма шигырьдәге «үз-үзен чукый торган бөркет» образы бу бәхет өчен көрәшүче милләт уллары-кызлары барлыгына шик тудыра, бәхет-хөрлеккә илаһи көчләр ярдәмендә генә ирешеп була, дигән бер яктан, өметле, икенче яктан әрнүле хисләр уята.

ӘДӘБИЯТ

Бисенбаев А. Мифы древних тюрков. – Алматы: Ан-арыс, 2008. – 120 с.

Мамбетова В.М. Культ Тенгри и образ Хумай в тюрко-башкирской эпической литературе // Вестник Челябинского государственного педагогического университета. – 2017. – №7. – С.160-163.

Сафина Г.Ф. Образ-символ крыльев в татарской поэзии второй половины XX в.: семантическая структура и особенности функционирования (на примере лирики Сажиды Сулеймановой) // Казанский лингвистический журнал. – 2020. – Т.3. – № 3. – Б. 224-242.

Янсуар Л. Мин сүзләрне җылы сөткә манам...: Шигырьләр // Казан утлары. – 2022. – Б. 3-7.

УДК 81’44

Кдырбаева Гулзира Курбанбаевна

Нукусский государственный педагогический институт им. Ажинияза

Мифологическая модель мира в формировании языкового сознания

миф, мифология, мифологическая картина мира

В современном этапе развития мировой лингвистики акцент делается на изучение различных концептов и явлений, включая элементы мифологических концептосфер, в контексте когнитивной лингвистики и языкознания, активизируется интеграция со смежными дисциплинами. В настоящее время особый интерес представляет изучение единиц мифологических концептосфер с точки зрения лингвокультурологии. Значительное внимание уделяется различиям в семантических структурах единиц, отражающих мифологическую концептосферу различных языков, признавая их универсальность. Следует отметить, что социальное и

мифологическое мышление человека представляет собой многообразный аспект познания мира. Однако для передачи этого многообразия необходимо адекватно выразить его в языковых формах, отражая особенности мышления разных культур.

Нацонально-культурные концептосферы представляют собой особые лингвокультурные конструкты, выраженные через языковые единицы и связанные с мифологическими представлениями. Эти концептосферы формируют основу культурного кода народа, влияя на лингвистические, когнитивные и культурные аспекты повседневной жизни.

Картина мира, сложившаяся в национальной мифологии, влияет на формирование языкового сознания. Эта картина мира формируется путем восприятия окружающего мира, его организации и исследования. Она воплощает в себе мифологические образы, символы, архетипы, которые тесно связаны с лингвистическими единицами и концептами.

Национальная картина мира отражает особенности восприятия мира нацией. Она формируется культурными, историческими, религиозными и социальными факторами. Языковая картина мира тесно связана с национальной, но представляет собой более специфический аспект, выраженный через языковые средства.

Мифологическая картина мира отражает глубинные мифологические представления, формирующиеся в процессе эволюции культуры и социума. Она включает в себя мифологические образы, символы, мифологические предания и верования, которые оказывают влияние на языковую систему и выражение мышления.

Архетипы и мифологемы являются фундаментальными концептами в мифологическом мышлении. Архетипы представляют собой универсальные образы и символы, находящиеся в коллективном бессознательном и повторяющиеся в мифах, сказаниях, мистических текстах различных культур. Мифологемы – это основные мифологические сюжеты, мифические сценарии, которые также переходят через различные культуры и языки.

Изучение непостижимых и сверхъестественных явлений и вещей, а также их отражение в языке, является важным аспектом для понимания культуры и мировоззрения различных обществ. Мифология, как система мифов и мифических представлений, возникает как попытка человека объяснить непознаваемое, обусловленное природой, человеческими действиями или непонятными явлениями.

Согласно Ш.С. Сафарову, когнитивная лингвистика акцентирует внимание на роли языка в формировании знаний о мире. Язык воспринимается как инструмент познания действительности, и анализ смысла, его формирование и эволюция получают особое значение. Это отношение к языку позволяет исследователям понимать, как язык отражает мировоззрение, включая мифологические представления [Сафаров 2015: 27].

Приведенный пример с фразеологизмами на каракалпакском языке («kók tigilsin», «kók kiygan», «egnida kóki bor», «ustida kóki bor») показывает, как через языковые единицы и фразеологизмы выражаются сложные концепции, такие как скорбь, траур, удивление и проклятие. Эти фразеологизмы отражают культурные аспекты и отношение к непостижимым событиям и переживаниям, влияя на лингвистическое выражение мышления.

Исследования, проведенные в этом направлении, позволяют глубже понимать влияние языка на наше восприятие мира, а также влияние мифологического мышления на формирование языковых конструкций и выражений. Это важно как для лингвистов, так и для культурологов, изучающих различные аспекты человеческой культуры и социума.

Изучение мифологии с точки зрения языкознания позволяет рассматривать мифы как «особое состояние языка». Изначально человек, изучая окружающий мир и жизнь, ассоциировал определенные понятия с природой. Однако со временем эти ассоциации и правила были забыты, и выражения начали употребляться в переносном смысле.

Анализ фразеологических единиц, связанных с мифологическими концептами, позволяет выявить антропоцентрический характер мифологической единицы «star» (звезда). Это подчеркивает важность рассмотрения языковых конструкций через призму мифологической картины мира, в которой звезды могут быть символами или иметь определенные значения.

Мифологическая картина мира, как указывает Р.С. Халимулина, представляет собой сложное мировоззрение, объединяющее различные аспекты, включая воображение и реальность, сверхъестественное и естественное. Языковая картина мира, в свою очередь, создается с использованием различных языковых средств, таких как мифологемы, метафоры, сравнения, символы и другие.

Таким образом, язык отражает не только сами концепции мифологии, но и способы, которыми человек взаимодействует с миром вокруг себя, ассоциируя и переосмысляя его через призму мифологических

представлений. Это влияет на формирование языковых конструкций и выражений, а также на культурное понимание и восприятие мира.

Из данного обобщения видно, что архетипы встречаются в текстах не случайно, а обусловлены бессознательным уровнем предметной, исторической, художественной и праксиологической памяти сообщества. Архетипы являются универсальными символическими образами, насыщенными золотым опытом человечества, которые авторы воспроизводят и формируют в своих произведениях.

Пример с образом «Qumar analıq» в произведении Т. Кайыпбергенова демонстрирует, как автор использует архетип матери, присущий культуре каракалпакского народа. Он трансформирует этот архетип, адаптируя его под специфику и особенности своего произведения, и тем самым создает уникальный образ, который воспринимается в контексте каракалпакской культуры.

Кроме того, пример с архетипом «Уммай анна» и его трансформацией в «Кумар аналық» в мифах и легендах также показывает, как архетипы могут эволюционировать и приспосабливаться к изменяющимся социокультурным условиям, сохраняя при этом свою основную семантику и значение.

Таким образом, архетипы играют важную роль в формировании культурных концепций и мифологических представлений, а их анализ в текстах позволяет понимать глубинные культурные особенности и трансформации в различных культурных контекстах.

ЛИТЕРАТУРА

Алефиренко Н.Ф. Современные проблемы науки о языке. – М.: Флинта, 2005. – 412 с.

Дейк Т.А. ван. Язык. Познание. Коммуникация: пер. с англ. / сост. В.В. Петрова. – М., 1989. – 312 с.

Dijk, T.A. van. Discourse, ideologyandcontext // FoliaLinguistica. 2001. № 35 (1-2). – P. 11-40.

Кубрякова Е.С. О понятиях дискурса и дискурсивного анализа в современной лингвистике (Обзор) // Дискурс, речь, речевая деятельность: функциональные и структурные аспекты: Сборник обзоров. – М.: РАН ИНИОН, 2000. – С. 7-25.

Сафаров Ш.С. Онг когнитив-дискурсив фаолият манбаси сифатида // Хорижий филология. – Самарқанд: СамЧТИ. – 2015. – № 3. – Б. 26-33.

УДК 373.51

Кириллова Зоя Николаевна,
Казан федераль университеты

М. Корбангалиевның урта мәктәп өчен татар теле дәреслекләре

М. Корбангалиев, татар теле, дәреслек, урта мәктәп

Мөхетдин Корбангалиев – XX гасырның беренче яртысында күренекле галим, педагог, күп санлы дәреслекләр авторы буларак танылган шәхес. Ул математика, география дәреслекләре, башлангыч мәктәпләр өчен әлифбалар төзи. Шулай да аның тарафыннан бастырып чыгарылган дәреслекләрнең күпчелеге татар телен чит тел буларак укытуга багышлана. Бу юнәлештә ул башлангыч сыйныфлар, урта мәктәп һәм вузлар өчен, ягъни телне төрле дәрәҗәдә белүчеләргә атап дәреслекләр эшли. Моннан тыш, татар телен читтән торып үзлектән өйрәнүчеләр өчен дә кулланмалары дөнья күрә.

М. Корбангалиев урта мәктәпнең 5-7 сыйныфлары өчен 1927-1934 елларда үзе генә яки Риза Газизов белән бергә «татарлардан башкалар өчен» яки «руслар өчен» дип аерып билгеләнгән татар теле дәреслекләре бастырып чыгара.

М. Корбангалиевның урта мәктәпләр өчен төзелгән татар теле дәреслекләре хәтта урта махсус белем бирү һәм югары уку йортларында да кулланыла. Дәреслекләр җитмәү сәбәпле, ТАССР Мәгариф комиссариаты да моны тәкъдим итә, нәтиҗәдә дәреслекләр алдан ук шундый максатка яраклы итеп төзелә.

Дәреслекләрдә татар булмаганнарны укырга һәм язарга өйрәтүгә, сөйләм телләрен үстерүгә, шулай ук грамматика һәм орфографиядән мәгълүматлар бирүгә дә игътибар юнәлтелә. Дәреслекләрнең төзелеше нигездә охшаш, бары тел материалы һәр сыйныф саен катлаулана бара, яңа сүз һәм формалар өстәлә, грамматикадан мәгълүматлар да зурая.

5 сыйныф укучылары һәм зурлар курслары өчен төзелгән һәм 1928 елда басылып чыккан «Руслар өчен татар теле дәреслеге»ндә аның нинди методик принциплардан чыгып төзелүе һәм дәресләрне ничек алып барырга кирәклеге хакында тәкъдимнәр дә урын ала: «Безнең дәреслек төзелешенең төп методик принцибы булып комплекслылык һәм тематик берлек санала: башта һәрбер дәрес эчтәлегенә кергән яңа

сүзләрне, яңа форма һәм әйләнмәләрне үзләштерү өчен, җанлы сөйләшү дәресләре алып барыла; аннан соң әлеге яңа һәм укучыларга инде таныш булган сүзләрдән төзелгән аерым фразаларны, тәгәлләнгән мәкаләләрне уку; сораулар ярдәмендә һәм сораусыз укыганны сөйләп бирү; затны яки бер заманны икенчесе белән алыштырып сөйләү; аннан соң грамматик һәм орфографик нәтиҗәләр һәм, укучылар үзләре чыгарган кагыйдәләрне тагын да тирәнрәк үзләштерсен өчен, язма һәм телдән күнегүләр; татар теленнән рус теленә һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәр өчен биремнәр тәкъдим ителә» [Корбангалиев1928: II-III].

Һәр дәреслектә диярлек башта сөйләшү уздыру максатында рәсемнәр бирелә, аннары сүзләр һәм алар белән кыска гыйбарәләр урын ала. Мәсәлән, М. Корбангалиев һәм Р. Газиз тарафыннан II баскыч мәктәпләрнең 5 нче елы өчен төзелгән дәреслекнең беренче битендә журнал, барабан, абажур, бур рәсемнәре төшерелеп, асларына шул сүзләр язылган һәм әлеге сүзләр кергән фразалар урнаштырылган: *Бу – журнал. Бу – бур* һ.б. Татарча һәм русча вариантта шул сүзләрне төзи торган хәрефләр бирелгән. Моннан соң теге яки бу хәрефне ничек язу турында русча нәтиҗә чыгарылган һәм иң соңыннан күнегү бирелгән: *Урал, буран, ура, жарһ.б. сүзләрне татар хәрефләре белән күчереп язарга һәм укырга* [Корбангалиев 1928: 7-8].

Дәреслектә материалның шундый тәртиптә бирелүеннән татар телендә укырга һәм язарга өйрәтү, укучылар арасында сөйләшү уздыру һәм грамматик мәгълүматны бергә бәйләп алып барырга кирәклек аңлашыла.

Дәреслектә, үткән материалны ныгыту өчен, күп санлы күнегүләр дә тәкъдим ителә. Аларның эчтәлеге дә төрле: исемнәрне берлек саннан күплеккә әйләндерү, фигыльләрнең заманын яки затын үзгәртеп язу һәм сөйләү, сүзләрнең башлангыч формаларын табып язу, татар теленнән русчага яки киресенчә тәрҗемә итеп язу яки сөйләү, җөмләләрдә төшеп калган сүзләрне табып язу һ.б.

Дәреслек авторлары күрсәткәнчә, барлык эш төрләре үзара комплекс тәшкил итә: «<...> мондый комплекслылык вакытында бер үк сүзләр бер үк вакытта төрле эш формаларында очрыйлар һәм шул сәбәпле хәтердә яхшырак калалар; шулай ук алар үле хәлдә, аерым кисемтә рәвешендә түгел, ә динамикада башка сүзләр белән төрле бәйләнештә истә калалар, шул ук вакытта комплекслылык, әлбәттә, кирәк булганда укучыларның игътибарын төрле эш моментларына

юнәлдерергә: әле сөйләмне үстерү, әле лексика яки орфография буенча тирәнрәк эшләргә мөмкинлек калдыра» [Корбангалиев 1928: III].

Дәреслекнең беренче басмасында дәрес башында текстларга кергән һәр яңа сүзнең тәрҗемәсе бирелгән булса, икенче басмасында инде андый тәрҗемәләр урын алмый, һәрбер сүз дәреснең номеры белән дәреслек азагына урнаштырыла, чөнки элеккеге бирелештә укучылар татар сүзләренә караганда рус сүзләренә күбрәк игътибар иткәннәр, бу исә татар сүзләрен үзләштерергә комачаулаган [Корбангалиев 1928: III].

1928 елда әлеге дәреслек гарәп шрифтында бастырылып, дәреслек ахырында гына танышу өчен латин шрифты һәм 6 текст бирелсә, аннан соң чыккан дәреслекләр инде латин шрифтына нигезләнә [Кириллова 2016: 307].

1928 елгы дәреслекнең дәвамы сыйфатында икенче елда 6 сыйныф өчен 2 кисәктән торган татар теле дәреслеге басылып чыга [Корбангалиев 1929]. Әлеге дәреслектә материал төрле яклап катлауландырыла, укучыларның яшь үзенчәлекләренә, гомуми белем һәм татар телен белү дәрәҗәләренә карап сайлана. Күнегүләрнең укучыларны ныклап уйлатырлык итеп төзелгән булуы күзгә ташлана.

М. Корбангалиев һәм Р. Газиз тарафыннан әлеге дәреслекләр кайбер үзгәрешләр белән 5 һәм 6 сыйныф укучылары өчен 1931 елда да бастырып чыгарылалар [Корбангалиев 1931].

М. Корбангалиев 1933-1934 елларда үзе генә дәреслекләр төзеп бастыра. Мисал өчен, 1933 елда ул «Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен. 5-уку елы өчен» исеме белән, ә 1934 елда исә 5-6 һәм 7-8 сыйныфлар өчен дәреслекләр чыгара. Аларның эчтәлеге нигездә бер төрле: беренче өлештә һәрбер дәрестә текст, грамматик (морфология һәм синтаксис буенча) материал, рус телендә кагыйдә яки аңлатма, соңыннан биремнәр бирелә, ә икенче өлештә кайбер татар әдипләре турында кыскача мәгълүмат, әсәрләреннән өзекләр китерелә. Әдәби әсәр үрнәгеннән соң авыррак сүз яки сүзтезмә, аерым очракларда җөмләләр дә рус теленә тәрҗемә итеп бирелә.

М. Корбангалиевның 1934 елда чыккан 7-8 сыйныфлар өчен дәреслегендә фонетика, морфология, синтаксис, татар һәм тәрҗемә әдәбият үрнәкләре аерым бүлекләр рәвешендә төркемләнгән.

Фонетика бүлегендәге материалдан күренгәнчә, укытучы бөтен курс дәвамында татар авазларының дөрес әйтелешенә зур игътибар бирергә тиеш.

Морфологиягә һәм синтаксисны өйрәтүгә багышланган бүлекләрдә татар теленең грамматик үзенчәлекләре рус формалары белән чагыштырып өйрәтелә. Авторның күрсәтүе буенча, «грамматика дәресләре сөйләм телен үстерү белән бәйләнеп барырга тиеш; дәреслектә текстлар рәвешендә һәм күнегүләр өчен конкрет сөйләм материалы алынды» [Корбангалиев 1934, 4-кисәк: 3].

Татар һәм тәрҗемә әдәбият үрнәкләренә багышланган соңгы бүлектә исә әдәби әсәрләрдән алынган өзекләр укучыларны әдәбият белән таныштыру максатында гына түгел, гади җөмлә һәм кушма җөмлә синтаксисын өйрәнгән вакытта файдалану өчен дә тәкъдим ителә.

Йомгак ясап әйткәндә, 1920-1930 нчы елларда М. Корбангалиевның Р. Газиз һ.б. белән берлектә яки үзе генә чыгарган руслар өчен татар теле дәреслекләре зур уңыш казана. Аның тарафыннан урта мәктәп өчен әзерләнгән татар теле дәреслекләрендә, башлангыч мәктәпләр белән чагыштырганда, эшләү системасы һәм төрләре киңәя: грамматикадан мәгълүматлар күбәя бара, шулай ук укучыларның сөйләм телен үстерү, аларның татар теленнән сүзлек запасын арттыру юнәлешендәге эш төрләренә дә зур урын бирелә.

Мәкалә «Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр» фәнни белем бирү үзәге кысаларында язылды.

ӘДӘБИЯТ

Кириллова З.Н. Узган гасырның 20-30 нчы елларында русларга татар теле өйрәтү // Филология в полиэтнической и межконфессиональной среде: состояние и перспективы. Сборник научных статей. – Выпуск 6. – Казань: РИИ, 2016. – С. 290-310.

Кириллова З.Н. Яңа мәктәп һәм ана теленең роле (1920 нче еллар «Мәгариф» журналы буенча) // Язык в контексте межкультурных и национальных взаимосвязей: Материалы VI Международной научно-практической конференции (29-30 апреля 2016 г.). – Казань: КГМУ, 2016. – С. 90-97.

Кириллова З.Н. Русларга татар телен укыту чаралары (1920-1930 нчы еллар тәҗрибәсеннән) // Язык в контексте межкультурных и национальных взаимосвязей: Материалы VII Международной научно-практической конференции (25 мая 2017 г.) / под ред. Л.И. Фидаевой, А.Г. Евдокимовой, В.Т. Балтаевой. – Казань: КГМУ, 2017. – Б. 113-125.

Корбангалиев М. Руслар өчен татар теле дәреслеге. 1-кисәк. 2-баскыч мәктәпләрнең 5-сыйныфлары һәм зурлар курслары өчен. – Казан: Татиздат, 1928. – 148 б.

Корбангалиев М., Газизов Р. Руслар өчен татар теле дәреслеге. Беренче кисәк. II баскыч мәктәпләрнең 5 нче елы өчен. 3 нче басма. – Казан: Татиздат, 1929. – 80 б.

Корбангалиев М., Газизов Р. Руслар өчен татар теле дәреслеге. 2 нче кисәк. II баскыч мәктәпләрнең 6 нчы группалары өчен. – Казан: Татиздат, 1929. – 88 б.

Корбангалиев М., Газизов Р. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен. Беренче кисәк. 5 нче уку елы өчен. – Казан: Татгосиздат, 1931. – 111 б.

Корбангалиев М., Газизов Р. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен. Икенче кисәк. 6 нчы уку елы өчен. – Казан: Татиздат, 1931. – 123 б.

Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен. 5-уку елы өчен. – Казан: Татгосиздат, 1933. – 183 б.

Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен. 4-кисәк. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 325 б.

УДК 851.51

Ktaybekova Zulfiya Kengesbayevna,
Nukus State Pedagogical Institute named after Ajiniyaz

Artistic use of vulgarisms in A. Atajanov's stories

story, vulgarisms, plot, character, writer, psychology

Vulgarisms are used by writers to reveal the psychology of the characters in a work of fiction, especially when depicting their unpleasant qualities. Also, from the words of the characters, curses and humiliating statements of the hero about others are given.

This original work reveals the characteristic features of arrogance, arrogance, lack of culture, and uncertainty of the heroes. However, more frequent use of such words may reduce the artistic value of the work. Therefore, the correct use of vulgarisms requires artistic skill from the writer. In the work you can see the effective use of vulgarisms in the speech of different categories of people in the lives of the heroes.

Vulgarism (lat. vulgaris – from the word rude) – vulgar words not used in the literary language, non-compliance with language norms, incorrectly constructed lines. Dictionaries define that authors skillfully use vulgarisms to depict the rudeness of various characters and the insipidness of unpleasant images [Hotamov 1979: 69].

The famous Karakalpak writer Abdimurat Atajanov used vulgarisms in his works to depict the events of everyday life, family problems, and reveal

the behavior and character of the characters. It can be seen that the writer used the language of the characters in order to express the thoughts of the heroes in the story «Iza».

The events in the story are taken from the life of old Dilmurat. The head of the district Joldasbai followed his uncle's words and said that Dilmurat's house near the river the mouth of the «Abat» must be vacated.

At the same time, he expressed his dissatisfaction and returned to the boss with the words that came to his mind.

«– Wáy, atańa ǵana **nálet (damn),** shıǵarıp bolıpsań» [Atajanov 2020: 132].

- Uyine barǵan soń da ǵarrınıń ashıwı tarqamay, óz-ózinen gúbirlenip júredi. «Jaydı bosat deydi - á, **náletiy (damn).** Al, bosatpaǵanım» [Atajanov 2020: 133].

Sonda da sózi shımbayıńa batadı eken, **shappattay júwernemektiń (little bastard)** [Atajanov 2020: 133].

– Ishi dútke tolǵan **aqımaq…(stupid)** [Atajanov 2020: 136].

In these examples, the writer skillfully presented that Dilmurat's inner anger and emotions did not fade away. Old Dilmurat, who owned the channel for 6 years, was in no mood for a couple of days. Sensing that her husband was angry about something, the old lady was shocked when she heard that she would have to leave the place. When the older says that the melon is to blame:

– Ne deydi mına, **aljıǵan (old aged).** Usı seni jin qaǵıp ketpese bolǵanı ǵoy… [Atajanov 2020: 137] deydi

– **Mushtay ǵana júўernemek (little bastard)** tınba suўday tımsırayıp júre bergen eken-dá. Qam túynek penen-aq **mushtay sarı qırshınnıń (little cub)** kóńlin kenshiter ediń [Atajanov 2020: 138].

– Ol **ırıldaǵan iytti (growling dog)**, bir dámiktirseń qır sońıńnan qalmaydı [Atajanov 2020: 138].

– Qoysań – á **sampıldıńdı (chatter)!** [Atajanov 2020: 138].

The dialogue between the two characters in these examples conveys that they are angry and dissatisfied with someone through the writer's use of vulgar words.

Vulgarisms can only be used in the language of characters in a work to show its character and general extent [Akhmetov 1972: 38].

The writer A. Atajanov very productively used vulgarisms based on the monologues and dialogues of the characters.

«Rasında da, Joldasbay qaўın bermegeni ushın jón-josaǵın aytpastan ǵarrıdan jaydı bosatıўdı talap etedi:

– Háy, sen… **chort ǵarrı (devil oldman)**! – dep Joldasbay papkasın sart ettirip japtı. – Xojayın sen be, ya men be? Ornıńa adam tayın».

The above examples show the arrogance and haughtiness of the head of the district, Joldasbai. Delighted that the water has arrived in the canal, the old man hurries to tell the leaders this good news. When he returned without finding the leaders, he saw the slate roof of the house:

«Usı bala ol ǵana **jalmawızdıń (scumbag)** kelip ketkenine neshe kún boldı?

– He continues talking to himself, not wanting to even say his head's name. A car followed him along the road, the district secretary and Joldasbai stopped and got into a car. Old man Dilmurat did not like the fact that he was repeatedly persuaded by Joldasbai not to inform the secretary about his guilt:

–Túrtinbey otır, qolıńnıń **wadwasılı (hand itches, twitch)** bar ma? – dep jekirinedi ǵarrı» [Hotamov 1979: 141].

…Ayırım **teris ayaqlar (arrogant person)** tabıladı [Hotamov 1979: 141].

Based on this, it is not difficult to see that even the secretary knows about Joldasbai's arrogance. …gáptiń hadalı, kimge bolsa da óz miynetiniń jemisi pal. Onı geybir **shalabaslar (slods)** uqpaydı [Hotamov 1979: 145].

The old man means those people who cannot work and who do not want to work. After this meeting, Joldasbai said to the old man and left: Ata, jıllı ornıńdı suўıtpay otıra ber…

The frankness and hot-tempered nature of the elderly man in the story are very skillfully conveyed by the writer in a figurative and emotional form through his words. It is shown that the writer has his own style in choosing words and describing typical folk life.

Of course, a writer must be able to choose artistic words in order to create effective language in a work. In conclusion, vulgarisms used in the work of the writer A. Atajanov represent one of the important problems awaiting study today.

REFERENCE

Akhmetov S. A short dictionary of literary terms. – Nukus: Karakalpakstan, 1972. – 148 p.

Atajanov A. Sapalaq paluan. Narrative and stories. – Nukus: Karakalpakstan, 2020. – P. 132-186.

Hotamov N., Sarimsakov B. Russian-Uzbek explanatory dictionary of literary terms. – Tashkent: O'qituvchi, 1979. – 361 p.

УДК 811.512.145

Кузьмина Халисә Хатиповна,
Казан федераль университеты

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә фонетик сурәтләү чарасы буларак аллитерация кулланышы

«Кыйссаи Йосыф» әсәре, аллитерация, фонетик стилистика

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы – Идел буенда язылган беренче зур күләмле төрки шигъри әсәр булып тора. Шигырь – билгеле бер ритмга корылган тәэсирле сөйләм. Иҗек санының һәм гадәттә цезураларның (силлабикада) яки озын һәм кыска иҗекләрнең (арузда) теге яки бу рәвештә кабатланып килүе сөйләмгә үзенә күрә бер яңгыраш – ритмлылык бирә.

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең шигъри төзелеше турындагы язмаларда Хатыйп Госман, Хәлиф Курбатов кебек күренекле галимнәр аның үзенчәлекле ритм белән язылганын искәртәләр.

Хатыйп Госман Кол Гали чорында ук шигъри әсәрләрне *шигырьгә* һәм *нәзымга* (шигъри сөйләмгә) бүлү булганлыгы турында яза һәм нәзымның стиле гадирәк булуын, катлаулы метафоралар һәм чагыштыруларның булмавын, сөйләп бирүгә корылган күрсәтә [Поэт 1987: 175]. Кол Гали мондый стильне кабул итеп алса да, аның әсәре нәзым – сөйләм бирүгә корылса да, тел-стиль чараларының искиткеч бай кулланылуы «Кыйссаи Йосыф»ны төрки шигърияттә аерым мөнбәргә куя.

«Кыйссаи Йосыф» строфаның һәр юлы 12 иҗектән торган, һәр дүрт иҗектән соң цезура кулланылган вәзен-үлчәм – робагый һәм нәзым белән язылган [Усманов 1987: 177]. Бу, беренчедән, шигырьнең катгый ритмик буыннарын барлыкка китерә, икенчедән, ятлау, нәзым жанрына хас булганча, истә калдыру һәм көйгә салып (көйләп) уку өчен уңайлы. Ритмик буыннарның камиллеген тәэмин итү өчен, шагыйрь төрле фонетик сурәтләү чараларына, шул исәптән аллитерация алымына мөрәҗәгать итә.

Аллитерация – сүзләрдә бер үк тартык авазны кабатлауга нигезләнгән стилистик фигура. Аллитерация шигърияттә дә, прозада да билгеле бер идеяләрне ассызыклау, укучыга эмоциональ йогынтыны көчәйтү яки текстның билгеле бер моментларына игътибарын җәлеп итү,

сөйләмнең аһәңлелеген, ритмын һәм эффектлылыгын булдыру өчен кулланыла. Традицион алым буларак, аллитерация аеруча поэтик сөйләмдә яки халык авыз иҗатының кайбер жанрларында зур урын ала [Хаков 1999: 168].

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең стилистик яктан үзенчәлеге шунда: әсәрнең телендә аерым бер сурәтләү чарасын гына аерып алу кыен; гадәттә, автор сурәт барлыкка китергәндә төрле сурәтләү чараларының кушылмасыннан файдалана [Кузьмина 1998: 160]. Мәсәлән, *Zöläjxa ol sözläri hich aӊlamaz, / Jusuf pändin dyӊlamaz, räua körməz,/ aӊa laiq kälächi söz sözlämäz,— /kändi sözin möqärrär sűjlär imdi* [Кол Гали 1987: 160].

Әлеге строфаның беренче өч юлы [з] авазына тәмамлана һәм ул аваз хикәя фигыльнең юклык формасы составында килә, ягъни аллитерация алымы грамматик стилистика алымы белән кушылып китә. Гомумән, мондый күренеш әсәрдә шактый еш кулланылган сурәтләү алымнарының берсе: *Jusuf dүshin anlara əjtű virməz,/ ata qäulin buzmağa räua körmäz, / jujudubän jalan söz häm sözlämäz, — / xäjran ulub, ğäҗäibə қalur imdi* [Кол Гали 1987: 54].

Әлеге очракта аллитерация ассонанс алымы белән синтез буларак бирелгән. Бу үзенчәлек, иң беренче чиратта, авторның ритмны тоя алырлык һәм аны сүзләр эчендә куллана алырлык дәрәҗәдә камил музыкаль сәләте булуын ачык күрсәтеп тора.

[з] авазының кабатлануына нигезләнгән аллитерация түбәндәге мисалда чагылыш таба:

Anlar äjdűr: “Bizlär däği bilűmäziz, / uқub sizä hich җäwab virűmäziz, / bu betidä datlu söz bulumazyz, / jaulaq dishvar betidir”, dirlər imdi [Кол Гали 1987: 262].

Бу очракта [з] авазына нигезләнгән аллитерация барлыкка килсен өчен, автор махсус грамматик форма кулланган яки бу форманы үзе ясаган булырга мөмкин: *билүмәзиз* сүзендә *билүмәз+из* (белмәс+без) киселгән грамматик форма күренә.

Алдагы мисалларда шул ук рәвешле [н], [т], [ш] авазларының кабатланып килүен күрәбез.

Jusuf säүchi qyjssasyn qyjlduқ ğäjan,/ ğäräb, ğäҗäm dilinchä qyjlduқ bäjan, / uqumağa, dyӊlamağa oldy asan, / uqyjanlar doğa ilə űksűn imdi [Кол Гали 1987: 292].

Әлеге строфада *гәйан* һәм*бәйан* сүзләреүзара рифма барлыкка китерүдән тыш, сүз азагында [н] авазының, ә строфа текстында тагы

өстәмә рәвештә [ғ] авазының да кабатланып килүе үзенчәлекле ритм барлыкка китерә.

űmiddyr-kim, mäүlya säңa virä műlkәt, / fazly birlä ruzi qyjla űkűsh niğmät, / qärdäshläriң ʒűmläsi qyjla xezmät, / on birisi säңa xezmät qyjla imdi [Кол Гали 1987: 52].

Әлеге юлларның азагында [т] авазы аллитерация барлыкка китерә, шуңа өстәмә рәвештә, *қыйла* сүзенең дә өч тапкыр кабатлануын күзәтәбез.

Qärdäshiңiz Jusuf [däjүr] bir dűsh körmish, / aj, kűn, on bir julduz aңa säʒdä qylmysh, / ataңyz Jağqub any izgű jurmysh, – / bәn ishitdűm, izgű täevil qyldy imdi [Кол Гали 1987: 54].

Әлеге мисалда өрелмәле саңгырау [ш] авазы үткән заман хикәя фигыльнең угыз формасы составында килеп, аллитерация барлыкка китерә. *Қәрдәшиңиз, дүш, ишитдүм* сүзләрендә дә [ш] авазы кабатлана.

[й] авазының кабатланып килүе үзенчәлекле яңгыраш барлыкка китерә: *Jarly Jusuf janlaryncha jäjän jäldi* [Кол Гали 1987: 62].

Йосыф үзе янында энесе Ибне-Йәминне алып калыр өчен, хәйлә корырга мәҗбүр. Әлеге ситуациядә Йосыф сөйләмендә [с] авазы нигезендә ясалган аллитерация кулланыла: *Bän säniң jűkűңdä bir sağ qujam,/ sağ buluban, bäs, säni oğryj dijäm* [Кол Гали 1987: 248].

[к] һәм [г] авазларының кабатланып килүе нигезендә ясалган аллитерация дә строфаның мәгънәсен тулырак ачып бирү һәм ритм барлыкка китерү өчен кулланыла: *Kűreklű jűzlär käfen saryb gűrgä kirsä, / űkűsh däğűl, gűr ichindä űch kűn dursa, / qanqyj dust gűr ichindä any körsä, / körmäs űchűn jűz dűndűrűb qachar imdi* [Кол Гали 1987: 162]. Әлеге юлларда [к], [г] авазлары *күз, күрү, күрекле* лексемаларының мәгънәләрен көчәйтеп киләләр һәм кабатлану юлы белән аллитерация барлыкка китерәләр.

Алдагы юлларда [қ] авазының аллитерация сурәтләү алымын ясавын күрәбез, әмма бу очракта мәгънә үзенчәлеге башка төрле:

Jusuf äjdűr: “Imdi bawär qyldyңyzmu, / sağ chyңyrab, nä didikin bildikizmű, / Jusufa nä qyldyqyңyz aңdyqyzmu?” – / Nä-char ulub, ʒűmlä iqrar qylur imdi [Кол Гали 1987: 264]

Бу очракта Йосыф агаларына каты итеп, кычкырып эндәшә, ул аларның үзен саткандагы ялганын фаш итәргә тели. Әмма агалары үзләре эшләгән явызлыкны танымыйлар, кире кагып, баш тарталар, шул

сәбәпле Йосыф та ярсый башлый. Әлеге эмоциональ киеренкелекне тасвирлау өчен Кол Гали увуляр тартык файдалана.

Боерык төсмере – императив – Йосыфның бертуган энесе Ибне-Йәмингә эндәшүендә дә күренә: *Jusuf äjdűr: "Ağlamağyl, jigil ashyŋ, / imdi qujğyl, ağyzmağyl köziŋ jäshin* [Кол Гали 1987: 248]. Бу юлларда Кол Гали императив мәгънәсен белдерү өчен грамматик форманы *–ғыл/-гил* кушымчасын файдалана, һәм аның составындагы [ғ] авазының еш кабатлануы авторга кирәкле булган катылык, боерык мәгънәсен белдерүгә ярдәм итә.

Аерым очракларда калган авазлардан [р] авазы (*Färeshtälär äjdyr: "ägär kirär irsäŋ* [Кол Гали 1987: 282]), [б] авазы *(bir biläzik ol bäŋa bağyshlady* [Кол Гали 1987: 236]; *Tulun ajğa biŋzär irdi biŋziŋ nəqshi* [ФК: 218]) һәм башка авазлар аллитерация барлыкка китерәләр. Шулай да, тартык авазлар арасыннан [қ] авазының аллитерация барлыкка китерү мөмкинлеге башкаларга караганда зуррак, ягъни Кол Гали тартыклар арасыннан күбрәк [қ] авазы нигезендә сурәт ясый.

Шул рәвешле, «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә аллитерация иң еш кулланыла торган фонетик сурәтләү чараларының берсе булып тора һәм әсәрдә ул башка сурәтләү алымнары белән бергә үрелеп килә. Әсәр телендә иң еш кабатлана торган тартык авазлар – [з], [с], [н], [т], [ш], [к], [қ], [г], [ғ], [д] авазлары. Әлеге авазларның аллитерация күренешен барлыкка китерүе нәтиҗәсендә ритмик буыннарның аһәңлелеге барлыкка килә, сөйләм көе оеша һәм әсәрнең укучыга тәэсир итү көче арта.

ӘДӘБИЯТ

Кол Гали. Кыйссаи Йосыф / Төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кулъязмаларның тасвирламасын ясаучы филология фәннәре кандидаты Ф.С. Фәсиев. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1983. – 542 б.

Кузьмина Х.Х. Лексико-семантические и стилистические особенности поэмы XIII века «Кысса-и Йусуф» Кул Гали: дисс. ... канд. филол. н.: 10.02.06. – Казань, 1998. – 177 с.

Поэт-гуманист Кул Гали. Сб. ст. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – 264 с.

Усманов Х.У. Вклад Кул Гали в развитие тюркского стиха. Сб. статей / Поэт-гуманист Кул Гали. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – 264 с.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле (Стилистика). – Казан: Тат. кит. нәшр., 1999. – 304 б.

УДК 811.512

Меметов Искәндәр Айдер улы,
В.И. Вернадский исемендәге Кырым федераль университеты
Усманова Миңсылу Гөбәйт кызы,
М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университеты
Нәсипов Илшат Сәхиятулла улы,
М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университеты
Экба Зарема Назир кызы,
Россия Фәннәр академиясе Тел белеме институты

Халкының лаеклы кызы
(Профессор Х.Ч. Алишинага 70 яшь тулу уңаеннан)

Халисә Алишина, Төмән, тел, галимә, тарих

Хәнисә Чәүдәт кызы Алишина Төмән дәүләт университетының дәүләт имтихан комиссиясе тәкъдиме буенча һәм Казан университеты профессоры Д.Г. Тумашева чакыруы белән 1988 елда КДУның көндезге аспирантурасына «Төрки телләр» юнәлеше буенча укырга керә. 1992 елда Казан дәүләт университетының татар тарихы, филологиясе һәм көнчыгыш телләре факультетының диссертация советында «Төмән өлкәсенең көньягындагы себер татарлары сөйләмнәре» дигән кандидатлык диссертациясен, 1999 елда «Себер татарларының ономастиконын тарихи-лингвистик тикшерү (Төмән өлкәсе материалында)» дигән докторлык диссертациясен яклый.

Аспирантураны тәмамлаганнан соң, ТР фәннәр академиясендә эшли. Бер елдан соң Төмән дәүләт университеты ректоры, философия фәннәре докторы, профессор, Россия мәгариф академиясе академигы Г.Ф. Куцев чакыруы буенча, Х.Ч. Алишина Төмәнгә филология факультетында төрки белгечлек ачу өчен күчерелә.

Филология фәннәре докторы, Төмән дәүләт университеты профессоры Х.Ч. Алишина соңгы елларда себер татарларының теле, фольклоры, әдәбияты буенча күпкырлы фәнни тикшеренүләр алып бара, «Төмән өлкәсендә татар телен, мәдәниятен, традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү» дигән зур фәнни проект өстендә эшли. Татар тел белеменең теоретик һәм гамәли аспектлары буенча төп фәнни нәтиҗәләр монографияләрдә, җыентыкларда, мәкаләләрдә, шул

исәптән «Scopus» һәм «Web of Science» халыкара мәгълүмат базалары индексацияләгән гуманитар һәм социаль фәннәр буенча журналларда бәян ителгән. «Себер татарларының ономастиконы», «Себер татарларының Тубыл-Иртеш диалекты» монографияләре, «Россия фәнни цитаталар индексы» мәгълүматлары буенча югары цитаталар индексына ия.

Хәнисә Чәүдәт кызы Алишина хәзерге вакытта себер татарлары теле һәм аның диалектлары буенча иң зур белгечләрнең берсе булып тора. Ул бөтен гомерен төрки филологиясенә һәм шуның белән бәйле социолингвистика, педагогика, фольклористика, әдәбият белеме, тарих мәсьәләләренә багышлый. Төмән дәүләт университетында бүгенге көндә бик кирәкле библиометрик һәм фәнни-метрик күзәтүләр гомумиләштерелгән. Аның фәнни хезмәтләре турында Төмән дәүләт университетының әйдәп баручы галимнәрен тәкъдим итүче «Docti primarii universitatis Tjumeniensis» биобиблиографик күрсәткечләр сериясендә 2013 елда төзелгән һәм тюркология, себер татарлары диалектологиясе өлкәсендәге белгеч, ТР Фәннәр академиясе академигы Д.Г. Тумашеваның укучысы һәм фәнни идеяләре дәвамчысы профессор Х.Ч. Алишинага багышланган махсус чыгарылыш дөнья күрә.

2021 елда «Университет в лицах» сериясендә «Ханиса Чавдатовна Алишина: биобиблиографик указатель» китабы басылып чыга. Анда 1039 библиографик берәмлек бар, шуларның 355 е фәнни, укыту-методик һәм публицистик хезмәтләр, 347 се газета мәкаләләре һәм Төмән дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге профессоры Х.Ч. Алишина турында 317 басма. Хронологик яктан 40 елдан артык вакытны колачлый. Монда монографияләр, укыту һәм методик әсбаплар, фәнни җыентыкларда һәм журналлардагы мәкаләләр генә түгел, ә татар язучыларының әдәби әсәрләрен тәрҗемә итү, татар иҗтимагый-сәяси һәм әдәби журналларында һәм газеталарында публицистика, шулай ук иң мөһим кульязма хезмәтләр – РФА иҗтимагый фәннәр буенча фәнни мәгълүмат институты китапханәсендә саклана торган депонирланган эшләр, кульязма хәлендә сакланган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренең авторефератлары да исәпкә алынган. Татарстанда, Төмәндә, Үзәк Азия республикаларында, Идел буе һәм Себер тюркология үзәкләрендә чыга торган күп санлы фәнни һәм публицистик вакытлы басмаларда татар телендә басылганнары аерым колорит бирә.

Х.Ч. Алишинаның 20 томлык «Күренекле кешеләр тормышы» дигән китаплар сериясен без «татар халкының кешеләр турындагы уникаль тарихы» дип саныйбыз. Татар тел белеменең теоретик аспектлары буенча төп фәнни нәтиҗәләр югары фәнни дәрәҗәдә башкарылган 6 монографиядә, 10 диссертациядә, 700 дән артык мәкаләдә һәм басмада, шул исәптән гуманитар һәм социаль фәннәр өчен Scopus, Web of Science журналларында язылган.

Х.Ч. Алишинаның «Себер татарларының ономастиконы (Төмән өлкәсе материалында)» монографиясе күп цитаталанган эш дип танылган, ул «Россия фәнни цитаталар индексы» мәгълүматлары буенча, барлык елларда әлеге фәнни юнәлеш буенча иң яхшы 10% басмалар исәбенә керә. Аннан соң Хәнисә Чәүдәт кызының иң күп цитаталар китерелгән хезмәтләре арасында «Себер татарлары теленең Тубыл-Иртеш диалекты» монографиясен һәм «Көнбатыш Себер татарлары тарихы һәм мәдәнияте» коллектив монографиясен билгеләп үтәргә кирәк. Россия фәнни цитаталар индексы мәгълүматлары буенча, аның фәнни басмаларына 318 сылтама теркәлә. Х.Ч. Алишинаның фәнни мәкаләләре еш кына елына бер чыга торган «Тюркологический сборник», «Филологический дискурс» җыентыкларында, «Российская тюркология», «Мәгариф», «Вестник Тюменского государственного университета», «Сибирский филологический журнал» һ.б. журналларда бастырыла.

Хәнисә Чәүдәт кызы Алишина Төмән дәүләт университетында һәм Төмән өлкәсендә тюркология мәктәбе башлангычында тора. Профессор югары уку йортында төрле вазифаларда эшләгән елларында укыту, киң фәнни-методик һәм оештыру эше алып бара. Нәкъ менә аның гаять зур тырышлыгы һәм көндәлек фидакарь хезмәте ярдәмендә Төмән дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла һәм ике дистә елдан артык уңышлы эшли.

Галимәнең бөтен һөнәри эшчәнлегенең мөһим өлеше булып фәнни-педагогик кадрлар, аспирантлар әзерләү тора, бүгенге көнгә кадәр Хәнисә Чәүдәт кызы моңа күп көч һәм энергия бирә. Төмән дәүләт университетын һәм Д.И. Менделеев исемендәге Тубыл дәүләт педагогия институтын тәмамлаучылар тарафыннан Төмәндә, Тубылда, Казанда ул биргән юнәлештә 30 га якын кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклана. Аның турыдан-туры җитәкчелегендә 115 диплом эше, 10 кандидатлык диссертациясе якланган.

Филология фәннәренең беренче докторы һәм тюркология буенча бердәнбер профессор буларак, ул 10.02.02 «РФ халыклары телләре. Татар теле» белгечлеге буенча Төмән дәүләт университеты һәм Тубыл дәүләт педагогия институтының уртак диссертация советын булдыру инициаторы да. Моннан тыш, Төмән дәүләт университеты каршындагы фәннәр кандидаты һәм докторы гыйльми дәрәҗәсенә дәгъва итү өчен диссертацияләр яклау буенча тагын ике: «Чагыштырма-тарихи, типологик һәм чагыштырма тел белеме», «РФ халыклары телләре. Рус теле» белгечлекләренең диссертация советы әгъзасы булып тора. Яшь галимнәр бөтен Төмән өлкәсе территориясендә, шул исәптән ХМАО, ЯНАО, шулай ук Татарстан Республикасында уңышлы эшлиләр.

2014 елда ректор В.Н. Фальков боерыгы белән профессор Х.Ч. Алишина Төмән дәүләт университетының тюркология үзәге директоры итеп билгеләнә. Тюркология үзәге Мәскәү, Новосибирск, Башкортостан, Калмыкия, Кырым, Татарстан, Тыва, Хакасия, Саха-Якутия һәм Россия Федерациясенең башка төрки телле төбәкләре белән актив фәнни элемтәләр тота. Х.Ч. Алишина федераль дәрәҗәдә милли филология һәм мәгариф киңлеген үстерүгә зур өлеш кертә. Аерым алганда, ул Башкортостан Республикасы югары уку йортлары эшчәнлегендә башкорт һәм татар филологиясе буенча фәнни һәм педагогик кадрлар әзерләүдә актив катнаша, Башкорт дәүләт университетының диссертация советы эшендә рәсми оппонент булып тора, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренең алдынгы оешмаларының бәяләмәләрен төзи, башкорт һәм татар филологияләре кафедралары төзегән авторефератларны, фәнни хезмәтләрне, дәреслекләрне һәм уку әсбапларын системалы рәвештә рецензияли. Профессор Казан, Башкортостан, Калмыкия, Чувашстан, Тубыл һәм Россия Федерациясенең башка югары уку йортлары һәм академияләренең диссертация советларында якланган фәнни дәрәҗәләргә дәгъва итүчеләргә һәрьяклап ярдәм күрсәтә.

Х.Ч. Алишина М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы эшендә актив катнаша. 2015 елдан В.И. Вернадский исемендәге Кырым федераль университетында «Кырымтатар теле һәм әдәбияты», «Гарәп теле һәм әдәбияты», «Төрек теле һәм әдәбияты», «Фарсы теле һәм әдәбияты» әзерләү юнәлешләре, шулай ук аспирантларны аттестацияләү буен-

ча дәүләт имтихан комиссиясен җитәкләп, Хәнисә Чәүдәт кызы Алишина Кырымның һәм Себернең нәтиҗәле хезмәттәшлегенә нигез сала.

Берничә ел дәвамында Б.Б. Городовиков исемендәге Калмык дәүләт университеты белән актив хезмәттәшлек итүе «Сетевое востоковедение» халыкара проекты кысаларында монголларны өйрәнүче һәм тюрколог В.И. Рассадинга багышланган фәнни конференциядән башлана. Калмык дәүләт университеты ректораты профессор Х.Ч. Алишинаны «Төрки һәм монгол телләрендә матди лексика катламын кушу (кием, аяк киеме һәм бизәнү әйберләре терминнары материалында)» өстенлекле фәнни юнәлешләр буенча югары уку йортындагы грант составына кертә.

Төмән дәүләт университетының алдынгы галимнәре арасында профессор Х.Ч. Алишина аерым урын алып тора. Профессиональ фәнни һәм педагогик кызыксынулардан тыш, иҗтимагый әһәмиятле эшчәнлек алып баручы белгечләр аз. Хәнисә Чәүдәт кызы Төмән өлкәсендә милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә зур өлеш кертә. Төмән өлкәсенең Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Россия профессорлар җыелышының төбәк бүлеге әгъзасы буларак, ул яшьләр һәм укучыларның белемен үстерүдә актив катнаша. 2013 елдан татар теле һәм әдәбияты буенча өлкә олимпиадаларын үткәрү комиссиясен җитәкли, «Төмән өлкәсенең иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» конкурсларында жюри эшенә җитәкчелек итә. Төмән дәүләт университеты профессоры Хәнисә Чәүдәт кызы Алишина тюркологияне һәм, аерым алганда, татар телен, мәдәниятен үстерүгә зур өлеш керткән себер галимнәре, шагыйрьләре, язучылары, җәмәгать, сәнгать һәм мәдәният эшлеклеләре хезмәтләрен популярлаштыра. Бу, һичшиксез, мөһим эш, ул халыкның фәнни, иҗтимагый, мәдәни тормышында тыгыз катнашуны таләп итә.

Хәнисә Чәүдәт кызы шәхесе, күптөрле һәм киң фәнни, мәгариф, иҗтимагый эшчәнлеген исәпкә алып, бүгенге көнгә кадәр аның коллегаларында кызыксыну уята. Аның турында массакүләм мәгълүмат чараларында дистәләгән мәкаләләр язылган, аларда аның шәхси һәм иҗади язмышы, кызыксынулары, казанышлары, үз халкына мәхәббәте һәм башка күп нәрсәләр ачыла.

УДК 372.881.1

Минмуллина Сиринә Фәнисовна,
Казан федераль университеты

Татар әдәбиятын укыту технологияләре һәм методлары

татар әдәбияты, технология, укыту методлары, инновацион технологияләр, проект эшчәнлеге

Через некоторое время два проекта были объединены. В сентябре 1932 года в Турткуле состоялась первая орфографическая конференция. На этой конференции была принята «Новая орфография каракалпакского языка», составленная Г. Алпаровым, К. Убайдуллаевым, К. Айымбетовым [Алпаров 1933]. В составе нового алфавита не было никаких изменений, только были изменены места некоторых букв: буквы, означающие специальные каракалпакские звуки перенесены в конец алфавита, а также впервые были приняты заглавные буквы.

В вышеназванной работе рассматриваются важные вопросы каракалпакской письменности, основанной на латинской графике, некоторые ее недостатки и достижения. «Установление твердых правил письменности способствовало дальнейшему развитию каракалпакского литературного языка в смысле выработки в стандартизации фонетико-грамматической нормы каракалпакского языка в письме» – пишет профессор Д.С. Насыров [Насыров 1976: 28].

По данному проекту в новом каракалпакском алфавите, основанном на латинской графике, представлены 32 буквы, из них 9 гласных и 23 согласных букв. В новые орфографические правила внесены следующие изменения: во всех слогах сохранять написание сдавленных звуков «ь» и «i», написание сдавленных губных гласных «и» и «у» сохранять только в первом и во втором слогах, например: uzunlьg, bygyngi, tylkyni, ykyni.

Открытые губные согласные звуки «о», «ө» писать только в первом слоге; например: bөdene, otьn, toqьm и т.д.

Хотя в словах некоторые согласные звуки имеют другое звучание, в письме должны были сохранены основы слов. Например, senler (seller emes), kөnbegen (kөmbegen emes) songa ит.д.

В этом проекте впервые были приняты правила правописания заглавных букв, также сложносокращенных слов в каракалпакском языке.

Созыв орфографической конференции по каракалпакскому языкознанию, принятие в ней каракалпакского алфавита и правил орфогра-

фии, также определение письменных знаков имеет важное значение в развитии каракалпакского литературного языка.

Были определены основные фонетические закономерности каракалпакского языка, уровень применения каждого из них. Также в этой орфографии в малом количестве были указаны правописание заимствованных слов, новых слов, вошедших в каракалпакский язык. Но, преобладание фонетического принципа в орфографии, к тому же не полное принятие букв латинского алфавита, отсутствие некоторых букв не смогло обеспечить правописание новых слов, вошедших в наш язык, а также правописание заимствований. Эти недостатки были устранены в последующих этапах.

При принятии нового алфавита и орфографии в 1995 году были учтены первые опыты, в истории каракалпакской письменности имена языковедов ее основателей остались в памяти на века.

Мышление человечества, успехи в различных сферах жизни, достижения современности сохраняются только через письменность, переходят от поколения к поколению. Без письменности не может быть развития. Письменность является самым важным, самым необходимым средством общения между людьми, обмена мнениями, в проживании жизни людей.

ЛИТЕРАТУРА

Алпаров Г. Qaraqalpaq tiliniň imlası / Г. Алпаров, К. Убайдуллаев, Қ. Айымбетов. – Төрткүл, 1933.

Баскаков Н.А.Замечания к проектам каракалпакской орфографии // Сб. Письменность и революция. – М., 1933. Т. I.

Пирниязов Қ. Қарақалпақ тилиниң лингвистикалық терминологиясы. – Нөкис, 1987.

Татарский энциклопедический словарь. Казань: Институт Татарской Энциклопедии АН РТ, 1999.

Ҳамидов Ҳ. Октябрь революциясына дейинги қарақалпақ жазыўы ҳаққында // Қарақалпақ тили бойынша изертлеўлер. – Нөкис, 1971.

Убайдуллаев К. Қарақалпақ тили жазыўының раўажланыўы. – Нөкис, 1957.

УДК 372.881.1

Сагдиева Рамилә Камиловна,

Казан федераль университеты

Олпат синтаксистларның методик эшчәнлеге

автор, дәреслек, синтаксис, күнегү, бирем

М.З. Зәкиев, С.М. Ибраһимов һәм Ф.С. Сафиуллина – хәзерге татар әдәби теле синтаксисына зур өлеш керткән галимнәр.

М.З. Зәкиев татар тел белемендә беренчеләрдән булып югары уку йортлары өчен синтаксис курсына нигез сала, һәм 1958 елда аның «Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис» дип аталган беренче монографиясе дөнья күрә. 1963 елда «Синтаксический строй татарского языка» дигән монографиясен бастыра һәм докторлык диссертациясен яклый. Әлеге фәнни эшчәнлеген галим XXI гасыр башларына кадәр дәвам итә.

Ф.С. Сафиуллина 1966 елда М.З. Зәкиев җитәкчелегендә «Порядок слов в современном татарском литературном языке» дип аталган темага кандидатлык, ә 2000 елда «Развитие синтаксического строя татарского литературного языка (ХХ века)» дигән исем астында докторлык диссертациясен уңышлы яклый. Галимә беренчеләрдә булып татар тел белемендә һәм тюркологиядә татар сөйләм теленең синтаксисын, диалектлар синтаксисын һәм текст стилистикасын өйрәнә. Ул рус һәм татар теле синтаксисын чагыштырмалы планда тикшерүгә ирешә.

С.М. Ибраһимов та М.З. Зәкиев җитәкчелегендә «Аналитические конструкции в татарском языке» дип аталган кандидатлык диссертациясен яклый. Автор аналитик иярчен җөмләләрнең төрләрен, аларның иярткүче компонентка иярткүче теркәгечләр, ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү интонация аша иярүләре хакында тулы мәгълүмат бирә. Аларның синтетик иярчен җөмләләрдән аермасы тулы итеп тасвирлана һәм дәлилләнә. Аның хезмәтләрендә аналитик һәм синтетик иярчен җөмләләрнең синонимлыгы хакында да кызыклы мәгълүматлар табарга мөмкин.

Югарыда исемнәре аталган галимнәр гомуми белем бирү оешмалары өчен төзелгән татар теле дәреслекләренең үсешенә дә зур йогынты ясыйлар. М.З. Зәкиев 1960 елдан башлап соңгы елларга кадәр татар теленнән программалар, дәреслекләр язу эшчәнлеген алып бара. Аның шәкертләре дә әлеге методик эшчәнлектә үз эзләрен калдыралар.

М.З. Зәкиев – татар телендә төп һәм урта гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныфлары өчен татар теленнән дәреслекләр авторы.

8 нче сыйныфлар өчен дәреслек тел турында мәгълүмат бирүдән башлана. Кереш дәрестән соң укучылар 7 нче сыйныфта алган белем-

нәрен искә төшерәләр. Бу исә кушма җөмлә синтаксисына кереп китәргә үзенә күрә бер нигез булып тора. Яңа материал туры һәм кыек сөйләм турында гомуми мәгълүмат бирүдән башлана. Укучылар туры сөйләм янындагы тыныш билгеләре һәм диалог белән танышалар, туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү вариантларын гамәлдә кулланырга өйрәнәләр. Әлеге материал укучыларга беренче тапкыр бирелә, шуңа күрә теория аерым рубрика форматында җентекләп аңлатыла, фактик мисаллар ярдәмендә дәлилләнә. Төп һәм истә калдырырга тиешле кагыйдәләр кыска, гади итеп тәкъдим ителә, алар аерым төс белән аерылып бирелә. Һәр дәрес ахырында укучыларның белемнәрен тикшерү максатыннан теоретик сораулар урын алган. Схема һәм таблицалар ярдәмендә теоретик материалны ассызыклап бару да яңа теманы җиңел һәм чагыштырмалы планда истә калдырырга нигез булып тора. Күнегүләр эчендәге фактик материал булып тоташ чәчмә һәм шигъри әсәрләр дә, классик язучы-шагыйрьләрнең иҗатыннан тупланган аерым җөмләләр дә хезмәт итә.

Алга таба кушма җөмлә синтаксисын өйрәтү башлана. Укучыларга аерым этәргеч сораулар, күзәтүләр алып бара һәм нәтиҗә ясый торган эш төрләре бирелә. Шул рәвешле шул чорда ук укучы дәреснең темасын, максатын үзе билгели алган, әлеге төр биремнәр аша нәтиҗә ясап, кагыйдә формалаштырган. Кушма җөмлә синтаксисы кысалараныда тезмә кушма җөмлә, иярченле кушма җөмлә һәм катлаулы кушма җөмлә җентекләп аңлатыла, анализ ясау үрнәкләре бирелә. Күп кенә башка дәреслекләрдән аермалы буларак, схемада укны иярчен җөмләдән баш җөмләгә каратып куялар. Теге яки бу иярчен җөмләгә билгеләмә биргәндә сораулар куелса да, иярчен компонентның баш җөмләгә ияреп килү принцибы буенча эш ителә. Дәреслектә беренче тапкыр иярчен аныклагыч җөмлә һәм тезем турында да мәгълүмат бирелә.

Авторлар тезмә һәм иярченле кушма җөмлә компонентлары арасындагы тыныш билгеләрен өйрәтеп, ассызыклап барсалар да, ахырдан пунктуация белән бәйле гомуми кагыйдәләр аерым бүлек итеп тәкъдим ителә. Шул чор таләпләреннән чыгып караганда, әлеге дәреслекләрдә грамматик белемне үзләштерүгә, грамоталылыкка нык басым ясала. Укучылар теге яки бу кагыйдәләрне үзләштерәләр һәм аны гамәлдә дөрес кулланырга өйрәнәләр.

Укытучының эшен җиңеләйтү максатыннан, зур темалардан соң укучыларның белемнәрен тикшерү өчен 2 вариантта гамәли биремнәр дә тәкъдим ителә.

Дәреслек ахырында синтаксис курсын гомумләштереп кабатлау өчен күнегүләр, биремнәр бирелә. Монда исә гади җөмлә синтаксисы да, кушма җөмлә синтаксисына да караган материал ныгытыла [Зәкиев 2015].

9 нчы сыйныфлар өчен дәреслектә мөстәкыйль рәвештә нәтиҗә ясау һәм сөйләм телен үстерү өчен биремнәр билгеле бер урынны алып тора. Димәк, укучылар логик фикерләргә, уйланырга, күзәтү һәм нәтиҗә ясарга өйрәнәләр. Шул ук вакытта коммуникатив компетенцияне тормышка ашыру да теоретик материалны аңлату белән бергә үрелеп алып барыла.

Программа буенча 9 нчы сыйныфта урта сыйныфларда үткән материалны тулысынча кабатлаттыру максат итеп куелса да, укучылар өчен кызыклы һәм яңа темалар да юк түгел. Мәсәлән, фонетика, лексика, сүз ясалышы һәм төзелеше, морфология, синтаксис бүлекләре кабатлаттырылса да, татар орфографиясенең төп принциплары, өстәлмә, күзаллаулы баш килештәге сүзләр һәм алар янындагы тыныш билгеләре укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә. Дәреслекнең шактый зур өлешен стилистика һәм сөйләм культурасы белән бәйле мәсьәләләр алып тора. Укучыга беренче тапкыр стилистика мәсьәләләренә: әдәби сөйләм стильләренә, сөйләм стиленең үзенчәлекләренә, синтаксик синонимнар турында аңлатма бирелә. Моннан тыш сөйләм культурасына, татар милли әдәби теленең барлыкка килү тарихына, татар сөйләмә теленең диалектларына да аерым бүлекләр, бүлекчәләр бирелә. Укучыларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып, теоретик материал шактый зур күләмдә, ләкин җиңел тел белән, таблица-схемаларга таянып аңлатыла, укучыларның исләренә төшерелә. Дәрестә тәкъдим ителгән күнегүләрнең санын күп дип әйтеп булмый. Күбрәк теоретик материалга, теоретик этәргеч сорауларга урын бирелә. Теоретик материалны ныгыту һәм кабатлау максатыннан, ахырдан 1-2 күнегү бирү белән чикләнелә. Ләкин дәреслек ахырында үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау өчен биремнәрнең, эш төрләренең саны шактый. Шуларга нигезләнеп, укытучы укучыларның белемнәрен бәяли һәм нәтиҗә ясый ала [Зәкиев 2015].

10 нчы сыйныфлар өчен төзелгән дәреслектә, программага таянып, телнең яшәеше, үсеше, җанлы һәм үле телләр белән таныштырыла. Татарстанда татар телен саклау һәм үстерү белән бәйле чаралар санала. Борынгы төрки әдәби тел, иске төрки әдәби тел, иске татар әдәби теле

турында да укучылар кызыклы мәгълүмат алалар. Гарәп һәм латин графикасы белән таныштыру, аларның үрнәкләрен бирү һәм укучыларның үзләреннән дә әлеге текстларны укыттырып карау өлкән сыйныф укучылары өчен кызыклы һәм мавыктыргыч булып санала. 11 нче сыйныф дәреслеге аша яшь буын борынгы төрки этнонимнар белән таныша. Авторлар татар этнонимының этимологиясе һәм семантикасы белән дә таныштырырга онытмыйлар. Татар теленнән программалар һәм дәреслекләр төзегән тел галимнәренең фотосурәтләре һәм аларның кыскача тормыш юлы, фәнни-методик эшчәнлекләре хакында мәгълүмат бирү укучылар арасында галимнәрне таныргa, хөрмәт итәргә һәм алар үрнәгендә фәнни эшчәнлек алып барырга этәргеч булып санала.

Әлбәттә, татар теленең төп теоретик материалы инде төп гомуми белем бирү оешмаларында үтелеп бетелсә дә, программа нигезендә, авторлар 11 нче сыйныфта фонетика, морфология һәм синтаксис курсын кабатлаттырып узалар. Теорияне аңлату характерындагы кагыйдәләр инде күзгә ташланмый. Бик сирәк очракта гына теге яки бу теоретик мәгълүмат таблица-схема форматында урын ала. Күбрәк гамәли биремнәргә, тел берәмлекләренә анализ ясауга басым ясала. Ләкин шул ук вакытта укучылар кагыйдәләрне исләренә төшерергә мәҗбүр. «Белемегезне тикшерегез» дигән рубрикада аларга теоретик сораулар тәкъдим ителә [Зәкиев 2016].

Ф.С. Сафиуллина һәм С.М. Ибраһимов рус урта гомуми белем мәктәпләренең 11 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек төзиләр. Дәреслек укучыга татар әдәби теленең функциональ стильләре, гади җөмлә һәм кушма җөмлә синтаксисы, текст төзелеше турында мәгълүмат бирүдән гыйбарәт. Әлбәттә, күп теоретик материал кабатлау форматында, чөнки алар инде төп гомуми белем бирү оешмаларында үтелгән темалар. Шул ук вакытта татар теленең төрки телләр арасында тоткан урыны, татар теленең диалектлары, хәзерге чорда татар әдәби теленең торышы, текст төзелеше белән бәйле мәгълүматлар беренче тапкыр тәкъдим ителә. Башка дәреслекләрдән аермалы буларак, авторлар укучыны логик фикерләүгә йөз тота торган биремнәр белән эш итә. Кагыйдәләр дә чагыштырмалы планда, ягъни татар һәм рус телләрендәге теоретик материалның яктыртылышын чагыштырып йөрәтүдән гыйбарәт. Һәр очрак та татар һәм рус телләренең охшаш һәм аермалы якларын барлаудан тора. Бу исә рус телендә белем бирү оешмаларында укучы татар балалары өчен гаять мөһим.

Авторлар укучыга төпле белем бирү генә түгел, ә аларның сөйләм телен үстерүне дә максат итеп куялар. Теге яки бу теоретик материал өйрәтелеп кенә калмый, ә бик мөһим булган синонимлык мәсьәләсенә дә даими рәвештә игътибар иттерелә. Сүзтезмәләрнең, бер составлы җөмләләрнең, аналитик һәм синтетик кушма җөмләләрнең синонимлыгына басым ясала. Шул рәвешле авторлар укучының бертөрле сөйләм калыпларыннан арынырга, төрле формаларны кулланырга, кабатлаудан котылырга юнәлеш бирәләр.

Моннан тыш Ф.С. Сафиуллина һәм С.М. Ибраһимов укучының логик фикерләвен үстерүне дә максат итеп куялар: җөмлә кисәкләре, иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре ияртүче сүздән чыгып сорау кую алымына түгел, ә теге яки бу җөмлә кисәгенең нинди мәгънә белдерүенә, ияртүче сүзне кайсы яктан ачыклап килүенә, нинди максат белән әйтелүенә бәйле аңлатыла.

М.З. Зәкиев, С.М. Ибраһимов, Ф.С. Сафиуллина – төп һәм урта гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы татар балалары өчен дә саллы дәреслекләр язган методистлар. Шул чор таләпләре белән бәйле теоретик белем бирү алгы планга чыкса да, бүгенге көндә актуаль булган проблемалы сорау кую, тема һәм максатларны үзлектән формалаштыру, кагыйдә чыгару, нәтиҗә ясау кебек эш төрләре әлеге хезмәтләрдә чагылыш таба. Алар белем алуны ятлау методикасы аша түгел, ә аңлы рәвештә үзләштерүгә юнәлдерәләр, укучыны логик фикерләргә өйрәтәләр. Теоретик материал күпчелек очракта күнегүләр эчендә бирелгән аерым җөмләләр аша ныгытылса да, тоташ текстларга да аерым урын бирелә, һәм алар һәрвакыт укучыны тәрбияләү максатын күз уңында тота.

Мәкалә «Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр» фәнни белем бирү үзәге кысаларында язылды.

ӘДӘБИЯТ

Зәкиев М.З. Татар теле. 9 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / М.З. Зәкиев, С.М. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 135 б.

Зәкиев М.З. Татар теле. 8 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / М.З. Зәкиев, Н.В. Максимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 159 б.

Зәкиев М.З. Татар теле. 10-11 сыйныфлар: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / М.З. Зәкиев, Н.В. Максимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 334 б.

Сафиуллина Ф.С. Татар теле: Рус урта гомуми белем мәкт. 11 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен д-лек. – Тулыл. 2 нче басма. / Ф.С. Сафиуллина, С.М. Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2000. – 175 б.

УДК 37.02

Садриева Илүзә Рәмзиловна,
Казан шәһәре Совет районының «180 нче күп профильле полилингваль гимназиясе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе
Хөснетдинов Дамир Хәйдәрович,
Казан федераль университеты

Татар телен дистанцион форматта укытуның дидактик чарасы буларак интернет-платформа

дистанцион белем бирү, татар теле, заманча технологияләр, дидактик чара

Хәзерге вакытта нинди дә булса телне өйрәнү процессында мәгълүмати технологияләр куллануга карата зур ихтыяҗ барлыкка килә, чөнки алар әлеге процессны җиңеләйтергә генә түгел, ә укучыларның кызыксынуын арттырырга да мөмкинлек бирә. Дәресләр өчен интернет-платформа куллану мөмкинлеге укытучыга шушы платформа чараларыннан файдаланып, дәресләрне реаль вакыт режимында үткәрергә мөмкинлек бирә. Шулай да, күпчелек укытучылар мондый белем бирүгә саклык белән карый, традицион дәресне яңа технологияләргә караганда өстенрәк күрә.

Дистанцион белем бирү өлкәсе татар теле предметын укыту өчен бераз чит булса да, аны куллану өчен мөмкинлекләр зур. Мисал өчен, сыйныф карантинга ябыла. Бу очракта, иң беренче чиратта, дистанцион дәресләр ярдәмгә килә.

Бу мәкаләдә сүз өстәмә белем бирү шартларында татар телен өйрәтүнең дидактик чарасы сыйфатында кулланылган интернет-платформа турында барачак. Безнең бурыч – традицион дидактик чараларны, аларның функцияләрен һәм интернет платформаны инновацион чара буларак чагыштыру, татар телен өйрәтү процессында аларның ролен ачыклау. Дидактик чара төшенчәсе тар һәм киң мәгънәдә карала.

В.А. Сластенина фикеренчә, дидактик чаралар – укучыларның тойгы органнарына тәэсир итүче һәм аларга дөньяны турыдан-туры танып белүне җиңеләйтүче сенсомотор стимуллар булган чаралар [Сластенина 2013: 276]. Автор фикеренчә, дидактик чараларга белем бирү процессында кулланыла торган һәм әлеге процессны җиңеләйтә торган барлык предметлар, мәсәлән, дәреслекләр, мәктәп кирәк-яраклары, компьютерлар һ.б. керә.

Без *дидактик чара* төшенчәсен киңрәк планда ачарга телибез. «Дидактик чаралар белем бирү максатларын тормышка ашыру чаралары булып тора. Алар материаль булган (дидактик материал) һәм материаль булмаган (укыту ысуллары һәм алымнары, уку-танып белү эшчәнлеген оештыру формалары) характердагы чараларга бүленәләр» [Вишнякова 1999: 113]. Димәк, дидактик чара – педагогның белем бирү эшчәнлегендә кулланган коралы гына түгел, ә бу эшчәнлекне оештыру ысулы да.

Традицион матди дидактик чаралар, гадәттә, тоемлау үзенчәлекләре буенча классификацияләнә. Димәк, укучыларның мәгълүматны кабул итү процессында нинди органнары катнашканы исәпкә алына. Моңа бәйле рәвештә дидактик чараларны визуаль, аудиаль, аудиовизуаль, тренажер һәм универсаль төркемнәргә аерып була. Интернет платформаны без универсаль дидактик чарага кертә алабыз, чөнки мәгълүматны үзләштерү процессында интернет-платформаны кулланып өйрәнгәндә ишетеп һәм күреп кабул итәргә, шулай ук билгеле бер күнекмәләрне заманча тренажерлар ярдәмендә эшкәртүне дә гамәлгә ашырырга була (мәсәлән, яңа сүзләрдән торган электрон карточкалар).

Дидактик чараны матди булмаган чара дип аңлаганда, без белем бирү эшчәнлеген оештыруның дидактик формалары белән эш итәбез. Интернет-платформалар уку сыйфатына йогынты ясамыйча, дәресләрне оештыруның гомуми формалары белән эшләргә мөмкинлек бирә. Интернет-платформа, дидактик чара буларак, традицион матди дидактик чаралардан нәтиҗәлелеге ягыннан ким түгел дигән фикергә килергә мөмкин.

Тел материалын дистанцион форматта өйрәнү традицион эш барышыннан аерылып торамы? «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы закон нигезендә, белем бирү программаларын гамәлгә ашыру электрон укыту һәм дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып гамәлгә ашырыла ала. «Электрон белем бирү» төшенчәсе мәгълүмат базаларында булган һәм белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланыла торган мәгълүматны һәм аны эшкәртүне тәэмин итүче

мәгълүмати технологияләрне, техник чараларны, шулай ук күрсәтелгән мәгълүматны тапшыруны, укучыларның һәм педагогик хезмәткәрләрнең үзара бәйләнешен тәэмин итүче мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләрне кулланып белем бирү эшчәнлеген оештыру буларак аңлатыла [Сластенин 2013: 156]. Димәк, электрон белем бирүгә без дистанцион укуны гына түгел, ә мәгълүмати технологияләр ярдәмендә материалны мөстәкыйль үзләштерүне дә кертә алабыз.

Мисал өчен, укытучы укучылар саны 20 дән артмаган сыйныфта онлайн режимда дәресләр алып бара ала, шул ук вакытта укытучы һәм укучылар бер-берсен күрәләр, бу социализация проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирә. Дистанцион белем бирүнең, һичшиксез, традицион белем бирүгә караганда берничә өстенлеге бар. Беренче һәм төп өстенлек, әлбәттә, дәрескә эләгү мөмкинлеге. Димәк, укучылар сыйныфтан читтә булып та, ирекле белем алу мөмкинлегенә ия. Моннан тыш, дистанцион белем бирүдә мөһим өстенлек – сыгылмалылык. Димәк биремнәрне үзеңә уңайлы вакытта башкарырга мөмкин дигән сүз. Безнең фикеребезчә, дистанцион белем бирүдә төп кимчелек – укытучының дәресләргә әзерләнүдә күп хезмәт куюы.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, без киләчәктә татар теле укытучыларының барлык ихтыяҗларына һәм таләпләренә җавап бирәчәк махсус платформа булдыру кирәк дигән фикергә килә алабыз. Беренчедән, ул төркемдә укыту өчен исәпләнгән булырга тиеш. Икенче мәҗбүри шарт – укытучыларның үз методик эшләнмәләрен булдыру, аларны платформада бастырып чыгару һәм алга таба куллану мөмкинлеге, ә өченчедән, биремнәр базасын тулыландыру һәм яңарту, башка укытучыларның методик эшләнмәләреннән үрнәк өчен шартлар тудыру.

ӘДӘБИЯТ

Вишнякова С.М. Профессиональное образование. Словарь. Ключевые понятия, термины, актуальная лексика. – М.: НМЦ СПО, 1999. – 538 с.

Сластенин В.А. Педагогика: учеб. пособие для студ. высш. пед. учеб. заведений. – М., 2013. – 576 с.

УДК 37.012; 070

Сәйфуллина Флера Сәгыйтовна,
Шәмсетдинова Суфия Илдаровна,
Казан федераль университеты

Ибраһим Биккол(-ов) мәкаләләрендә XX гасыр башы татар мәктәпләрендә уку-укыту мәсьәләләре

Ибраһим Биккол(-ов), XX гасыр башы мәктәпләре, милли журналистика, милли тәрбия

Татар җәмгыятендә XIX гасыр урталарында башланган Яңарыш хәрәкәте XX гасыр башында тагын да активлаша. Әлеге чор – милли реалистик әдәбият үсеше көчәйгән, вакытлы матбугат, басмаханәләр, публицистика, журналистика, татар профессиональ театры формалашкан вакыт. Милли әдәбият, мәдәният, сәнгать үсешендә зур эшләр башкарып, исемен халкыбыз тарихына алтын хәрефләр белән язып калдырган зыялыларыбыз белән беррәттән, әлеге Яңарыш хакына шактый күп эшләр башкарып та, шәхесләре бүгенге көндә дә бик аз санлы укучыларга мәгълум булган, совет чорында авыр язмышка дучар ителгән милләттәшләребез дә шактый. Шулардан берсе – заманының танылган журналисты, милли-мәдәни-сәяси мәсьәләләргә кагылышлы күпсанлы аналитик мәкаләләр авторы – сәяси репрессияләр корбаны булган шәхес – Касыйм Биккол(ов).

Ибраһим Җамаледдин улы Биккол(ов) (1884-1938) – җәмәгать эшлеклесе, педагог, XX гасыр башында актив әдәби-публицистик эшчәнлек алып баручы журналист, тәрҗемәче. (Әлеге шәхес һәм бертуган абыйсы Касыйм Бикколовларның биография-эшчәнлекләре хакында аерым фикерләр «Бертуган Бикколовлар» китабында басылып чыкты). «XIX йөзнең соңгы чирегендә татар дөнъясына мәгърифәтчелек идеаллары иңә, зыялыларның прогресс-тәрәккъыят хакында хыял-өметләр белән яши башлаган елларда Сембер губернасы Буа өязе, Суыксу волосте, Яңа Тинчәле авылында (хәзерге Татарстанның Буа районы) үз заманында танылган руханилар гаиләсендә дөньяга килә» [Бертуган Бикколовлар 2016: 14-26].

И. Бикколовның милләтебезне дөньяга таныткан атаклы шәхесләр – Шиһабеддин Мәрҗани, Исмәгыйль Гаспралы, замандашлары – Фатих

Әмирхан, Габдулла Тукай хакындагы мәкаләләрендә аларның эшчәнлегенә төпле бәя бирә. Талантлы журналист, алдынгы карашлы җәдитче буларак, ул мәкаләләрендә тормыштагы төрле өлкәләргә мөрәҗәгать итә: иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр куя, илдәге, дөньядагы тарихи-сәяси торышка бәя бирә,Ф.Әмирхан белән берлектә «Кояш»та эшли, «Шура», «Сөембикә», «Ак юл», «Мәктәп», «Аң» журналларында мәкаләләр яза, «Әл-ислах», «Казан мөхбире», «Йолдыз», «Сибирия» газетларында языша. Автор киң колачлы, аналитик фикер йөртүче оста журналист, җәмәгать эшлеклесе, педагог булып таныла.

Үз вакытында аның журналистика өлкәдәге эшчәнлегенә Г.Ибраһимов югары бәя бирә, ләкин 1930-1937 елларда шәхес культы корбаннары булган бик күпләр кебек, аның исеме дә озак заманнарга тарих битләреннән югалган.

Әлеге мәкаләдә өйрәнү объекты итеп И.Бикколовның ХХ гасыр башы зыялылары өчен гаять тә әһәмиятле булган милли уку-укыту, тәрбия мәсьәләләргә багышланган мәкаләләреннән берсен алачакбыз. Авторның «Мәктәп» җурналында басылып чыккан «Ибтидәи мәктәпләребез хакында» [Бикколов 2013: 14-26] язмасы бу җәһәттән игътибарга лаек. Белгәнебезчә, Ибтидәи мәктәпләр – башлангыч дини белем бирә торган мәктәпләр.

Бу мәкаләнең асыл проблемасы – кадими ибтидәи мәктәпләрдә балаларга «миллият хис»е бирелмәү белән бәйле. Бөтен милләтнең киләчәге – бүгенге балаларның тәрбиясенә һәм белем бирү системасына корылган. Шушы мәсьәләне аңлаган хәлдә, мәкалә авторы сүзен түбәндәгечә башлый: «Төркиянең олуг тәрбия галимләрендән булган Сәтыйг бәк хәзрәтләре «Фән тәрбиясе» исемле әсәренең башында ук «...яренге (иртәгә булачак) госманлык, бу көнге мәктәпләрдә хәзерләнәчәктер» димеш». Әлеге фикернең асыл мәгънәсен аңлатып, И.Биккол(ов), «безнең дә киләчәктә татарлык, төркилек һәм мөселманлыгыбыз бу көнге мәктәпләрдә хәзерләнәчәктер – ягъни киләчәктә татар, мөселман булып яшәвебез бу көнге мәктәпләргә багылыдыр. Хакыйкаттер ки: безнең балаларыбыз дөньяда төркилеккә барган вакытта, мәгыйшәт илә тартышканда, чит милләтләр тәэсиренә, һәм гомум агышка бирелмәенчә, татар, мөселман улып яшәр өчен мутлака (тәгаен) бер куәт руханиягә мохтаҗлардыр. Бу куәтне башка һич нәрсәдән көтергә ярамый, моны бирәчәк нәрсә – бары тик мәктәпләребездер. Бу куәт исә шул миллият һәм исламият рухын бирүдер ки, балаларыбызны кайда

гына булсын, нинди генә милләт арасында торсын һәм нинди генә тискәре тәэсирләр булсын, буниләрнең һичберсенә бирелмәенчә, һаман татар, һаман мөселман улып яшәрлек хәлгә китерүдер. Шуның өчен ибтидәи мәктәпләргә руслар, гомумән башка милләтләр нинди күз илә карасалар, без мәктәпләргә анлардан да ныграк карарга тиеш кенә түгел, бәлки һичшиксез тиешледер», – дип яза. Журналист, гасыр башы чынбарлыгын исәпкә алып, башлангыч мәктәптән соң татар балаларының күбесенең милли белем алу мөмкинлекләре булмаячак, яки рус мәктәпләрендә укыячаклар, шул сәбәпле нәкъ башлангыч сыйныфларда тиешенчә миллият хисе, исламият рухы бирергә тиешбез, дигән фикерне куәтли. «Аларны бирүне башка мәктәпләрдән көтергә ярамый. Сәбәбе исә мәгълүм: башкалар аның өчен тәэсис ителмәгәннәр, бәлки икенче бер идеалга, икенче бер планга карап корылганнар». Алга таба, фикерен куәтләп, И. Биккол(ов), чагыштыру өчен рус балаларының мөмкинлекләрен күрсәтә: алар башлангычтан соң чит милләт мәктәпләренә китмиләр, һаман шул үзләренең мәктәпләрендә калалар, шул сәбәпле миллият хисен, дин рухын башлангыч уку йортында ала алмасалар, бу юнәлештә тәрбияне урта мәктәпләрендә алырга мөмкин булуын яза, «чөнки алар һаман тирә-якларда рус улган хәлдә яшиләр». Шуңа да карамастан, рус халкының башлангыч сыйныфтан ук, балаларына миллият, дин хисен камил итеп бирергә омтылалар, ди автор, «чөнки 5-10 яшьләрдә алган миллият, дин хисе шул кадәр нык урнаша, ки соңыннан тешең, тырнагың илә ябешсәң дә куптарып алу мөмкин булмый. Ибтидәи мәктәп бетергәчтә, хөкүмәт мәктәпләренә, чит галим мәктәбенә барачак безнең балаларыбызга ибтидәи мәктәпләребездә ни дәрәҗәдә миллият хисе, исламият рухы бирергә тиешле икәнлеге, бу икәүне чагыштырып караганда, шәйяд (бәлки) аңлашылса кирәк».

Шул рәвешле, татар рухлы балалар әзерләүне башлангыч сыйныфлардан ук игътибар үзәгенә алырга кирәклеккә басым ясаганнан соң, автор, алга таба әлеге максатка ирешү өчен кирәк булган төп мәсьәләне күтәрә: шундый әзерлекле мөгаллимнәрне кайдан алабыз, проблеманы аңлаган хәлдә дә шундый мөгаллимләр җитештерә торган, дәрелмөгәлиминнәребезнең булмавына көрсенә. «Черек нигезгә корылган, миллият хисе бирү бөтенләй юк булган, дин укытабыз дип әллә нинди әкәмәтләр ятлатып, баланың диннән рухын сүндерә торган ибтидәи мәктәпләребездән чыккан балаларыбыз мәтлубыбыз булмаган якка авышсалар, мәсьүлият алар өстендә түгел, бәлки бер тиенлек

миллият хисе, дин рухы бирә алмаган ибтидәи мәктәпләребездәдер. Шуның өчен ибтидәи мәктәпләр безне ислах итәргә, чын мәгънәсе илә ибтидәи мәктәп итү өстебезгә фарыз булган беренче эшебездер», дип төгәлли автор үзенең мәкаләсен. Шул рәвешле, гомерен журналист булуыннан башка күп еллар балалар укытуга багышлаган шәхес башлангыч мәктәпләрнең асыл максатын ачып бирә.

ӘДӘБИЯТ

Бертуган Бикколовлар: әдәби – биографик җыентык / Төз. авт. Ф.С.Сәйфуллина, И. Гомәрев, Р. Мирхаев. – Казан: Җыен, 2016. – 448 б.

Биккол И. Ибтидәи мәктәпләребез хакында // Мәктәп, 1913, № 2 – 92-93 б.

УДК 316.728: 37.035

Салимова Дания Абузаровна,
Елабужский институт Казанского федерального университета

«Каз канаты» как симбиоз танцев, культуры, образования и науки

Каз канаты, хореографический коллектив, участники, карьерный рост, городские проекты

Многие помнят: в конце 70-х и в 80-90-е годы прошлого века танцевальный коллектив «Каз канаты», состоящий из студентов знаменитого Казанского госуниверситета им. В.И. Ульянова-Ленина, блистал на сцене во всех ДК, театров и культурных центров Казани. Постановки «Каз канаты» / *Гусиное крыло*, «Туй» / *Свадьба*, «Печәнчеләр» / *На сенокосе*, «Вальс», «Колхоз яшьлэре» / *Колхозная молодежь*, «Аучылар» / *Охотники*, ритуальный индийский танец, «Жиде кыз» / *Семь красавиц*, «Татарская полька», «Танец татар-кряшен», «Язгы шаярулар» / *Весенние игры* и др. были не просто танцами, а представляли танцевально-вокальный спектакль, каждое движение и мимика, песенное сопровождение в котором были знаком-символом красоты, силы и народного духа, вековых традиций. Эксперты (члены жюри и др.) уже тогда отметили своеобразие и хореографических постановок, и манеру исполнения участников ансамбля, заслуженно получившего звание «народный».

Уникальность коллектива заключается во многих факторах. Во-первых, ансамбль встречается и танцует уже с 1977-го года несмотря на

то, что изумительный наш руководитель Габдрахман ага Салимов (1926-1990), наделивший нас «хореографическими крыльями», ушел из жизни 33 года тому назад. Видимо, профессионализм и сила духа нашего хореографа были так сильны, что Габдрахман ага сумел нас объединить на долгие десятилетия. Во-вторых, «Каз канаты», как бы парадоксально это ни выглядело, состоит из представителей совершенно разных профессий, на первый взгляд, совсем не связанных с танцами. В коллективе, который объединил в крепкое ядро Заслуженный работник культуры ТАССР Габдрахман Фаритович Салимов, танцевали ученые: академик Международной гуманитарной академии (Альбина Валиева); 5 докторов наук (Альбина Валиева, Васил Гарифуллин, Рустам Маликов, Тагир Мингазев, Дания Салимова), 11 кандидатов наук Светлана Айдарова, Диляфруз Гаптелганиева, Тагир Гилязев, Раил Имамов, Загир Исрафилов, Ания Киямова, Ландыш Латфуллина, Резеда Садыйкова, Резеда Сафиуллина, Миляуша Сибгатуллина, Фирдавес Хазиева); талантливые и известные в стране журналисты, мастера пера (Рамис Айметов, Фаил Мохамметов, Флюра Низамова, Нуриса Габдуллина (Фатихова), Лейсан Гильмутдинова, Мидхэт Садыйков, Минназыйм Сафаров, Милэушэ Сибгатуллина, Наил Хисамиев (Алан), Резеда Шарипова); известные в РТ и России в целом учителя высшей категории (Сирина Абдуллина, Сания Батршина, Рустем Батталов, Асия Валиева, Файрузя Исрафилова, Голнур Зайнуллина, Разина Калимуллина, Роза Набиуллина, Гузель Нотфуллина, Гульшагида Нуриева, Миляуша Нуриева, Таслима Фаттахова, Лилия Фатыйхова, Моршидэ Халилова, Голия Шэрипова и др.); работники сферы культуры и искусства, телевидения (Рим Гильфанов, Илфак Гилязетдинов, Лейсан Гильмутдинова, Лилия Иванова, Наджип Исмагилов, Вильсор Камильянов, Голнар Камильянова, Николай Михайлов, Азат Назмиев, Рамил Нуриев, Диляра Салимгараева, Флорида Фомина, Халиса Хакимуллина, Рамзия Халиуллина, Илиза Хасаншина, Хидая Шигапова); энергичные и активные предприниматели, руководители, работники администрации (Газинур Ахмадуллин, Ильвира Ахметова, Ригель Ахметов, Альфис Валиев, Ильфак Гилязетдинов, Загир Исрафилов, Хамит Салихов, Фарит Фатыйхов, Фаргаф Хаертдинов, Рамил Хасанов, Алсу Хисматуллина); серьезные юристы, работники прокураторы, сотрудники МВД (Роза Батталова, Рафил Валиев, Ильсур Вазиев, Идеал Вафин, Миляуша Гильмуллина, Модарис Каюмов, Самат Нуриев, Ринур Хасаншин); финансисты и экономисты (Эльвира Фатыхова, Габдрауф

Хазиев) и др. Что примечательно, вместе с танцами, сопровождавшими нас всю жизнь, среди «канатлар» (крыльев) практически все добились высоких профессиональных успехов и высот, о чем говорят звания и регалии: коллектив гордится Заслуженными: деятелями науки РТ (Васил Гарифуллин, Дания Салимова), искусства (легендарный художник Наджип Исмагилов, поэт Рамис Аймет), учителями (Разина Калимуллина), геологами (Тагир Мингазев), работниками культуры (Азат Назмиев, Мидхат Садыйков, Хидая Шигапова), юристами (Рафил Валиев), экономистами (Эльвира Фатыхова), таможенниками (Миляуша Гильмуллина), работниками печати и массовых коммуникаций (Резеда Шарипова) и др. Удостоенных различных государственных наград Республики Татарстан (орденов и медалей) среди нас свыше 30 (Алсу Хисматуллина, Альбина Валиева, Разина Калимуллина, Ландыш Латфуллина, Хамит Салихов, Минназыйм Сафаров др.); обладателей Почетного звания Отличника просвещения (Сания Батршина), нагрудных золотых знаков (Камильянов Вильсор, Дания Салимова), лауреатов республиканских премий (Васил Гарифуллин, Наджип Исмагилов и Тагир Мингазев) не перечесть! Если перечислить подробно звания и достигнутые успехи каждого из нас (наша ватсап-группа включает 43 активных участников), понадобится целая книга-справочник. Вот такую книгу, с полной информацией о наших достижениях, мы постараемся создать к 50-летию нашего ансамбля (в 2027 году).

С чем же это связано, чем объяснить успех танцоров и юристов, журналистов и учителей? Будучи студентами, мы 3 раза в неделю по три часа занимались танцами на репетициях (плюс к этому каждую неделю выступления на сценах): это и рациональное распределение времени, и ответственность перед другими, дисциплина, и умение прислушиваться друг к другу, ладить, поддерживать добрые отношения в большом коллективе, и чувство красоты, и … взаимовыручки. Именно все это необходимо в работе, профессиональной деятельности каждого из нас. Габдрахман ага Салимов, таким образом, не только научил нас танцевать и видеть прекрасное вокруг, но и смог подготовить плеяду профессионалов, с необходимым для работы набором качеств, разных сфер. Примечателен факт: в нашем ансамбле образовалось 8 крепких семейных пар, так коллектив укрепился и духовно, и семейными узами: это Ахметовы, Батталовы, Ивановы, Камильяновы, Исрафиловы, Нуриевы, Садыйковы, Хасаншины.

Феноменальность коллектива, наконец, заключается в том, что «Каз канаты» сегодня по-прежнему дружит, общается, выступает, танцует, как будто не было между нами сорока лет отсутствия репетиции. Способствует долголетию дружбы-контактов и книга-сборник «Каз канаты каурый-каурый» (Казан: Ихлас, 2013) со статьями и фотографиями участников ансамбля, воспоминаниями о коллективе и руководителе; это книга, изданная трудами самих участников и на их же средства.

Добрую память мы храним всем коллективом и о тех, кто рано ушел от нас, оставив красивый след в полете крыльев: это известные и высококвалифицированные специалисты, обладатели грантов и других наград: Наил Алан, Илсур Вазиев, Марсель Иванов, Фаил Мохамметов, Нияз Фэрхетдинов, Рифат Ногманов, Лилия Фатыйхова. Наши теплые слова пусть идут как дуа родным канатларга!

Я как автор, первая староста и солистка ансамбля, особо хотела бы подчеркнуть роль нескольких наших «канатлар» / крыльев в сегодняшнем полноценном функционировании дружного коллектива: это Васил (профессор-журналист), Загир (предприниматель) и Файрузя (учитель), Рамзия и Лейсан (работники культуры), Лилия (работник телевидения), Миляуша (редактор канала «Туган тел» на телевидении). Благодаря организационным способностям, активному участию в культурной жизни республики именно они оказались локомотивом на пути «Каз канаты» в будущее. Хочется надеяться: в наше время, сверхсжатое и концентрированное, время дефицита во всем (внимания, уважения к другим, культурным ценностям), непростое в экономическом и социальном планах, дружба и взаимоотношения крыльев свидетельствуют о вечности человеческого тепла, любви, уважения, также о том, что народное творчество (танцы, песни, обряды / традиции и д.) и культура в целом, общие история и интересы есть фундамент сохранения нас как народа. Следует подчеркнуть и то, что социальные сайты, группы, интернет-общение придали также современное дыхание ансамблю. Встречи «крыльев» совмещают и танцы, и беседы о науке, культуре и об образовании, что создает особую атмосферу участникам национального коллектива.

2023 год объявлен в Татарстане Годом национальной культуры и традиций: «Каз канаты» – самое живое и яркое доказательство движения этого Года, также свидетельство настоящей эффективности многих официальных / государственных / городских мероприятий в этом русле.

В частности, танцевальный проект мэрии Казани «Хэрэкэттэ – бэрэкэт» придал новый импульс для нашего развития, укрепил наши крылья, в рамках проекта мы встречались все лето каждую неделю и танцевали, как в юности, окунались в мир культуры и народного искусства.

УДК 811.512.145

Саттарова Мәдинә Рәшидовна,
Сабирова Раилә Мусавировна,
Казан федераль университеты

Татар халык мәкальләрендә туганлык атамалары кулланылышы

туганлык атамалары, татар теле, мәкаль

Татар телендә туганлык атамалары аерым тематик төркемне тәшкил итә һәм галимнәр тарафыннан төрле яссылыкларда өйрәнелеп килә. Соңгы елларда тел берәмлекләрен башка фәннәр белән киселеш ноктасыннан чыгып анализлау тел байлыгы мөмкинлекләренең тагын да тирәнрәк булуын ачыкларга мөмкинлек бирде. Туганлык атамаларының әдәби телдә һәм халык сөйләшләрендә кулланылган вариантларын туплап, аларның үзенчәлекләрен барлаган галимә Д.Б. Рамазанова татар халкының рухи мәдәниятен укучыга танытты [Рамазанова 2014].

Соңгы дистә елда Казан федераль университеты галимнәре тарафыннан халыкның матди һәм рухи мәдәнияте белән бәйле сүзләрне өйрәнү аеруча зур кызыксыну белән башкарыла [Татар 2012]. Төп игътибар аерым тематик төркемгә караган сүзләрнең килеп чыгышын, аларның халык авыз иҗаты үрнәкләреннән булган паремияләрдә теркәлүен өйрәнүгә юналдерелгән. Әлеге мәкаләдә шул юнәлештә бара торган эзләнүләрнең үрнәге буларак, татар халык мәкальләрнедә туганлык атамаларыныда кулланылышына игътибар ителде.

Билгеле булганча, мәкаль – халык хикмәте тупланган, буыннан-буынга тапшырылып килгән, тотрыклы берәмлекләр буларак, тирән эчтәлеккә ия. Туганлык атамалары да халыкның рухи мәдәнияте күрсәткече, тотрыклы берәмлекләр буларак билгеле. Туганлык атамалары кан туганлыгы һәм никах туганлыгы белән бәйле ике төркемгә бүлеп

карала. Туганлык атамаларының татар сөйләшләрендә күп төрле фонетик вариантларда кулланылуы аеруча кызыклы.

Гаилә төшенчәсе татар халкы өчен элек-электәп мөһим булып, гаиләдә балалар үсү, нәсел дәвам итү аеруча әһәмиятле саналган. Әлеге нисбәттән, ир бала һәм кыз бала төшенчәләренең мәкальләрдә кулланылышы үзенчәлекләрен өйрәнеп, түбәндәге гомуми фикерләр ачыкланды.

Хәзерге татар телендә гаиләдәге *ир бала* ‘ул’ төшенчәсе белән белдерелә. *Угыл* нигезеннән татар диалектларында *уғлақ, улақ, ылак* «һәрнинди хайван баласы, бәти» һәм *углан / оглан* «княжич» мәгънәсендәге сүзләр ясалган. Шор теле сөйләшләрендә *улак / уланшак* сүзе «ир бала, бала» мәгънәсендә дә кулланыла. *Угыл һәм углан* нигезләре татар телендә һәртөрле фономорфологик модификацияләргә бай: угылчак ~ угланчак, угылчык ~ угланчык, угыл-ушак, углан-ушақ һ.б. шуңа мисал булып тора [Әхмәтьянов 2015].

Олан, ылан вариантлары татар теле сөйләшләрендә очрый һәм «дитятко, малыш; братец» мәгънәсен белдерә. Иске татар телендә *ŏлан* берәмлеге *улан* «асылзат егет; шаһзадә, принц» сүзеннән поэтик-иркәләүле атама буларак кулланылган.

Ир баланы яше буенча аеру өчен татар телендә төрле лексик берәмлекләр кулланыла: *ул / ир бала / малай / яшьүсмер / егет / ир*. Әдәби телдә «балигъ булу» мәгънәсе минзәлә һәм бөре сөйләшендә, әдәби нормадан тыш, самай сүзе белән дә белдерелә. Көнчыгыш диалектларда бу мәгънәдә *ир йеткән пала, қәткә йеткән, қатыққан* сүзләре кулланыла [Рамазанова 2014].

Татар халык мәкальләрендә ‘ул’ сүзе шактый еш кулланыла. Мисал өчен бу берәмлек кулланылган мәкальләрне барлау, ир балага гомуми мөнәсәбәтне күзалларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, ир баланың кадерле булуын түбәндәге мәкальләр раслый: *акыллы ул – алтын кул; ил улсыз булмас, җир гөлсез булмас; ир бала унбиштә өй хуҗасы; укыган угыл – атадан олы; улы барның кулы бар; улы барның уты бар* һ.б.

Ир баланың кадерле булуы шул дәрәҗәдә югары бәяләнә ки, хәтта ир бала тудырган хатын да кадерле була. Мәсәлән, *алты ул тапкан хатынны ханым дисәң, урыны бар; җиде ул тапкан хатынны җаным дисәң, урыны бар; тугыз ул тапкан хатынны тугзак дисәң, урыны бар; өеңдә бала уйнаса, оҗмах дисәң, урыны бар. Ир балалы хатын алтын табактан аш ашар. Уңган хатын ул китерер, изге хатын кыз китерер* һ.б.

Ир баланың булуы белән бергә аның чын ир кеше булып тәрбияләнүе дә мөһим. Мәсәлән, *атага ул булмасаң, хатынга кол булырсың; атадан качкан ул башсыз, хуҗадан качкан кол башсыз; ул азса, кесәсендә алып кайтыр, кыз азса, итәгендә алып кайтыр; улың белән мактанма, улыңның кулы белән мактан; улың булуга куанма, мие булуга куан; улың йәштә тәрбияче бул, улың үскәч туган бул* һ.б.

Тормыш алып бару, нәсел дәвам итү өчен гаиләдә ир балаларның саны да мөһим булган. Мәсәлән, *бер угыл – угыл түгел, ике угыл – исәп түгел, өч угыл – исәп башы, дүрт угыл – нигез ташы, биш угыл – авыл, алты угыл – кала, җиде угыл яу ала. Ялгыз ул яудан каты* һ.б.

Кыз сүзе хәзерге татар телендә «девушка, девица; дочка, дочь» мәгънәләрендә кулланыла. Килеп чыгышы белән бу берәмлек гомум төрки телдәге *қыз, қыыз* сүзенә барып тоташа. Сүзнең этимологиясе өчен татар телендә кулланыла торган материал аерча әһәмиятле. Татар теленең касыйм сөйләшендә ʼŏз - кŏз «кыз» сүзеннән ясалган; себер татарлары сөйләмендәге қысақ, қызақ «ахирәт; җария, каравыш», қыргын «хатын-кыз» берәмлекләре моңа дәлил. Борынгы төрки истәлекләрдә qïz, qïzγaq «кыз», qïz «кыйммәтле, сирәк; кыйбат бәяле» дигән мәгънәдә теркәлгән. Гомумән, *кыз* сүзе элек нәсел-нәсәп терминологиясенә карамаган, ул кыйммәтле нәрсә, энҗе-җәүһәр, алтын-көмеш кебегрәк мәгънәдә булган булса кирәк [Әхмәтьянов 2015].

Татар халкында *кыз* сүзе белән бәйле күп төрле йола атамалары кулланыла: *қызаш* – нократ сөйләшендә: кыз туганнарының туйга катнашучыларны кунакка чакыру йоласы; *кыз әйттерү* – кызны кияүгә сорый бару; *кыз багу* – кияүнең һәм аның туганнарының кыз белән танышу йоласы; *кыз бүләге* – кызның ата-аналарыннан яки якын туганнарыннан, кызны кияүгә бирергә ризалык алгач, аерым акча бәрабәренә килешү билгесе итеп алдан бирелә торган бүләк (ашъяулык, яулык, җәймә, кулъяулык, янчык һ.б.); *кыз димләү* – кемгә дә булса билгеле бер кызга өйләнергә тәкъдим итү, өйләнергә киңәш бирү; *кыз елату* – кызны кияү йортына озатыр алдыннан, аның якыннарын һәм иптәш кызларын җыеп, кыз исеменнән моңланып бәет әйтүдән гыйбарәт мәҗлес, чеңләү; *кыз качыру* – кыз урлау; *кыз килешү* – ата-анасыннан яки якын кардәшләреннән кызны кияүгә бирергә ризалык алу; *кыз куенына керү* –. никахтан соң кияүнең беренче тапкыр кыз янына куна керүе; *кыз озату* – кияүгә чыккан кызны кияү өенә җибәрү, озату; *кыз сорау* – кызга өйләнер өчен, аны ата-аналарыннан яки якын туганнарыннан хатынлыкка сорау;

кыз урлау – кызны, аның яки гаиләсенең ризалыгыннан башка урлап, хатынлыкка алу; *кыз ярәшү* – кызны кемнең дә булса кәләше дип белдерү, кәләше итеп игълан итү; *кыз яучылау* – кыз сорау һ.б.

Татар халык мәкальләрендә [Исәнбәт 2010] *кыз* берәмлеге актив кулланыла. Мәгънәләренә бәйле төркемләсәк, түбәндәге үзенчәлекләр барлыгы ачыклана.

Кызларның матур булуы ассызыкланган мәкальләр күп. Мәсәлән, *ат матуры арканда, кыз матуры тарханда; егет булса, батыр булсын, кыз булса, матур булсын; каз тәзәнүдән туймас, кыз бизәнүдән туймас; ашның тәме тозында, өйнең йәме кызында; кызлы йорт – нурлы йорт; ябалдашлы агач – тау күрке, кыз матуры – ил күрке* һ.б.

Кыз баланың акыллы булуы кыйммәтлелекне раслый торган мәкальләр дә бар. Мәсәлән, *белемле кыз – бирнәле кыз; кыз акыллы егет эзли, егет матур кыз күзли; кыз байлыгы – күркәм холык, ир байлыгы – тәвәккәл; оялчан кыз – сөйкемле кыз* һ.б.

Кызларның үсеп буй җитүгә кияүгә китәчәге, аның күңелендә үз гаиләсе булырга тиешлеге турындагы фикер яши кебек мәгънәдә теркәлгән мәкальләр дә бар: *җиткән кыз – киткән кыз; кыз күңелендә – балалы бишек, ир күңелендә – иярле ат (ятар); кызлы өйгә кырык ат бәйләнер; кызны балам бар димә, кәҗәне малым бар димә* һ.б.

Кызларның шаян, шат күңелле, тапкыр, борчусыз булулары, турындагы мәкальләргә мисаллар: *кызлар бүрәнә ярыгындагы таракан ботыннан да көләләр; кызлар гәүдәгә кече, үзләре чикләвек төше; кызлар көе белән йөрсәң, төпсез күлгә төшәрсең; кызлар янында чыршы шырпы кабызма; кызның күңеле кыл кебек, көйләмәсәң, тиз китәр; кызларның күз яше иртәнге чык кебек, кояш төшү белән кибеп оча һ.б*.

Кызларның яхшы исемен, данын саклау мөһим булу турында *кызлар кыл өстендә, кылдан төшкәч, тел өстендә; кызларның хәле – караңгыда аткан ук; кызлар үсә – гөл була, гөл яндымы – көл була; кызлы кыздан көлмәсен; кызны картлар күзе белән,киемне яшьләр күзе белән сайла; кыз саклаганчы, тоз сакла; яхшы кызның чабы китәр, яман кызның яманаты китәр һ.б.* кебек мәкальләрне мисал итеп китерергә мөмкин.

Ул / ир бала һәм *кыз / кыз бала* төшенчәләренең халык авыз иҗаты үрнәкләре составында кулланылышы бу мисаллар белән генә чикләнми. Н. Исәнбәт туплаган татар халык мәкальләре арасыннан тагын бик күп мисаллар теркәлгән. Мәкаль-әйтемнәрнең гасырлар дәвамында да

үзгәрми кулланылуын исәпкә алганда, шул кадәр күпсанлы мисаллар булу, бу төшенчәләрнең халык мәдәнияте, көнкүреше, әхлагы, тәрбиясе өчен зур әһәмияткә ия булуын билгели, гаилә, туганлык мөнәсәбәтләренең татар халкы өчен кадерле булуын ассызыклый.

Мәкалә «Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр» фәнни белем бирү үзәге кысаларында язылды.

ЛИТЕРАТУРА

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А-Л). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 543 б.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. II том (М-Я). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 567 б.

Рамазанова Д.Б. Родственные и семейные отношения в названиях. – Казань: Татарское кн. изд-во, 2014. – 287 с.

Татар теленең этнокультура сүзлеге: рухи мәдәният лексикасы (сүзлек белешмәлек) / Төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Г.Ф. Җамалетдинова, Р.С. Нурмөхәмммәтова, М.Р. Саттарова. – Казан: Отечество, 2012. – 144 б.

Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җынтыгы 3 томда. I том – 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 622 б.

Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җынтыгы 3 томда. II том – 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 748 б.

Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җынтыгы 3 томда. III том – 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 799 б.

УДК 371.3

Сибгатова Эльза Миннахметовна,
Әгерҗе районы, Татарстан Республикасы
Гайнуллина Гөлфия Расилевна,
Казан федераль университеты

М. Корбангалиевнең исемен мәңгеләштерү мәсьәләсенә карата

татар теле белеме, укыту методикасы, педагогика, М. Корбангалиев

Агымдагы елда киң җәмәгатьчелек күренекле галим-педагог, тел белгече, җәмәгать эшлеклесе Татарстан Республикасы милли мәгариф системасын төзү һәм үстерүдә бик күп көч куйган һәм дәрәҗәле исемнәр белән макталган шәхес, ВЦСПС күрсәтүе буенча «Хезмәт герое» исе-

менә лаек (1928), «Хезмәт Кызыл Байрагы ордены» кавалеры (1940), СССРның «Атказанган фән эшлеклесе» (1940), исеме Бөтенсоюз Почет тактасына кертелгән (1933), Татар педагогик җәмгыятен оештыручы, аның беренче рәисе, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасында хезмәт куйган Мөхетдин Корбангалиев 150 еллык юбилеен билгеләп уза.

Корбангалиев Мөхетдин Хафизитдин улы 1873 елның 26 ноябрендә элекке Вятка губернасы Алабуга өязе Сарсак-Умга олысы Биектау авылында (хәзерге Әгерҗе районы) крепостной крестьян крестьян гаиләсендә туган.1605 елда нигезләнгән Мөхетдин Корбангалиевның туган авылы Биектау борынгы Себер трактында урнашкан. Авыл турында эзләнгәндә «Татар энциклопедик сүзлеге»нә кергән күренекле шәхесләр исемнәрен табарга була. Мөхетдиннең эти-әнисе иртәннән төнгә кадәр алпавыт Тәфкилевта эшли, ә бабалары һәм бабаларының бабалары кенәз Яушевның крепостнойлары була. Пугачев фетнәсенең данлыклы җитәкчесе Әбҗәлил Сөләйманов Биектауда яшәгән. Кечкенә Мөхетдин авыл башындагы юан агачларга фетнәчеләрне асып куюлары турында риваятьләр ишетеп үскән. Ә XVIII гасырда төзелгән елга аша таш күпер (Әби патша күпере) бүген дә исән. Балачагында Мөхетдин Казаннан Себергә товарлар белән арбалар йөрүен, юлчылар, богауланган каторжаннар үтүен күзәтә. Авыл читендәге йортта каторжаннарны төн кунарга туктатканнар, ә иртә таңнан тагын Себергә куганнар. Нәкъ шул балачакта күргәннәре һәм тойгылары дөньяны аңлауның башы була: сораулар кую, аннан соң аларга җаваплар алу өчен караш формалаша. Бу истәлекле урыннар, һичшиксез, зур тарихи кыйммәткә ия, өйрәнелергә һәм сакланырга тиеш.

Мәгълүм булганча, галимнең фәнни хезмәтләренең саны 130 га җитә, ул – йөзгә якын дәреслек авторы. Галимнең унбер телне белүе дә югары эрудициясе турында сөйли. Бу гаҗәеп тирән гыйлемле галим XIX гасыр төрки мәктәбенең өзелеп бетә язган җепләрен саклап калып, XX гасырның 40 нчы еллар башына кадәр үстерүдә искиткеч зур хезмәт куйган. Шул еллардагы татар тел белеменең фәнни фикер дәрәҗәсенә күтәрелгән беренче баскыч мәктәп укучылары, укый-яза белмәүчеләр һәм югары уку йортлары студентлары өчен татар теле, әлифба дәреслекләре иҗат итә. Урта һәм югары мәктәп өчен белем бирү программалары, рус һәм татар телләрен чагыштырып эшләнгән грамматика, арифметика, география дәреслекләре; уку, күзаллау әсбаплары,

таблицалар. Ул төзегән орфографик, аңлатмалы сүзлекләрдә, фәнни терминнар сүзлекләрендә һәм белешмәлекләрдә XX гасыр башында актив кулланылган лексика чагыла. Алар татарлар өчен рус телен өйрәнү өчен нигез булып тора һәм үткән гасырның 50 нче елларына кадәр популяр була. Лексикограф М. Корбангалиев һәр сүзнең яки фәнни терминның мәгънәсен һәм төсмерләрен җентекләп билгели. Аның фәнни терминнар сүзлеге унҗиде меңнән артык фәнни төшенчәдән һәм сүздән тора, бу татар сүзләренең күләмен киңәйтергә мөмкинлек бирә.

Талантлы галим-энциклопедистның фәнни-тикшеренү эшчәнлеге мәгърифәтчелектә бик катлаулы чорга туры килә, ул вакытта 30 ел эчендә татарлар өчен өч алфавит һәм орфография кагыйдәләре алыштырыла һәм яраклаштырыла. 1912 елдан башлап М. Корбангалиев өч вариантта дәреслекләр яза: әлифба, арифметика (Риазият); География (Дөнья). Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: татар-башкорт мәктәпләре өчен дәреслекләр арасында аның дәреслекләре иң яхшыларның берсе булып чыга һәм 20 елдан артык аларга тиңнәр булмый. Бу елларда галим укуның тормыш, хезмәт, табигать белән тыгыз бәйләнеше, туган телдә укыту, укуда хәрәкәтчән уеннар, укучыларның сәламәтлеге өчен кайгырту турында методик хезмәтләр яза, чыгышлар ясый. Бу турыда Г. Ибраһимов та үзенең «Мәдәни хезмәт юлында 30 ел» мәкаләсендә (1925) ассызыклап үтә.

М.Х. Корбангалиев 1917 елдан халык мәгарифе системасында җаваплы урыннар били: милли азчылыкларның губерна халык мәгарифе бүлеге мөдире ярдәмчесе, аннары губерна мәктәп инспекторы булып эшли, ТАССР оешканнан соң Татнаркомпросның бердәм хезмәт мәктәбе бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Бер үк вакытта Казан педагогия институтында, Татар коммунистлары университетында укыта. Кафедрага нигез салучының катлаулы проблемаларын үз өстенә алып, Казан университетында татар теле кафедрасы мөдире, хәрби-командалар курсларында, педагогика һәм җир төзелеше техникумында, мәктәп хезмәткәрләрен әзерләү курсларында һ.б. укыта. Талант, хезмәт сөючәнлек, намуслылык, үз эшенә мәхәббәт М. Корбангалиевны югары хакимият өлкәләре утырышларында үз сүзен әйтергә лаеклы шәхес итеп, иң җаваплы карарлар кабул итү дәрәҗәсенә күтәрә. Корбангалиев М.Х. дүрт чакырылыш ТатЦИК әгъзасы, ТССР Үзәк сайлау комиссиясе Президиумы әгъзасы, күп кенә съездлар һәм конференцияләр делегаты булып сайлана. Фундаменталь хезмәтләре ярдәмендә татар тел белеме генә

түгел, укыту методикасы да үсеш алган һәм системалаштырылган галим, «Мәктәб» журналын ачу башында тора (1913) һәм «Мәгариф» журналының редакция коллегиясе әгъзасы була. 1926 елда Татар педагогик җәмгыятен оештыра һәм аның беренче рәисе була. Галимнең абруе турында шундый факт сөйли. 1941 елда Мәскәүдә Учпедгиз рус булмаган мәктәпләр өчен рус теле дәреслеге язарга планлаштыра. Учпедгиз редакторы Корбангалиевка язган хатында: «...Сез җитәкче булу шарты белән генә Учпедгиз Казан галимнәре коллективына дәреслек төзүне йөкли. Авторларны сайлау хокукы Сездә кала».

Галимнең фәнни-педагогик мирасы бүген дә әһәмияткә ия, аңа галимнәр, студентлар һәм мәктәп укытучылары мөрәҗәгать итә, диссертацияләр языла, юбилейлар билгеләп үтелә, карарлар чыгарыла. Мәшһүр якташыбыз Мөхетдин Корбангалиевның исемен мәңгеләштерү өчен кулыбыздан килгәнне эшлибез: «Бөек Себер юлында Биктау» исемле авыл тарихына багышланган китапның бер бүлеге бөек якташыбызга багышланды, Корбангалиевларның нәсел шәҗәрәсе торгызылды, нәсел варислары белән элемтә булдырылды, даими рәвештә галимнең фәнни мирасы экспозициясе оештырыла килә, семинарлар, фәнни хезмәтләрен өйрәнү буенча конференцияләр, конкурслар үткәрелә.

Биектау – күренекле педагог Мөхетдин Курбангалиевның туган җире Әгерҗе районындагы зур тарихи комплексның бер өлеше булырга тиеш. Бу – үсеп килүче буынның тарихи хәтерен саклап калу юлы. Киләчәктә Иж-Буби мәдрәсәсе музее эчендә М. Корбангалиев бүлмәсен ачу хакында агымдагы елда юбилей мөнәсәбәте белән Казанда үткән «Хәрефләр әфсенләүче» исемле чарада сүз булды, мөрәҗәгать хаты эшләнде.

Казанда һәм галимнең туган җирендә мемориаль такта урнаштыру, Казан шәһәренең татар мәктәпләренең берсенә галимнең исемен бирү турындагы карар кабул ителсә дә, бүгенгә кадәр ул гамәлгә ашырылмаган. Бу проблема да хәл ителү сәгатен көтә.

Күренекле татар галиме Мөхетдин Корбангалиевның исемен мәңгеләштерү юлындагы гамәлләребез киләчәк буынны тәрбияләүдә гаять зур әһәмияткә ия.

УДК 82-16

Толегенова Гулайым,
Нукусский государственный педогогический
институт им. Ажинияза

Место творчества Габдуллы Тукая в каракалпакско-татарских литературных связях

литература, культура, поэзия, казка, сюжет, поэма, литературная связь

Габдулла Тукай (1886-1913), творивший в конце XIX – начала XX веков является великим поэтом не только татарского народа, но и с начала XX века своими талантливо написанными произведениями превращается в любимого поэта тюркоязычных народов.

Мы не ошибемся, если скажем, что в начале XX века для многих литературоведов тюркоязычных народов ознакомление с русской литературой, культурой, а также ознакомление с европейской культурой через русскую культуру происходило при содействии татарской литературы, татарской интеллигенции, татарских писателей, как Габдулла Тукай. Необходимо особо отметить роль образованной татарской интеллигенции в распространении европейской и русской культуры в Средней Азии. Поэтому, когда идет речь о каракалпакско-татарских литературных связях, творчество Г. Тукая вызывает особый интерес. Через газеты и журналы, выходящие на татарском языке в Казани, Уфе, Оренбурге его произведения распространялись на Среднюю Азию [Максетов 1987].

Издание в 1960 году Каракалпакским государственным издательством отдельной книги Г. Тукая является большим событием в литературной жизни нашей республики, а также в каракалпакско-татарских литературных связях.

В этом сборнике собраны около 90 его произведений разной тематики. В переводе сборника принимали участие каракалпакские поэты Бабаш Исмайылов, Усербай Хожаниязов, Ибрайым Юсупов. В качестве предисловия книги дана статья Ибрайыма Юсупова «Солнце татарской поэзии». В ней идет речь о жизни и творчестве Г. Тукая, его связях с

Россией и русской литературой, о его влиянии на каракалпакскую литературу и лично на самого поэта [Тукай 1960].

Хорошо зная поэзию тюркоязычных народов, он был близко знаком с восточной поэзией. Особенно, по сравнению с поэтами-современниками того периода, вышедших из тюркоязычных народов Г. Тукай совершенно отличался от них хорошим знанием русской литературы, литературы Западной Европы. То, что он учился у А.С. Пушкина, М.Ю. Лермонтова, Л.Н. Толстого, В.А. Жуковского, И.А. Крылова указывает на глубокую связь его творчества с русской классической литературой.

Известный ученый, поэт Бабаш Исмайылов перевел на каракалпакский язык около 70 стихотворений, вошедших в сборник Г. Тукая. Среди них можно выделить: «Әке ҳәм бала» («Отец и сын»), «Семья тынышлығы» («Семейное благополучие»), «Фатима ҳәмҚарлығаш» («Фатима и Карлыгаш»), «Ай ҳәмтүн» («Луна и ночь»), «Ғарға» («Ворона»), «Ана тили» («Родной язык»), «Критик», «Жас бала» («Подросток»), «Шайыр» («Поэт»), «Жуўап» («Ответ»).

Поэт Усербай Хожаниязов мастерски перевел стихотворения Г. Тукая «Таз» («Плешивый»), «Ийман» («Вера»), «Уйқы» («Сон»), «Қайда?, Ким?» («Где?, Кто?»), «Кетпеймиз» («Не уйдем»), «Суўық» («Холод»). Необходимо особо отметить участие Ибрайыма Юсупова в переводе на каракалпакский язык произведений Г. Тукая в данном сборнике. Он перевел на каракалпакский язык «Сказку о Шурале», стихотворения «Мухаббат» («Любовь»), «Бир кайгылы кунде» («Однажды в печальный день»), «Уасият» («Завещание»).

Сказка-поэма Г. Тукая «Шурале» написана в 1908 году. В этой сказке он мастерски использовал сюжет татарских народных сказок. Он говорил, что написал «Сказку о Шурале» на основе народных фантастических сказок, применяя способы Пушкина и Лермонтова, сотворивших красивые произведения [Тукай 1956].

Эта сказка-поэма по сей день дается в программе школьных учебников. Кроме этого, мы можем читать в переводах произведения видных представителей татарской литературы Хади Такташа, Галимжана Ибрагимова, Мажита Гафури, Мусы Джалиля и других.

В каракалпакско-татарских связях очень много сведений о жизни и творчестве Габдуллы Тукая. Все они придают особую прелесть каракалпакско-татарским связям, дружбе каракалпакского и татарского народов.

В перспективе эта очень важная связь, история дружбы станут одной из важных задач, требующих широкого исследования.

ЛИТЕРАТУРА

Максетов К.М. Связи каракалпакской литературы с литературами братских народов. – Нукус: Изд-во «Каракалпакстан»,1987.–С. 85-86.

Тукай Г. Сочинения. Каракалпакское государственное изд-во. – Нукус, 1960. – С. 3-6.

Тукай Г. Избранное. – М.,1956. – 98 с.

Мажитов С. Избранные сочинения. – Нукус: Изд-во «Каракалпакстан», 1965. – С. 8.

УДК 316.7

Файзуллина Гузель Чахваровна,
Уразова Лилия Мирхадовна,
Тюменский государственный университет

Территориальные особенности размещения мечетей в Ялуторовском округе Тобольской губернии во второй половине XIX века

Ялуторовский округ, метрические записи, сибирские татары, мечеть

На данный момент существует очень мало работ, посвященных изучению Ялуторовского округа и проживавших на его территории сибирских татар. В своей работе «Исламские культовые сооружения в Тобольской губернии в конце XVIII – начале XX в.» [Мавлютова 2021]. Мавлютова Г. Ш. рассматривает развитие мечетей в Тобольской губернии, в том числе и в Ялуторовском округе. Метрические записи Тобольской губернии также являются малоисследованными, ученые Файзуллина Г.Ч., Кадирова Э.Х., Масловская Л.З. [Файзуллина 2021] исследовали названия болезней сибирских татар на основе мечетных книг.

Мечеть является не только местом для совершения молитв и получения знаний, но в ней также духовными лицами велись метрические записи, которые позволяют узнать о рождении / смерти / сочетании брака / разводе. Отметим, что в фонде Национального архива Республики Башкортостан на данный момент сохранилась единственная метрическая запись юрт Ново-Атьяновские (Атьян / Атьяловские) Ялуторовского округа.

Рассмотрим расположение инородческих населенных пунктов Ялуторовского округа. В этом округе существовал 391 населенный пункт, среди которых было 14 инородческих юрт и 4 инородческих выселка, что составляет 4,6% от общего количества населенных мест. Среди них в 14 функционировала мечеть, а это составляет 77,7%.

I. По почтовому тракту:

1. **По левую сторону почтового тракта из города Ялуторовска в город Тюмень** существовала одна юрта: Кошелевские – 143 жителя, в 30 верстах от округа, при озере Кошелях. Единственная инородная юрта по эту сторону тракта была обособлена от других инородных юрт на несколько десятков верст вокруг.

2. **По левую сторону почтового тракта из города Ялуторовска в город Шадринск (Сингульской волости)**: Зимне-Сингульские (2 мечети) – 902 жителя, в 19 верстах от округа, при речке Исети; Летне-Сингульские – 113 жителей, в 19 верстах от округа, при озере Сингульском; Нижне-Ингальские – 285 жителей, в 45 верстах от округа, Верхне-Ингальские – 265 жителя, в 41 верстах от округа – при речке Ингаль. В каждой юрте проживало большое количество жителей, а особенно в Зимне-Сингульских юртах, именно поэтому на ее территории функционировали две мечети. Кроме того, вокруг каждой юрты расположено много рек, озер, что осложняло передвижение жителей в соседние юрты.

II. На проселочной дороге (проселочному тракту):

3. **По левую сторону проселочной дороги из города Курган в город Тюмень** существовал только один населенный пункт: Сунгуровские – 111 жителей, в 69 верстах от округа, при речке Сунгуровке. Единственная инородная юрта по эту сторону дороги, вокруг которой было много русских деревень.

III. По коммерческому тракту:

4. **По коммерческому тракту из города Ялуторовска в город Тобольск**: Осиновские (Помоир) – 364 жителя, в 27 верстах от округа, при озере Помоир, близ реки Тобол; Асланинские (Кашаул) – 461 жителей, в 30 верстах от округа, Красноярские (召Кактаман) – 74 жителей, в 35 верстах от округа, Авозбакеевские (Калмаклар, Азбакеевы) – 263 жителей, в 37 верстах от округа, Ново-Атьяновские (Атьян) – 498 жителей, в 50 верстах от округа, Чечкинские (Тархан) – 506 жителей, в 70 верстах от округа – при реке Тобол. В каждой юрте было большое количество жи-

телей, что способствовало появлению в них мечетей. Более того, юрты находились в нескольких десятках верст друг от друга.

5. **По правую сторону коммерческого тракта из города Ялуторовска в город Тобольск** существовал только один населенный пункт: Ревдинские – 283 жителя, в 36 верстах от округа, при озере Ревде. Рядом существовали Асланинские юрты, однако они были отделены от Ревдинских юрт реками, что повлияло на возникновение мечети в юртах Ревдинских.

6. **По левую сторону коммерческого тракта из города Ялуторовска в город Тобольск** также существовал один населенный пункт: Озернинские (Куеул) юрты – 76 жителей, в 31 верстах от округа, при озере Цуртоллы.

В Ялуторовском округе: от 1 до 100 жителей – в 1 юрте (7,14%), от 101 до 200 жителей – в 3 юртах (21,4%), от 201 до 300 жителей – в 4 юртах (28,5%), от 301 до 902 жителей – в 5 юртах (35,7%).



Исходя из вышеуказанного можно сделать вывод о расположении инородческих населенных пунктов, в которых существовали мечети: по почтовому тракту (35,7%), на проселочной дороге/на проселочном тракте (7,1%), по коммерческому тракту (57,1%). Выявленный характер расположения мечетей в татарских юртах может быть использован при реконструкции исторической территории и топографии поселений.

Исследование выполнено за счет гранта Российского научного фонда № 23-28-00838, https://rscf.ru/project/23-28-00838/

ЛИТЕРАТУРА

Мавлютова Г.Ш. Исламские культовые сооружения в Тобольской губернии в конце XVIII — начале XX в. // ВААЭ. 2021. № 4 (55).

Список населённых мест по сведениям 1868–1869 годов. СПб: Центральный статистический комитет Министерства внутренних дел, 1871. – 196 с.

Файзуллина Г.Ч. Названия болезней в письменном языке сибирских татар XIX – начала XX века (на материале мечетных книг Тобольской губернии) / Г.Ч. Файзуллина, Э.Х. Кадирова, Л.З. Масловская // Сибирский филологический журнал. – 2021. – № 4.

УДК 372.881.1

Фатыхова Алия Ленаровна,
Казан федераль университеты

Туган (татар) телдән белем һәм күнекмәләргә мониторинг үткәрү системасы

татар теле, мониторинг, белем, күнекмә, система

XXI гасырның беренче дистә еллары татар теле, аны мәктәптә укыту процессы өчен шактый катлаулы булды. Мәктәптә татар телен укытудагы җитди үзгәрешләр (өйрәнелә торган предметның исеме, өйрәнү дәрәҗәсе, формалаштырыла торган компетенцияләр) кертелеп кенә калмады, татар теле дәресе мәктәптә хакыйкый урыны барлыгын расларга-дәлилләргә тиешле шартларга куелды. Мондый шартларда татар теле буенча белем бирү сыйфатын объектив бәяләү һәм аның тиешле дәрәҗәдә булуын тәэмин итү аерым әһәмияткә ия һәм монда да заман таләпләрен һәм тенденцияләрен тою, аларга нисбәтле рәвештә эш итү кирәк.

Соңгы елларда традицион *контроль, диагностика* төшенчәләре урынына ешрак *мониторинг* сүзе кулланыла. Терминга аңлатма А.Н. Майоров [Майоров 1998], В.А. Кальней [Кальней 1999], В.В. Гузеев [Гузеев 2000] кебек галимнәр тарафыннан бирелә. Шуларны гомумиләштереп, без мониторинг терминын – нәтиҗәләрне теркәү һәм анализлауга юнәлдерелгән тикшеренү эше, белем бирү өлкәсендә бу «укытучы – укучы» системасындагы тикшерү эшчәнлеге буларак аңлыйбыз. Әлеге эшчәнлек белем алу процессында укучыларның үсешен күзәтергә һәм үз вакытында кимчелек, җитешсезлекләрне юкка чыгарырга ярдәм итә. Мониторинг – укучыларның белем-күнекмәләрен, осталыкларын күзәтү, планлаштыру һәм тикшерүнең комплекслы системасы ул. Мониторингның мөмкинлекләре:

– билгеле бер уку периодында укучының белем динамикасын объектив бәяләү;

– динамика анализыннан чыгып, укытучының үз эшенә даими рәвештә коррективлар кертүе;

– укучының һәм тулаем сыйныфның көчле һәм йомшак якларын белү һәм аларга йогынты ясау.

Укучыларның белемнәрен даими тикшерү системасы буларак мәктәптә мониторинг куллану үзенчәлекле методика булдыруны таләп итә. Мәктәпләрдә мониторинг системасы барлык предметлар буенча да, шул җөмләдән, татар теле буенча да кулланыла. Ул үз эченә түбәндәге этапларны ала:

– мониторинг үткәрүгә әзерлек;

– мониторингны үткәрү;

– җыелган мәгълүматны анализлау;

– статистик интерпретация.

Татар теле буенча мониторинг үткәрүдә түбәндәге бурычлар куела:

– татар теле буенча уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен күзәтү;

– укучыларның индивидуаль мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру;

– укучыларның татар теле буенча уңыш-казанышларын билгеләү.

Мониторинг процессында түбәндәге төп сорауларга ачыклык кертелә:

– белем бирү процессы максатына ирешеләме?

– алдарак үткәрелгән диагностик тикшеренүләр нәтиҗәләре белән чагыштырганда уңай динамика күзәтеләме?

– укытучы эшен камилләштерү өчен алшартлар бармы?

– уку материалының катлаулылык дәрәҗәсе укучыларның мөмкинлекләре белән туры киләме?

Татар теленнән мониторинг, заман таләпләренә ярашлы рәвештә, предмет нәтиҗәләрен генә түгел, метапредмет һәм шәхескә юнәлгән нәтиҗәләргә дә кагылышлы. Әйтик, шәхескә юнәлгән нәтиҗәләр укучыларның үзүсешкә сәләтен, танып белү мотивациясенең формалашу дәрәҗәсен күрсәтәләр, социаль компетенцияләрне дә үз эченә алалар. Метапредмет нәтиҗәләр укучылар тарафыннан үзләштерелгән универсаль уку гамәлләрен үз эченә ала. Нәкъ менә предмет нәтиҗәләр татар телен өйрәнү дәвамында әлеге предмет өчен специфик булган фәнни белем нигезләрен, шушы предметны өйрәнгәндә үзләштерелгән тәҗрибә һәм аны куллана белүне чагылдыра.

Татар теленнән мониторингның үтә җаваплы һәм укуының белем сыйфатын тулы чагылдыра торган төре – Дәүләт йомгаклау аттестациясе. Ул тугызынчы сыйныф укучылары тарафыннан сайлап алынган имтихан буларак кабул ителә. Татар телен уку-укыту төрләренә нисбәтле рәвештә, мондый имтихан сораулары һәм биремнәрен дә өч төрле адресатка атап төзелә:

– татар мәктәбендә укучы татар балалары;

– рус мәктәбендә укучы татар балалары;

– рус мәктәбендә укучы рус телле укучы.

Шулай итеп, татар теле буенча белем бирү сыйфаты мониторингы ике факторның йогынтысын тоя, дип әйтә алабыз: белем бирүдәге үзгәрешләр, татар теле дәресенең мәктәп программасындагы урыны. Мониторинг татар теле предметын укыту үзенчәлекләрен исәпкә ала һәм өч төрле укучыларга атап төзелә. Мониторинг предмет белемнәреннән тыш, метапредмет һәм шәхескә юнәлгән нәтиҗәләрне дә чагылдыра.

ӘДӘБИЯТ

Гузеев В.В. Планирование результатов образования и образовательная технология. – М.: Народное образование, 2000. – 240 с.

Кальней В.А. Технология мониторинга качества обучения в системе «учитель-ученик». – М.: Педагогическое общество России, 1999. – 86 с.

Майоров, А.Н. Мониторинг как научно-практический феномен // Школьные технологии. – 1998. – № 5. – С. 25-48.

УДК 81ʹ342

Хадиева Гөлфия Камиловна,
Казан федераль университеты

Т.И. Ибраһимовның татар теле фонетикасы өлкәсендәге эшчәнлеге

Т.И. Ибраһимов, татар теле фонетикасы, иҗек, фонема, аваз

ХХ йөзнең җитмешенче елларында татар теле фонетикасында актуаль булган яңа юнәлешләрнең берсе кибернетика лингвистикасы (машина тәрҗемәсе) өлкәсендә фәнни хезмәтләре, эшчәнлеге белән

филология фәннәре кандидаты, доцент Тәүзих Ибраһимович Ибраһимов аерым урын алып тора.

Тәүзих Ибраһим улы Ибраһимов 1938 нче елның 23 октябрендә Оренбург өлкәсе Люксембург районының Ибрай авылында туа. Ул 1957 нче елда урта мәктәпне тәмамлый һәм Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә.

Студент елларының соңгы курсларында Т. Ибраһимов машина тәрҗемәсе белән мавыга башлый. 1960 нчы елларда Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетында физика-математика фәннәре кандидаты, доцент Н.А. Халитова җитәкчелегендә студентлар фәнни түгәрәге эшли башлый. Машина тәрҗемәсе буенча махсус курс укыла. Т.И. Ибраһимов фәнни түгәрәккә актив йөри. Курс һәм диплом эшләрен машина тәрҗемәсе буенча яза.

Т.И. Ибраһимов диплом эшендә машина белән рус теленнән татар теленә җөмләләр тәрҗемә итә. Татар теле белемендә өйрәнелмәгән, яңа, актуаль булган фәнни эш татар теле һәм әдәбияты кафедрасында зур кызыксыну уята.

Тәүзих Ибраһимович 1957-1962 нче елларда тарих-филология факультетында укый һәм КДУ каршында эшләп килгән Н.Г. Чеботарев исемендәге фәнни-тикшеренү институтына эшкә алына. Белемен тагын да тирәнәйтү максатыннан яшь белгеч 1966 нчы елда КДУның физика факультетына кичке бүлеккә укырга керә. Аны 1973 нче елда уңышлы тәмамлый.

1964 нче елда аның «Вероятностные методы и кибернетика» дигән җыентыкта «Оценка взаимосвязи букв в татарском литературном языке» дигән беренче мәкаләсе басылып чыга. Бу мәкаләдә хәрефләрнең тел системасында мәгълүмат системасының бер төре буларак бәяләнә.

Т.И. Ибраһимов эшләре нигездә гамәли характерда булды һәм тематика буенча үз вакыты өчен актуаль булган бурычларга туры килде. 1970 нче елларда кибернетик лингвистикада шундый проблемаларныңберсе сөйләмнең барлыкка килүен һәм кабул ителүен тикшерү булган. Сөйләмне кабул итүнең мотор теориясе кысаларында Т. Ибраһимов сөйләмне оештыру иҗеген, шулай ук татар теленең иҗек төзелешен экспериментальь тикшеренүләр үткәреп өйрәнә.

Ул 1970 нче елда филология фәннәре докторы, профессор Д.Г. Тумашева һәм физика фәннәре кандидаты, доцент Н.А. Халитова җитәкчелегендә «Изучение образования слогов и структуры их сочета-

ний в татарском литературном языке» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.

Иҗек – иң кечкенә әйтелеш берәмлеге һәм иң элек анда телнең аваз системасы үзенчәлекләре чагыла. Т.И. Ибраһимов заманча ысуллар кулланып, татар иҗекләренең барлыкка килүүзенчәлекләрен, төзелешен, ешлыгын, иҗектә фонемаларның үзара бәйләнешен тикшерә. Ул иҗекләр барлыкка килүне психолингвистик аспектта аңлата. Галим диссертациясендә эксперименталь, математик статистика һәм мәгълүмат теориясе методлары кулланып, татар теле сүзләрен сөйләм материалы да, фонема да буларак өйрәнә.Тарихи мәгълүматларга да игътибар бирә. Нигез итеп алынган акустик, артикуляцион билгеләрнең характерыннан чыгып, ул иҗекләрне акустик, физиологик, физиологик-акустик һәм психолингвистикалымнар белән тикшерә. Автор шулай ук түбәндәге мәсьәләләрне карый: а) иҗекләрнең төзелешеиҗек ясамаган фонема тезмәләретөзелешеннән аермасы; б) хәзерге татар телендәге иҗекләрнең типлары һәм конструкцияләре; в) язма телнең төрле стильләрендә билгеләнгән конструкцияләрнең ярашуы; г) татар теле сүзләрендә иҗек барлыкка килү.

Т.И. Ибраһимов түбәндәге нәтиҗәләрне ясый: беренчедән, иҗек эчендәге фонемалар, сүзнең башка иҗекләрендәге фонемаларга караганда, үзара ныграк бәйләнгән; икенчедән, сүздәге сүз ахыры позициясендәге фонеманың озынлыгы иҗек башындагы яки уртасындагы шундый ук аваздан озынрак әйтелә.

1986 нчы елда Т.И. Ибраһимов филология факультетына өлкән укытучы булып эшкә күчә, студентларга «Прикладная лингвистика» курсын укый, информатика буенча теоретик һәм гамәли дәресләр алып бара.

90 нчы еллардан соң Т.И. Ибраһимов Казан дәүләт университеты һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе бергә төзегән ясалма интеллект лабораториясе белән актив хезмәттәшлек итә. Бу лабораториядә ул татар сөйләме синтезаторын эшләүдә катнаша. Казан университетында аның уку-укыту эше тагын да киңәя. Ул «Информатика һәм математика» дигән гомуми курсны, шулай ук «Социолингвистикага кереш», «Чит телгә өйрәтүдә психолингвистика», «Прикладная фонетика» дигән махсус курслар укый. Курс һәм диплом эшләренә җитәкчелек була, аспирантлар әзерли.

А.Н. Туполев исемендәге КДТУның гуманитар факультеты студентларына татар телен өйрәтә. Студентларны укыту максатыннан

«Ускоренное обучение татарскому языку» (1993, 1994) дәреслеген бастырып чыгара.

Галим тел белеменең төрле тармаклары белән кызыксына. Ул компьютер һәм когнитив лингвистика өлкәсендә эшләүче математиклар белән актив хезмәттәшлек итә.

Т. Ибраһимов үзенең шәкертләре белән бергә, ритмик төркемнәрнең просодик структурасын һәм фраза, җөмләләрнең интонацион төзелешен тикшерә. Ул татар сөйләмен автомат синтезлау проблемасы белән шөгыльләнеп, түбәндәгене билгели: татар теле өчен сүз басымы хас түгел, ягъни сүзне әйтү процессында ниндидер иҗек аерып чыгару өчен өстәмә көч куелмый. Фонетистлар тарафыннан соңгы иҗекнең беркадәр көч белән әйтелүе әлеге сүзнең сүз басымы белән түгел, ә ритмик төркемдәге урыны (аның ритмик төркемнең ахырында килүе) белән аңлата.

Галимнең 100 дән артык мәкаләсе, студентлар өчен уку-укыту әсбаблары, дәреслекләре, монографиясе басылып чыга. Мәкаләләре сөйләм процессында фонемаларның позицион һәм контекстта үзгәрешләре, сүз басымының фонетик табигате һәм функцияләре, татар телендә сүз просодиясе һәм җөмләнең интонациясе, татар теленең фонемалар составын билгеләүгә багышлана [Ибрагимов 2009].

Т.И. Ибраһимов хезмәтләрендә, Л.В. Щерба һәм аның тарафдарлары тәгълиматына таянып, татар теленең фонологик системасында 9 сузык һәм 23 тартык фонеманы (барлыгы 32 фонема) ачыклый. Татар сөйләмен автомат синтезлау системасында әлеге сандагы сузыклар һәм тартыклар фонемасы телнең язма формасын һәм телдән яңгырашының табигый булуын тәэмин итә алуын әйтә [Казанская 2008].

Тәүзих Ибраһимов М.Р. Сайхунов, И.Ф. Сәлимҗанов белән берлектә 116 млн. сүз күләмендәге «Татар теленең язма корпусы»н булдыруга күп көч куйды. Монда сүзләрнең язылышын һәм нинди текстларда урнашуын күреп була.

Язма корпус телчеләргә сүзформаларның кулланылыш ешлыгын, аларның үз чолганышындагы сүзформалар белән мөнәсәбәткә керү мөмкинлекләрен бәян итә. Хәзерге халәтендә «Татар теленең язма корпусы» репрезентативлык һәм төрле стильләрне телгә бәрабәр күләмдә чагылдыру таләпләренә тулысынча җавап бирә [Письменный 2012].

Соңгы елларда Т.И. Ибраһимов, Ф.И. Сәлимов, Р.Р. Хөсәенов, М.Р. Сайхунов текст буенча татар сөйләмен автомат рәвештә синтезлау системасын эшләделәр.

2021 нче елда Т.И. Ибраһимов һәм М.Р. Сайхуновның «Звуковой строй татарского языка: Социолингвистический и прикладные аспекты» дигән монографиясе басылып чыкты [Ибрагимов 2021]. Хезмәт актуаль мәсьәләләргә багышланган: татар теленең аваз төзелешен социолингвистик һәм лингвокультурологик аспектларда комплекслы өйрәнүгә юнәлтелгән. Эш татар теленең гамәли экспериментaль фонетикасының фәнни проблемаларын яктырту һәм чишелә торган проблемаларның яңалыгы белән аерылып тора.

Фәнни хезмәттә татар сөйләменең сузык һәм тартык авазлары тасвирлана, аларга классификация бирелә. Хезмәттә лингвист И.А. Бодуэн де Куртенэ, тюркологлар В.А. Богородицкий, Г. Шәрәф идеяләре һәм фикерләре киң кулланыла. Татар фонетикасын өйрәнү тарихы яктыртыла. Экспериментaль фонетика өлкәсенә караган фәнни эшләр анализлана.

Татар теле морфологиясе телнең фонетик төзелеше белән тыгыз бәйләнгән һәм артикуляцияне гадиләштерү тенденциясен таба. Эштә автоматик танып белү һәм сөйләмне синтезлау күзлегеннән караганда иң гомуми һәм әһәмиятле булган татар теле морфемасы үзенчәлекләре карала.

Авторлар татар теле акцентологиясен сөйләм синтезаторы ярдәмендә тикшерәләр. Цифрланган материалны анализлау GoldWave, CoolEdit, WinPitchPro һәм Speech Analyzer программалары чаралары тарафыннан гамәлгә ашырылган. Speech Analyzer программасы чаралары ярдәмендә иҗекләрнең чикләре билгеләнгән, аларның дәвамлылыгы, шулай ук сүз башы, сүз уртасы һәм сүз ахырында килгән иҗек ясаучы сузыкның төп тон ешлыгы һәм интенсивлыгы тикшерелә. Экспериментaль фонетик анализларга нәтиҗә ясап, авторлар, татар теленә сүз басымының хас булмавы турындафикерләрен әйтәләр.

Монографиядә татар теленең аваз төзелеше социологик һәм лингвокультурологик аспектларда каралган. Татар теленең хәзерге торышы, эшчәнлеге, тарихы турында мәгълүматлар китерелә. Шулай ук татар теле өчен сөйләм синтезаторының экспериментaль үрнәген булдыру тәҗрибәсе бәян ителә. Татар сөйләме синтезаторы фонология, интонация мәсьәләләрен, сөйләмгә семантик-синтаксик анализ үзенчәлекләрен һ.б. хәл итә.

Авторлар беренче тапкыр Speech Analyzer программасының компьютер технологияләре ярдәмендә сөйләм эшчәнлеген анализлау өчен фонетик күренешләр нәтиҗәләрен тәкъдим итәләр. Хезмәттә татар теле фонетикасы буенча белемнәрне киңәйтергә мөмкинлек бирә торган бай иллюстратив материал һәм таблицалар тәкъдим ителә.

Монография татар фонетикасы проблемаларына багышланган, заманча гамәли татар фонетикасының актуаль мәсьәләләренә яңа караш булып тора.

ӘДӘБИЯТ

Ибрагимов Т.И. Вопросы интонационного синтеза татарской речи. Реконструкция ритмики письменного текста / Т.И. Ибрагимов, М.Р. Сайхунов // Труды Казанской школы по компьютерной и когнетивной лингвистике TEL – 2008. – Казань: Изд-во Казан. гос. ун-та, 2009. – С. 123-128.

Ибрагимов Т.И. К проблеме реконструкции звучания письменного текста. Редукция кратких гласных в татарском языке / Т.И. Ибрагимов, М.Р. Сайхунов // Ученые записки Казанского государственного университета. Серия гуманитарные науки. Книга 3 / науч. ред. М.Х. Салахов. – Казань: Изд-во Казан, гос. ун-та, 2009. – С. 288-298.

Ибрагимов Т.И. Звуковой строй татарского языка: социолингвистический и прикладные аспекты / Т.И. Ибрагимов, М.Р. Сайхунов. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2021 – 142 с.

Изучение образования слогов и структуры их сочетаний в татарском литературном языке: дис. … канд. филол. наук. – Казань, 1970.

Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / сост. М.З. Закиев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. – 424 с.

Письменный корпус татарского языка [Электронный ресурс] / М.Р. Сайхунов, Т.И. Ибрагимов. Казань, 2012. Режим доступа: http://corpus. tatfolk.ru

УДК 82-91

Халиуллина Алсу Мәсхүтовна,

Идел буе районы Казан шәһәренең 106 нчы балалар бакчасы

Татар әдәбиятында әкият жанрының формалашуы һәм үсеше

халык әкиятләре, татар теле, Каюм Насыйри

Әкият – халык авыз иҗатының борынгы, шул ук вакытта киң таралган һәм мавыктыргыч жанрларыннан берсе [Гатина, Ярми 1977: 7].

Әкият жанрында халыкның тормыш тәҗрибәсе, җыелып килгән зирәклек, тапкырлык, яхшылык һәм явызлык турындагы күзаллаулар тупланган, аның хыяллары һәм киләчәккә өметләре чагылдырылган. Әкиятләр явызлыкны хөкем итә, гаделлекне, дөреслекне яклый, кешеләрдә игелеклелек, тугрылык һәм мәрхәмәтлелек тәрбияли.

«Әкият» сүзе гарәп теленнән алынган. Ул «хикәят» дигән сүзнең фонетик үзгәрүе ярдәмендә барлыкка килгән. Бүгенге көндә дә кайбер кешеләр әкиятне хикәят дип атаучылар бар.

Фольклористикада әкиятләрне гадәттә төп өч төркемгә аеру яшәп килә:

– хайваннар турындагы;

– тылсымлы;

– тормыш-көнкүреш әкиятләре [Татар әдәбияты 2006: 94].

Халык әкиятләре беренче булып барлыкка килә. Алар борынгы заманнарда ук булган, ул вакытта әле басма китаплар да, заманча технологияләр дә булмаган.

Әкиятнең башлангыч чыганагы булып, тормышта булган вакыйгалар хезмәт итә. Кешеләр ишеткәннәрен һәм күргәннәрен бер-берсенә сөйләгәннәр. Ләкин кешегә могҗизаларга ышану һәм хыяллану теләге хас булганлыктан, күп «сөйләү» процессында чын вакыйгалар вакыт узу белән «яңа кызыклы детальләр белән тулган», бизәлгән, гаҗәеп нәрсәгә әверелгән. Әкиятләр шулай барлыкка килгән.

Борынгы кеше дөньяның, кешенең һәм гомумән җанлы һәм җансыз табигатьнең барлыкка килүен, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, кешеләр тормышындагы төрле хәлләрне – барысында мифологик карашлар нигезендә аңлаган, һәм аларның аңлатмалары миф – мифик риваять (миф-быличка) формасында йөргән. Бу хикәяләрнең бер өлеше изге итеп саналган. Алар теләсә кайда, теләсә кайчан һәм теләсә кемгә сөйләнмәгән. Мондый хикәяләрне сөйләү изге йоланы үтәү белән бергә алып барылган һәм бары тик балигъ булган кешеләргә генә җиткерелгән, ягъни мифлар ритуал белән тыгыз бәйләнештә булган. Гамәли вазифа үтәгән бу мифик риваятьләр әкиятнең иң борынгы формасы дип санала [Мелетинский 1960: 86-87].

Л.Ш. Җамалетдинов фикеренчә, «иҗтимагый практиканың, беренче чиратта, матди җитештерүнең үсүе нәтиҗәсендә, кешенең рухи дөньясы киңәя һәм, шуның белән бәйле рәвештә, эстетик ихтыяҗ туа. Бу ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен рухи азык, әлбәттә инде, шул чордагы

бердәнбер чыганактан – идеологик синкретизмнан алынырга тиеш була» [Җамалетдинов 2015: 8-9].

Эстетик ихтыяҗ үсә барган, үскән саен ул төрлелек таләп итә башлаган. Аларның нәтиҗәсе булып, халык иҗатының төрле жанрлары барлыкка килгән. Шул жанрларның берсе булып әкият тора.

Чын мәгънәсендәге әкиятнең туу вакыты ул – нәкъ менә изге хикәянең (әкият «баба»сының) нәфис хикәягә әверелеп киткән чагы [Пропп 2000: 336]. Бу хәл исә изге хикәянең ритуалдан аерылуы нәтиҗәсендә була, чөнки йоланы барлыкка китергән шартлар вакытлар узу белән бетә (аларнын иң мөһиме – аучылыкның бердәнбер яки төп яшәү чыганагы булудан туктавы). Бу исә, үз чиратында, әүвәлге изге мәгънәдәге йоланың да бетүенә китерә, йоладан аерылган хикәя шулай ук үзенең «изге»леген җуя һәм барлык кешеләр өчен дә сөйләнелә башлый. Әкиятнең шушы рәвешчә мөстәкыйль жанр булып формалашып житүе борынгы община строеның таркалу чорына туры килә [Мелетинский 1960: 87]. Әкиятнең гамәлилектән арынып, эстетик вазифалар үти башлавы шул чорга туры килә. Шуңа да карамастан, әкиятнең идеясе, ягъни вазифасы да мөһим урынны алып тора. Мәсәлән, әхлакый, иҗтимагый һ.б.

Шулай итеп, әкият, берничә гасыр дәвамында камилләшеп, тулы бер әдәби жанрга әверелә.

Әкиятең сюжетында, төзелешендә мөһим урынны уйдырма алып тора.

Уйдырма ул – кешенең уйлап чыгарылган фантазиясе. Әмма һәр фантазия дә уйдырма була алмый. Уйдырма булсын өчен материал, тормыштагы хәлләр, вакыйгалар кирәк. Тормышта әлеге вакыйгалар, материаллар барлыкка килеп торган. Мәсәлән, кеше белән табигать арасындагы каршылык, искелекнең яңалык белән көрәше, гомумән, искелекне кабул итмәү, тормыштагы бүтән төрле хәл-вакыйгалар, кешеләрнең бер-берсе белән мөнәсәбәтләре һ.б.

Борынгы әкиятләрдә кешеләр, хайваннар яки кешеләргә бик охшаган, әмма сихри көчкә ия булган затлар сурәтләнгән. Мәсәлән, алар кирәк булганда күзгә күренмәс була алганнар, үз тәннәрен үзгәртә алганнар һәм хайваннарга һәм кошларга әверелгәннәр, стеналар аша үткәннәр, киләчәкне алдан әйткәннәр.

Мондый әкиятләрне халык әкиятләре дип атыйлар. Аларның билгеле бер авторы юк һәм алар халык тарафыннан язылган дип әйтәләр.

Мондый әкиятләр буыннан-буынга телдән тапшырылган, аларда халык тарихы, аның өметләре һәм хыяллары сакланган.

Вакыт узу белән, тирә-юньдәге дөнья үзгәрү белән, яңа көнкүреш әйберләре, яңа технологияләр һәм яңа мөмкинлекләр барлыкка килү белән, кешеләрнең фантазияләре дә, әкият геройларының образлары да үзгәрә.

Шуңа күрә һәр халык әкиятенең, гадәттә, берничә варианты булган, вакыт узу белән хикәяченең фантазиясенә һәм теге яки бу халыкның яшәгән җиренә бәйле рәвештә үзгәргән.

Татар телендәге беренче әкиятләр М. Ивановның «Татарская грамматика» хезмәтендә 1842 елда басылып чыга. Алга таба 1859 елда С. Күкләшевнең «Диване хикәяте татар» хезмәтендә фольклор әсәрләре урын ала. Аларның кайберләре М. Иванов дәреслегеннән алынганнар. 1872 елда В.В. Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен» хезмәте басылып чыга. Галим биредә Себер татарларының фольклорын өйрәнеп, әкиятләр турында да мәгълүматлар бирә. 1875 елда венг галиме «Казан татарларын теле» хезмәтен бастырып чыгара. Китапта әкиятләр дә урнаштырылган. Шунысын да билгеләп үтик: галим татар телен, халык иҗатын өйрәнү өчен махсус Казанга килә.

1890 елда Габделгалләм Фәезхановның «Хикәят вә мәкаләт» исемле китабы басылып чыга. Китапта 12 әкият, 3 бәет һәм 500 дән артык мәкаль урнаштырылган. Әлеге җыентыктагы кайбер әкият текстлары Таип Яхинның бары тик тәрҗемә әсәрләрдән торган «Сабый вә сабыяләр өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәнбиһ өчен гаҗаиб булган гыйбрәтләр» (Казан, 1897) дигән җыентыгында да басылган. 1898 елда Н.Ф. Катановның «Материалы к изучению казанско-татарского наречия» хезмәтендә Г. Фәезханов китабындагы әкиятләр кабат дөнья күрә.

1900 елда Т. Яхинның «Дәфгылькәсәл мин әссабый вәсабыят» китабы басылып чыга. Китапка 100 гә якын текст урнаштырылган. Әлеге текст арасында тәрҗемә әсәрләре дә күп. Шуңа да карамастан, бу җыентыкта оригиналь булган әсәрләр дә бар.

Татар теленең күренекле мәгърифәтчесе К. Насыйри да татар халык иҗаты, шул исәптән әкиятләр җыю белән мәшгуль булган. Аның тупланган әкиятләрен кулланып, П.А. Поляков «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру» дип аталган хезмәтен язган.

1915 елда Г. Рәхимнең «Халык әкиятләре» исемле җыентыгы; 1924 елда М.А. Васильев татар әкиятләрен легендалары белән бергә туплап, рус телендә җыетык чыгара.

30 елларның икенче яртысында Г. Толымбай татар халык иҗатын туплаган, өйрәнгән. Совет чорында татар халык әкиятләрен өйрәнү, җыю һәм бастырып чыгару Г. Бәширов, Х. Ярми, Э. Касыймов, Ф. Әхмәтова тарафыннан башкарылган.

1977 елда «Татар халык иҗаты» сериясендә фольклор әсәрләре басылып чыга. Беренче һәм икенче китапта әкиятләр урнаштырылган.

Җыелган әлеге хәзинә – халкыбызның бик кыйммәтле, мөһим булган рухи байлыгы. Фольклорчылар, галимнәр алдында бу байлыкны саклау, үстерү, арттыру, бастырып чыгару һәм төрле яклап өйрәнү, тикшерү бурычы тора.

ӘДӘБИЯТ

Җамалетдинов Л.Ш. Татар әкиятләрен барлау юлында / төз. И.И. Ямалтдинов. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 264 б.

Мелетинский Е.М. О генезисе и путях дифференциации эпических жанров // Русский фольклор. Материалы и исследования. V. М. – Л., 1960. – С. 86-87.

Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки. – М.: Лабиринт, 2000. – 416 с.

Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Беренче китап / төз.: Х. Гатина, Х. Ярми. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 482 б.

УДК 377.8:811

Харисов Фираз Фахразович,
Казан федераль университеты

Мәгърифәтле булуның нигезе

тел, сөйләм, мәгърифәт, прогресс, мәгълүмат, әдәби норма

Туган телебездә, бигрәк тә аның язма сөйләм формасын чагылдырган вакытлы матбугатта һәм радио-телевидениедә соңгы елларда борчылырлык урыннарның күп булуы турында тәфсилләп язылган хезмәтләр авторы – Татарстан фәннәр академиясе академигы, филология фәннәре докторы, профессор Р.А. Юсуповның эшчәнлеге аерым

урын алып тора. Ул әледән-әле шушы проблемаларны яктырткан зур күләмле хезмәтләрен укучылар хөкеменә тапшыра. Күптән түгел генә аның *«Мәгърифәт – прогрессның нигезе. – Просвещенность – основа прогресса»* исемле китабы [Юсупов 2023: 447] дөнья күрде. Исеменнән үк күренеп тора: автор анда үзен бик борчыган проблемаларны – милли мәгариф һәм мәдәниятнең кичекмәстән игътибар үзәгенә алынырга тиешле мәсьәләләрен күтәрә. Һәрвакыттагыча алар ике телдә – хәзерге татар һәм рус әдәби телләренең әдәби нормаларына хилафлык китермичә язылган.

Баштан ук шуны да искәртеп куйыйк: максатыбыз – укучыларны әлеге китапка хас булган өстенлекле сыйфатлар белән генә таныштырудан бигрәк (ә алар, һичшиксез, шундыйлар!), аның эчтәлегенә юнәлтү. Шуның өчен авторның хезмәтендә урын алган язмаларның исемнәренә күз салыйк: «Хокукларыбыздан тулы файдаланыйк», «Кайчан дөрес сөйли һәм яза башларбыз икән?» «Үзебездән тора», «Сумеем ли сохранить наш литературный язык?» «Дөрес дәреслекләр кирәк», «Сүзләрне дөрес кулланыйк», «Иң мөһим бурычлар», «Насущные задачи», «Совершенствование учебного процесса», «Тынычланып йөрер чак түгел», «Не время для успокоения», «Матбугатны яратыйк» һ.б.

Академик Р.А. Юсупов китабында яктыртылган проблемаларга игътибар белән карасак, бер нәрсә бәхәссез: бу китапны шартлы рәвештә өч зур бүлеккә аерып була.

Беренчесе – инде югарыда саналган темалар (проблемалар) тормышыбызның төрле өлкәләрендә кулланыла торган туган телебезнең сафлыгын, чисталыгын, дөреслеген саклауга, яклауга, аны киләчәк буыннарга тиешле дәрәҗәдә җиткерү өчен,ниләр кылырга кирәклеге хакында. Автор бу мәсьәләнең көн тәртибенә бик кискен куелышы турында чаң суга: «... халкыбыз гыйбрәтле тарихы, алдынгы мәдәнияте, күркәм сыйфатлары турында тиешле, уңай, объектив мәгълүматтан мәхрүм ..., чөнки мәктәпләрдә татарларның тулы объектив тарихы укытылмый, дөнья күләмендә мәгълүм бөек шәхесләре турында тиешле информация бирелми, ... татарча газета-журналлар, әдәбият укучылар бик аз ...» [Юсупов 2023: 7-8]. Нәтиҗәдә, кызганычка каршы, телдән һәм язма сөйләмдә татар теле күренешләрен хаталы куллану очраклары киң таралган: сүзләр ялгыш мәгънәдә кулланыла, телебезгә хас булган гадәти сүз төзелеше калыпларына туры килми торган лексик берәмлекләр тарала, җөмләдәге сүз тәртибен рус телендәгечә оештыру, аерым сүз

төркемнәренең табигый формалары бозылу һ.б. Бер сүз белән әйткәндә, дөньядагы иң камил 14 тел арасында үзенең лаеклы урынын тапкан татар теле шул рәвешчә кыерсытыла, җәберләнә, рәнҗетелә. Боларны кем шулай эшли? Кем гаепле? – дигән сорауларга автор «Үзебездән тора», «Сүзләрне дөрес кулланыйк», «Тынычланып йөрер чак түгел», «Матбугатны яратыйк», «Мәгърифәт – прогрессның нигезе» исемле язмалары белән җавап биреп тә бара.

Югарыда әйтелгәнчә, Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов үз хезмәтендә яктырткан проблемаларның килеп чыгу сәбәпләрен генә санап чыгу белән чикләнми. Тел галимнәренә хас булганча, иң башта аларга җентекле анализ ясый, фикерләрен күп төрле басмалардан алынган фактик материаллар (мисаллар) белән нигезләп, ничек булырга тиешлеге хакында укучыга барып җитәрлек, ягъни аңлаешлы итеп тасвирлый. Бу урында шуны да искә төшерик: автор – әле узган гасырның 60 нчы елларыннан ук тәрҗемә теориясе мәсьәләләре белән җиң сызганып шөгыльләнгән күренекле галим, ярты гасырга якын гомерендә югарыда саналган проблемалар эчендә «кайнаган», шул өлкәләрдә эшчәнлек күрсәткән күп санлы шәкертләренең (алар арасында телче-филологлар да бихисап!) икетеллелек һәм күптеллелек өлкәләрендә дә үз фикерен үтемле итеп җиткерә белүче остазы. Димәк, безнең замандашыбыз – китапта әйтелгән фикерләрне раслауда «янәшә гомер кичергән» татар һәм рус телләренең уртак һәм аермалы якларының телдән һәм язма сөйләмебезгә йогынтысы хакында әйтерлек уйтеләкләре белән уртаклашучы аксакал.

Р.А. Юсуповның әлеге саллы хезмәтенең һәр бите телебез өчен чын күңелдән борчылу, аның киләчәге хакында уйланулардан гыйбарәт. Бу фикеребезне раслау өчен, мисаллар китапның һәр битендә тулып ята. Алар безнең фикерләр белән дә тәңгәл килә. Мәсәлән, 49 нчы биттә *яңгырау, яңгырату* сүзләре, рус телендәге *живой* сүзе, 50 нче биттәге төрле бәйрәмнәр белән татарча котлау формаларындагы җитешсезлекләр – болар барысы да рус теленнән уйламыйча тәрҗемә ителгән калькалар *(С днем рождения!).* Безнең халык бәйрәм котлавына фигыль дигән сүз төркеменнән бик үтемле бер сүз өстәп, аның мәгънәсен көчәйтә: *Туган көнең (көнегез) белән котлыйм!*

Әйе, соңгы елларда сөйләмебезнең телдән һәм язма формаларына рус теленең йогынтысы бермә-бер артты. Кече яшьтәге балалардан башлап, урта һәм югары уку йортларында татар теле укыту сәгать-

ләренең кискен рәвештә кимүе, әлеге чынбарлыкны бигрәк тә аяныч хәлгә калдыра, мәсәлән, «мескен» [h] авазының әйтелешен генә алыйк, хәзер аны бозмыйча әйткән кешене табуы хәтта кыен (40 нчы бит). Югары филологик белемле укытучылар әзерләүне “бакалавр” формасында алып бару да уңай нәтиҗәләр бирми, чөнки телебезнең үзенә генә хас булган аһәңле яңгырашын, лексик берәмлекләренең төзелешен, формаларының байлыгын, сөйләм калыпларының киң кырлы мөмкинлекләрен яшь буын – киләчәктә телне өйрәтәчәк белгечләр күрми-белми кала. Еш кына айбер әти-әниләрнең ана теленә битараф булуы, аңа кимсетеп каравы эшне тагын да катлауландыра, милләтебезнең теленә һәм әдәбиятына, тарихына, рухи байлыкларына карата балаларның мөнәсәбәтен дә тискәре якка үзгәртә. Нәтиҗә – бүгенге чынбарлык! Шушы хәлләр аркасында, рус теленә ияреп, телебездәге күп кенә сүзтезмәләрне кушып «язу модасы» таралды. Менә кайбер мисаллар: *республикакүләм конференция (республика конференциясе), микән (ме+икән)* һ.б. [Юсупов 2023: 41]. Рус телендәге *словообразование* терминын татарчага *сүзъясалышы* дип калькага әйләндерү дә яхшы үрнәк түгел, чөнки анда (рус телендә) *соединительное гласное* булу бу типтагы сүзләрне ясарга мөмкинлек тудыра (самолет, пароход).

Тел өлкәсендә тагын бер киң таралган чир – ул да булса кайбер нисби сыйфатларның кулланылыш үзенчәлеге. Башта кыскача бер мәгълүмат бирик: татар телендә бу сүз төркемендә ике төркемчә – асыл һәм нисби сыйфатлар бар. Телебездәгы сыйфатлар, ачыклап килгән исем янында – сыйфатланмыш алдында килгәндә төрләнмиләр: *бүгенге көн*, *хәзерге вакыт.* Татар телендә асыл һәм кайбер нисби сыйфатлар җөмлә эчендә сыйфатланмышсыз да кулланыла ала. Бу – фәнни әдәбиятта сыйфатларның исемләшүе дип атала (әлеге очракны исем ясалу белән бутарга ярамый!). Исемләшкән очракта, ягъни сыйфатланмышы булмаса, сыйфат вакытлыча, тартым яисә килеш кушымчасы белән кулланыла ала: *бүгенгене (көнне* сүзе кулланылмаганда*) онытмыйк.* Димәк, *бүгенгесе көн, хәзергесе вакыт* дип сөйләү – һич кенә дә ярый торган эш түгел (*көн, вакыт* сүзләре – сыйфатланмышлар, алар төшеп калмаган!). Сүз уңаеннан искә төшерик: бик киң таралган әлеге сөйләм хатасы турында үз вакытында Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев тә мәкаләләренең берсендә болай дип язган иде: *«Быелгысы елда» – монысы колхоз җитәкчеләре телендә – иң актив сүз.*

«Быелгысы» сүзе дөрес түгел, чөнки «быелгы» сүзе белән бөтенесе дә әйтелде инде» [Мәһдиев 2009: 212].

Р.А. Юсупов үзенең китабында тел һәм сөйләм хаталарын тел ярусларының барысыннан да алынган мисаллар үрнәгендә тасвирлый. Әйтик, «татар теленең үткән заман фигыльләре» дигән материалда ул рус телендә үткән заманның *ехал, шел, сделал, принес, посмотрел* сүзләре мисалында бер генә формада кулланылуын искәрткәч, телебездәге бу заманның гаҗәп дәрәҗәдә бай – төрле формаларда кулланылуын хезмәтенең 54-56 нчы битләрендә раслый да матбугатта очраган бик күп мисалларга мөрәҗәгать итә. Әйе, кызганычка каршы, хәзерге вакытта татар теле белемендә «билгеле һәм билгесез үткән заман» дип йөртелгән *-ды/-де, -ты/-те* формаларын гына куллану инде гадәти бер хәлгә әверелде. Күрәбез: бу – телебезнең мөмкинлекләрен күләгәдә калдыру, ярлыландыру. Укучыда «ни өчен бу шулай?» – дигән сорау туар. Сәбәбе бик гади: татар телендә ярдәмче фигыльләр заманнарны, фигыль дәрәҗәләрен формалаштырганда, төрле сүз төркемнәреннән фигыль ясаганда бик киң кулланыла, тик алар мәктәптә өйрәнелми (хәтта татар мәктәпләре өчен дә мондый материал авыр дип санала, шулай да элегрәк бу теманың бер өлеше программада бар иде). Бу урында шул да мәгълүм булсын: колакка ятышсыз ишетелә торган сүзләр арасында *хезмәт кую* сүзе дә очрый [Юсупов 2023: 53]. *Кую* сүзе туры мәгънәсендә *(өстәлгә кую),* еш кына фигыльнең кинәтлек-тизлек дәрәҗәсендә аз гына вакыт эчендә үтәлгән эш-хәрәкәт мәгънәсендә *(карап кую)* килә алуы мәгълүм. Әмма бездә *эшли,* контекстка бәйле рәвештә *хезмәт итә* сүзләре дә бар. *Ит* – төрле сүз төркемнәрен ясауда бик актив кулланыла торган ярдәмче фигыль. Әлеге төгәлсезлекләр чыннан да студент-бакалаврларга, фигыльләрне җентекләбрәк өйрәнү өчен, сәгать саны җитмәвен күрсәтә. Ә менә журналистларга ул бик кирәк булыр иде! Хөрмәтле галимебез үзенең 30-40 еллар элек басылып чыккан хезмәтләрендә үк бу турыда кисәтә килде.

Шушы ук сүз төркеменең сыйфат фигыль дип аталганформасы турында автор «фигыльләрне куллану өлкәсендәге хаталарның күбесе сыйфат фигыльләр. Сәбәбе – ... мәгънә үзенчәлекләрен белеп бетермәү ..., ... һәрвакыт диярлек *эшләүче, баручы* формалары гына кулланыла» [Юсупов 2023: 55], – дип искәртүе белән дә бик хаклы, чөнки матбугатта фәкать *-учы/-үче* формасына гынаөстенлек бирелә. Ә бит сыйфат фигыльнең заманнары алты. Без бу урында авторның фикерләрен хуплап

һәм дәвам итеп, телебезнең эчке һәм бик матур үзенчәлеге турында тагын шуны да өстик: татар телендә *-учы/-үче* формасындагы сыйфат фигыльләр затны белдергән исемнәр алдында (апа, абый, агроном, укытучы, укучы һ.б.) кулланыла. Хәзерге заман сыйфат фигыльнең тезмә формасы (*бара торган* яисә *килә торган кеше*) предметның даими үтәлә (яки үтәлми торган) эш-хәрәкәтен аның (предметның) билгесе итеп белдерә. Димәк, алар арасындагы аерма шактый зур икән, ләбаса!

Фигыльләр турындагы сүзебезне дәвам итеп, телебездә бу сүз төркеменең башкаларын ияртү (ияртүле бәйләнеш барлыкка китерү) үзенчәлеген искә төшермичә булмый, чөнки хәзерге вакытта *файдалану, куллану* кебек сүзләр алдына бәйлекләр өстәү гадәти хәлгә әверелеп бара: *китапны файдалану* дип әйтәсе урында, *китап белән файдалану* кебек сүзтезмәләр еш очрый [Юсупов 2023: 38]. Моның сәбәбе – безнең уебызча, сүзләрнең, бу очракта фигыльләрнең, лексик мәгънәләрен аңламауда, чөнки телефон, телевизор кебек җайланмаларга ябышып яткан чорда, әдәби әсәрләр укырга вакыты да, теләге дә булмаган яшь буынның сүз байлыгы көннән-көн ярлылана, саега бара.

Р.А. Юсупов язган хезмәт исемнәре (бу очракта кайбер китапларының исемнәрен генә истә тотабыз) үзләре дә телебез, халкыбыз һәм гомумән яшәешебезне чагылдырган афоризмнардан гыйбарәт: «Инсафлының теле саф», «Җылы сүз җан эретә», «Әдәп башы – тел», «Икесен дә яхшы бел», «Туган тел – милләтнең нигезе» һ.б. Аларның буеннан-буена милли мәгарифнең киләчәге, телебезнең сафлыгы өчен борчылу, киләчәктә әлеге проблемаларны хәл итүгә караган уй-фикерләре белән уртаклашу кызыл җеп булып сузылып килә. Гомерен уку-укыту эшенә, фән өлкәсенә багышлаган күренекле замандашыбыз киләчәккә өмет белән карый, оптимистик рухта эшли, яңадан-яңа хезмәтләр иҗат итә.

Рүзәл Абдуллаҗан улының әлеге китабының бер өлеше башкаларыннан бераз аерылып тора. Автор хаклы рәвештә тәрбия һәм тәртиплелекне «кешелек җәмгыяте тормышының нигезе», – дип атый һәм үзенең тәрбия программасын тәкъдим итә. Ул әхлакый тәрбияне беренче урынга куя, укыту-тәрбия бирү эшендә элек һәм хәзер яшәп килгән кимчелекләрне, алар арасындагы аермаларны тормыштан алынган мисаллар белән раслый. Хезмәт тәрбиясенең яшь буын өчен аеруча әһәмиятле булуын, балаларны чын кеше, үз иленең патриотлары итеп тәрбияләүдә, эстетик тәрбия өлкәсендә дә хәл ителәсе мәсьәләләргә

туктала. Әлеге проблемаларга чорыбызның күренекле математигы Россия фәннәр академиясе академигы Роберт Искәндәрович Нигъмәтуллинның мөнәсәбәте, аның телебез һәм мәдәниятебезгә караган фикерләре китап укучыларга аеруча кызыклы булыр дип уйлыйбыз. Р.А. Юсупов дини тәрбия, экологик һәм физик тәрбия бирүгә караган мәсьәләләргә дә җентекләп туктала, ирешелгән уңышлар белән генә чикләнмичә, яшәп килгән җитешсезлекләрне бетерү юлларын тәкъдим итә.

Рүзәл Абдуллаҗан улының яңа китабының шартлы рәвештә билгеләгән өченче бүлеге авторның иҗтимагый-сәяси өлкәгә караган эшчәнлеген яктырта. Унбиш елдан артык Россиянең өченче педагогика уку йорты булган КДПИ ректоры булып эшләгәндә, аны университет статусына күтәрү өчен, искиткеч зур хезмәт куйган җитәкче буларак һәм гасыр ярым вакыт эчендә Идел буе республикалары өчен белгечләр әзерләгән югары уку йортының бай тарихына кыскача диахроник анализ ясый, педагогика университетын бетерүне кискен тәнкыйтьли, ни өчен яңадан торгызырга кирәклеген мисаллар белән дәлилли.

Билгеле булганча, узган гасырның 90 нчы елларында Р.А. Юсупов җитәкчелегендә Татарстан Республикасы партиясе төзелгән иде. Китапта партиянең программасына аңлатма бирелә, «... партия Татарстанны чәчәк аттыру максатын истә тотып төзелә, программасында аның максат һәм бурычлары яктыртыла, беренче чиратта халык мәнфәгатьләрен истә тотып эшли», – диелә.

Галим чит илләргә сәяхәтләре, андагы гыйбрәтле хәлләр турында, аларның үз эшендә – Казан дәүләт педагогика университеты ректоры булып эшләгән чорда – кирәкле һәм урынлы формада куллана алу мөмкинлекләрен тасвирлый. Мәсәлән, Кытайга эшлекле сәфәр ясаганнан соң, университетның гыйльми советы утырышында галимнәр белән фикер алышып карар кабул иткәч, Россия югары уку йортларында беренчеләрдән булып, музыка нигезләре исемле кафедра ача, финанс мәсьәләләрен хәл итеп, тиешле музыка уен коралларын сатып алдыра һәм булачак укытучыларга бик тә кирәкле булган музыка нигезләре фәне барлык факультетларда да күп еллар дәвамында укытыла.

Кыскасы, киң катлам укучыларга атап чыгарылган *«Мәгърифәт – прогрессның нигезе. – Просвещенность – основа прогресса»* исемле китап беркемне дә битараф калдырмас дип уйлыйбыз, чөнки автор сүзләре белән әйткәндә, «бүгенге көндә, XXI гасырның өченче дистәсенә кереп барган цивилизация заманында, үз телеңне белмәү һәм

өйрәнмәүне, ул телдә иркенләп сөйләшмәүне» берничек тә аклап булмый. Без – булдыклы һәм югары әхлаклы, укымышлы һәм хезмәт сөючән халык, лаеклы милләт вәкилләре буларак, телебез һәм горефгадәтләребезне, мәдәниятебезне яшь буынга тапшыру өчен, армыйталмый эшләргә бурычлы.

ӘДӘБИЯТ

Мәһдиев М.С. Әсәрләр. 9 нчы том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – Б. 212.

Юсупов Р.А. Милләтебез иминлеге сагында. За развитие нации. – Казань: Слово, 2023. – 560 с.

Юсупов Р.А. Мәгърифәт – прогрессның нигезе. Просвещенность – основа прогресса. – Казан, 2023. – 447 с.

УДК 377.8:811

Харисова Чулпан Мөхәррәм кызы,
Казан федераль университеты

Олпат галим

иҗтимагый, орфография, алфавит, графика, шәкли, мәгариф

Телебезнең үсеше, аның казанышлары шул өлкәдә эшләгән галимнәр хезмәтендә ачык күренә. Озак еллар буе армый-талмый тел күренешләрен җентекләп өйрәнеп, үзеннән соң шактый зур хезмәтләр калдырган галимнәребез арасында Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров аерым урын алып тора.

XX йөз башы, билгеле булганча, тарихи вакыйгаларга бик бай чор. Нәкъ менә шул еллардагы иҗтимагый хәрәкәт халкыбызның йөзек кашы булырдай вәкилләрен бөтен дөньяга танытты. Ул вакытта яшәгән башка бик күп чордашлары кебек үк Гыйбад Алпаров та башы-аягы белән мәгариф, журналистика һәм фән дөньясына чума, моңа, әлбәттә, аның аңбелемгә омтылуы, уку-язу, иҗат һәм оештыру эшләре белән кызыксынуы, тынгысыз актив тормыш белән яшәве булышлык итми калмагандыр.

Архивларда сакланган мәгълүматларга караганда, Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров 1888 нче елның 11 нче ноябрендә Уфа губернасының Стәрлетамак өязенә караган Корманай авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Белем алу өчен, әтисе аны Уфадагы «Галия»

мәдрәсәсенә укырга җибәрә. Гыйбадулланы, беренче чиратта, дөньяви фәннәр кызыксындыра, шуңа да ул укуын дәвам итү өчен, Казанга килә һәм Татар укытучылар мәктәбендә белем ала.

Октябрь инкыйлабы һәм аннан соңгы чорда Г. Алпаров төрле китапханәләрдә эшли, шул елларда татарча нәшер ителгән «Кызыл яу», «Кызыл армия», «Көрәш» һәм башка күп кенә газеталарда актив язышa. Әлеге эшләр белән бергә ул укытучылар һәм кызылармеецлар өчен оештырылган курсларда дәресләр алып бара, Уфа эшче-крестьян университетында да укыта. Шушындый актив, тынгысыз һәм киң кырлы эшчәнлек Г. Алпаровның сәламәтлегенә зыян китерми калмый һәм ул Урта Азия якларына чыгып китәргә мәҗбүр була. Аның төп максаты, дәваланып, сәламәтлеген ныгыту булса да, нәкъ менә шул чорда аның галимлек эшчәнлеге башлана.

Баштарак, ягъни 1921-24 елларда, Г. Алпаров Ташкент шәһәрендә чыга торган «Ак юл» («Ак жол») газетасында һәм «Чулпан» («Чолпан») басмаларында журналистлык хезмәтен дәвам итә, аннары Төркестан Халык мәгарифе комиссариатында фәнни хезмәткәр булып эшли. Урта Азия халыкларының дәреслекләрен, орфографик нормаларын төзүдә актив катнаша, хәтта «Төрекмән теленең грамматикасы»н төзегән галимнәр төркеменә җитәкчелек итә, шунда эшләү аңа формаль нигезгә корылган беренче хезмәтне бастырырга ярдәм итә.

Аннан соң (1924-1926 нчы елларда) Г. Алпаров Башкортстан Халык мәгарифе комиссариатында һәм Татарстан Халык мәгарифе комисариатының Академик үзәгендә эшли. Ул Беренче тюркология съездына делегат булып бара, гарәп графикасына нигезләнгән татар орфографиясе мәсьәләләренә караган чыгышлар ясый. Чыганаклардан күренгәнчә, Г. Алпаров бу елларда мәгариф һәм фән өлкәсенә караган вакыйгаларда бик актив катнаша. Югары белем алу теләге аны 1926 нчы елда Ленинград Көнчыгыш институтына алып килә, шунда ук аспирантура да уза.

Укуын тәмамлагач, Г. Алпаров Казанга кайта һәм бөтен гомерен укытуга һәм фәнни эшкә багышлый: педагогика институтында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире булып эшли, башта доцент, аннары профессор дәрәҗәсе ала.

Галимнең фәнни хезмәтләре арасында татар алфавиты, орфографиясе мәсьәләләрен яктыртканнары шактый. Татар язуын латин графикасына күчерү белән килешмичә, Г. Алпаров вакытлы матбугатта үз

фикерләрен кыю дәлилләп язган күп кенә мәкаләләр белән дә чыгышлар ясый.

XX гасырның 20 нче елларыннан ук галим татар тел белеменә караган фәнни эзләнүләр алып бара башлый. Аның бу эшчәнлегендә философия фәненең йогынтысы, Н.Я. Марр фикерләре белән теләктәш булуы бик ачык күренә.

Г. Алпаров хезмәтләреннән «Әлифба тәртибе, имла кагыйдәләре, атамалар мәсьәләсе, халык әдәбиятын җыю турында инструкцияләр» (1926), «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926), «Татар теленең имла сүзлеге» (1927), «10 ел эчендә татар теле» (1927) һ.б. телебез үсешендә аерым урын алып тора [Алпаров 1945; 2008]. Алар арасында «Шәкли нигездә татар грамматикасы» татар теленең фәнни грамматикасына багышланган беренче җитди хезмәт дип саналырга хаклы [Алпаров 1926]. Анда галим татар телендәге сүз төркемнәренә, җөмлә төзелешенә һәм андагы кушымчаларга карата үзенең кыю фикерләрен әйтә. Тел берәмлекләрен тасвирлаганда, автор аларга башкача – формаль яктан чыгып, телебезнең эчке үзенчәлекләрен истә тотып якын килә. Шуңа да бүгенге көн укучысында әлеге хезмәт каршылыклы фикерләр дә уятырга мөмкин. Тик шуны онытмаска кирәк: бу хезмәт – 100 ел чамасы элек язылып дөнья күргән грамматика – татар теленең эчке үзенчәлекләрен алгы планга куя, галим тарафыннан әйтелгән татар теле белеменең төп нигезен тәшкил итәрлек фикерләрне киләчәк буыннарга җиткерә.

Киң кырлы галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе, фән, мәгариф һәм журналистика өлкәсендә үз сүзен әйткән шәхес – Гыйбад Алпаровның хезмәтләре татар телен фәнни яктан өйрәнүгә, аның үсешенә зур өлеш кертә; алар бүген дә үзләренең актуальлеген саклый һәм киләчәк буыннарга данлы еллар авазы булып килеп ирешә.

Бер булганнан бар да була, ди халык. Галимнең дәвамчысы – улы Үзбәк Гыйбадович Алпаров исеме төзелеш һәм архитектура өлкәсендә эшләүчеләргә яхшы таныш. Ул – РСФСРның һәм Татарстанның атказанган төзүчесе, Казандагы проект оешмаларында җитәкче урыннарда эшли, 20 елга якын Татгражданпроект институты директоры була. Хезмәттәшләре аны сәләтле оештыручы һәм үз эшен камил дәрәҗәдә белгән җитәкче буларак хәтерлиләр. Ү.Г. Алпаров җитәкчелегендә эшләнгән проектлар буенча Казанда Болак елгасы буйлары, Кремль яны яңартыла, Үзәк стадион, Үзәк универмаг, Казан циркы, Яшьләр үзәге һәм башка күп кенә корылмалар төзелә. Ул башкалабыз үзәгендәге Болак

елгасы ярларын – татар әдәбиятының күренекле вәкилләре Муса Җәлил һәм Таҗи Гыйззәт исемнәре белән аталган урамнарны – тоташтырган күпер проектын эшләүчеләрнең дә берсе була.

Тел белеме өлкәсендә зур хезмәтләре белән билгеле булган галимнәребез арасында Г. Алпаровның үз урыны бар. Аның эшчәнлеге милли азатлык хәрәкәте башланган елларда үз юнәлешен таба. Аннан соңгы буыннар да галимнең хезмәтләрен онытмыйлар, аларны өйрәнәләр, үз эшләрендә аларга таяналар.

ӘДӘБИЯТ

Алпаров Г.Х. Шәкли нигездә татар грамматикасы: Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1926. – 164 б.

Алпаров Г.Х. Әлифба тәртибе, имла кагыйдәләре, атамалар мәсьәләсе, халык әдәбиятын җыю турында инструкцияләр җыентыгы / җыючы Г. Алпаров. – Казан: Татарстан халык мәгариф комиссариатының басмасы, 1926. – 55 б.

Алпаров Г.Х. Сайланма хезмәтләр. – Казан: Татгосиздат, 1945. – 330 б.

Алпаров Г.Х. Сайланма хезмәтләр: фонетика, графика, орфография, грамматика, мәсьәләләре. – Казан: Мәгариф, 2008. – 287 б.

Харисова Ч.М. Күренекле галим // Казан утлары. – 2013. – № 12. – Б. 153-155.

УДК 81’367; 811.512.145

Хаялиева Раилә Ренатовна,

Казан федераль университеты

«ШАЯН ТВ» каналы тапшыруларында телевизион сөйләм үзенчәлекләре

медиадискурс, балалар тапшыруы, тел үзенчәлекләре, медиасөйләм

Журналистика фәнендә балалар өчен эфирга чыга торган телевизион тапшырулар медиадискурс жанрына кертеп карала. Т.Г. Добросклонский фикеренчә, әлеге жанрга караган медиатекстларның төп билгеләре булып «форматның тотрыклылыгы, тематик бәйләнеш, телнең тәэсирле сөйләме хас». Шулай ук бу жанрга караган текстлар сүз аша йогынты ясарга, сәнгати-эстетикнәтиҗәгә юнәлдерелгән була [Адамьянц 1999].

Максатыбыз – «ШАЯН ТВ» каналында балалар өчен эфирга чыга торган «Әти һәм мин», «Мин татарча өйрәнәм», «Шаян балалар»,

«Дөньяның 100 могҗизасы», «Уймак», «Бергәләп өйрәник!» тапшыруларына нигезләнеп, балалар тапшыруларының тел үзенчәлекләрен өйрәнү. Максатка ирешү өчен, эфирга чыккан тапшыруларның транскрипты ясалды, балалар тапшыруларының лексик-грамматик үзенчәлекләре анализланды.

Чыганак итеп алынган телевизион тапшыруларның даими композицион компонентлары түбәндәгедән гыйбарәт:

1. Тапшыруның башлам өлеше музыка белән башлана һәм тема билгеләнә.

2. Төп өлештә сюжет линиясе үстерелә, белем бирү, тирә-як дөнья белән таныштыру функцияләре башкарыла.

3. Йомгакта өйрәнелгән күнекмәләр ныгытыла, практик нәтиҗәләр күрсәтелә.

Тамашачыларның игътибарын җәлеп итү, эмоциональ контактны саклау һәм күңел ачу функциясен саклау өчен, һәр бүлек музыка яки тематик картина ярдәмендә кечкенә кисәкләргә бүлеп тәкъдим ителә.

Балалар тапшыруларының тел үзенчәлеге зурлар өчен эфирга чыга торган тапшырулардан аерылып тора. Бу максаттан, «ШАЯН ТВ» каналында эфирга чыгучы балалар тапшыруларын тикшереп, түбәндәге лексик һәм синтаксик үзенчәлекләре ачыкланды.

1) Балалар тапшыруларында тасвирлау чаралары кулланыла: *Күрегез, яшел келәм сыман чирәм чыккан. Якты кояш алын нурларын сибеп җирне җылыта* («Дөньяның 100 могҗизасы» тапшыруы);

2) Гади синтаксик конструкцияләр: *Мин монда бик күп хәрефләр күрәм! Бер, ике, өч... әмма алар унга тулмый бугай! Ә саннар ничә булыр? (*«Мин татарча өйрәнәм» тапшыруы);

3) Өндәү җөмләләр: *Менә бит безнең студия кунаклары нинди матур рәсемнәр ясады!* («Шаян балалар» тапшыруы); *Азим, син юкка борчыласың, барлык хәрефләрне дә белдең бит!* («Мин татарча өйрәнәм!» тапшыруы); *Кояш белән бергә йокларга ятарга тырышыгыз!* («Дөньяның 100 могҗизасы» тапшыруы);

4) Эндәш сүзләр: *Безне яратып караучы тамашачыларыбыз, сезне хәзер яңа геройлар белән таныштырабыз! Сәлам,дуслар! Хәлләрегез ничек? Дуслар, ә сез ничек, дәрескә әзерме?* («Мин татарча өйрәнәм» тапшыруы); Эндәш сүзләр җансыз пердметларга карата да куланыла: *Ә пароход ничек кычкыра, тавыш бир әле? Туп, син безнең малайларга үпкәләмәдеңме? У хәрефе А хәрефенә таба йөгерә!* («Мин

татарча өйрәнәм» тапшыруы*);* Кайбер очракларда, җансыз пердметлар җанландырып бирелә: *Хөрмәтле Әлифба китабы, безгә үзеңнең серләреңне ач әле! Шаян тупның Алиханны тыңлыйсы килми әле!* («Мин татарча өйрәнәм» тапшыруы*);* Ягымлы эндәш сүзләр: *Түти, син билгеләнгән чиктән узма әле, яме! Балакаем, әйдә, әкиятеңне сөйлә инде!* («Әти һәм мин» тапшыруы);

5) Эмоциональ төсмердәге тәэсирле стилистик чаралар: *Тукта, тукта, син бүре кебек улап күрсәткәндә тәннәр чымырдый башлады, куркыныч бит монда! Хәй-хәй, катырак басып басып биергә кирәк! Борчылма, Марат, без сиңа булышырбыз!* («Шаян балалар» тапшыруы);

6) Кабатлаулар: *Туктагыз, туктагыз дим! Кил инде, кил якынрак кил, безгә синең белән танышырга, дуслашырга кирәк! Лә-лә-лә, трәллә-лә-лә, миңа эләгә алмыйсыз!* («Уймак» һәм «Бергәләп өйрәник» тапшырулары);

7) Чагыштырулар: *Син нәкъ балык тоткан бабай кебек бөкрәеп утырасың! Бу О хәрефе тәмле коймакка охшаган, шундый түгәрәк!* («Мин татарча өйрәнәм» тапшыруы*)*;

8) Афоризм, мәкаль-әйтемнәреш кулланыла: *Өйләре булган таштан, сөйлимме яңа баштан? Бер-ике-өч, бездә көч! Ярышны башладык! Туган бар җирдә – ярдәм бар.* («Әти һәм мин» тапшыруы);

Шунысын да искәртеп узарга кирәк: «ШАЯН ТВ» каналында эфирга чыккан балалар тапшыруларының күбесенә уен элементы хас. Балаларның сөйләмен үстерүдә уеннарның әһәмияте шактый зур, чөнки уеннар мәктәпкәчә яшьтәге баланың танып белү эшчәнлеген, иҗади фикерләвен һәм сөйләмен үстерә, уенда бала үзе белмәгәнне өйрәнергә, аны эшләргә омтыла. Уен уйнап сөйләшү балаларның бәйләнешле сөйләмен (диалогик, монологик) һәм сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру, камилләштерү, сүзлеген баету чарасы булып тора. Сәнгатьле сөйләм, сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру һәм камилләштерү, сүзлекне баету (предметларны, аларның билгеләрен атау), бәйләнешле сөйләм (предметны тасвирлау) мәктәпкәчә яшьтә булган балаларның фикерләү, хәтер үсешен, күзаллау, игътибарлыгын арттырырга да ярдәм итә.

Гомумиләштереп әйткәндә, телевидение көндәлек тормышта шактый зур урын алып торса да, татарча телевизион тапшыруларның теле фәнни яктан әлегә ныклап өйрәнелмәгән. Балалар тапшыруларының теле аудитория белән элемтәгә корылган, бу максаттан телевизион

тапшыруларда эмоциональ төсмердәге тәэсирле стилистик чаралар, ягымлы эндәш сүзләр, чагыштырулар, җансыз пердметларны җанландырып бирү, өндәү җөмләләр, гади җөмләләр кулланыла.

ӘДӘБИЯТ

Адамьянц Т.З. К диалогической телекоммуникации: от воздействия к взаимодействию. – М.: Ин-т социологии РАН, 1999. – 136 с.

Бахтин М.М. Собр. соч. – М.: Русские словари, 1996. – Т. 5: Работы 1940-1960 гг. – С.159-206

Добросклонская Т.Г. Вопросы изучения медиатекстов. – М.: 2000. – 287 с.

Добросклонская Т.Г. Медиалингвистика: системный подход к изучению языка СМИ: современная английская медиаречь. – М.: Флинта: Наука, 2008. – 264 с.

Муратов С.А. Телевизионное общение в кадре и за кадром: учеб. пособие для вузов. – М.: Аспект Пресс, 2003. – 201 с.

Кузнецов Г.В. Журналист на экране. – М.: 1985. – 207 с.

Психология общения: энциклопедический словарь / Учреждение Российской акад. образования Психологический ин-т; под общ. ред. А.А. Бодалева. – М., 2011. – 598 с.

Светана С.В. Телевизионная речь // Язык и стиль средств массовой информации и пропаганды. – М., 1980. – С. 194-196.

УДК 81-115

Чернышев Алексей Борисович,
Публичное акционерное общество «Автодизель», г. Ярославль

К вопросу о формальной вариативности дательно-направительного маркера *-га* в татарском языке и его сопоставлении с некоторыми тюркскими и индоевропейскими формантами

агглютинация, дательно-направительный падеж, аффикс

Исследования в области татарского языка в контексте евразийской гуманитарной науки приобретают все большую актуальность и ценность. Это обусловлено тем, что функционирование татарского языка, с учетом географических особенностей региона его носителей, подвержено влиянию как восточных, так и европейских культурно-исторических и языковых артефактов. И на фоне меняющегося мира репрезентация фрагментов татарской языковой картины мира, актуализируемых посредством языковых единиц разного уровня, может стать ключевым в

понимании стратегического ориентира в движении языка и общества. В настоящей статье рассматриваются особенности формирования маркеров дательно-направительного падежа в татарском языке в сопоставлении с языками разных семей, отражая специфический фрагмент языковой картины мира.

В одной из предыдущих работ нами были подмечены особенности семантической структуры дательно-направительного аффикса *-ga* в узбекском языке в аспекте когнитивного моделирования. В частности, было установлено, что семантическую сеть аффикса *-ga* образуют денотативные сегменты и конфигурации, отображающие общую идею направленности и в большинстве своем идентичные соответствующим конфигурациям морфем индоевропейского языкового ареала [Чернышев 2017: 60-61].

Сопоставление татарских дательно-направительных маркеров с узбекским аффиксом *-ga* вполне закономерно, поскольку узбекский язык, наряду с татарским, не просто относится к языкам тюркской семьи, но и выступает в качестве едва ли не этнического синонима всех языков восточно-алтайского ареала. Подтверждением этому факту может служить монография В.П. Наливкина, небесспорно утверждавшего, что ни один туземец не назовет Чингизхана монголом, но узбеком, и что татары суть ни что иное как Ногай и относятся к одному из известных 92 родов узбеков [Наливкин 2017: 11].

Если следовать тому научному предположению, что узбекский язык в силу определенных причин шел по пути искусственного упрощения [Чернышев 2017: 57], то вариантность татарских дательно-направительных маркеров – *-га/-гә/-ка/кә*, – очевидно, объясняется в целом типичным для агглютинативных языков законом сингармонизма. Примеры:

*Мулла, бу арада сүзне башка**га** борып* (Ш. Камал).

*Гали вә мөкатдәс максат**ка** юнәлгәннәр* (Ш. Камал).

*Солдат шулай дигәч, төрле яктан бу егет**кә** берничә күз төште, гүя сокланып карый иделәр* (Ш. Камал).

Представленные примеры наглядно демонстрируют как ярко выраженное семантическое значение, заключающееся в направленности, или векторном движении как частном ее случае, одного объекта к другому, так и фонетические разновидности инварианта *-га*.

Особенность функционирования инварианта *-га* во всех его разновидностях в татарском языке позволяет усмотреть и его генеалогическую связь с предлогами индоевропейских языков, ставшими самостоятельными единицами в ходе языковой эволюции. Как указывает в своем очерке О. Сулейменов, славянский предлог к восходит к полногласному *ка* (*ко*, *къ*) и через него к праформе *а*, реализующейся в качестве дательного предлога уже в романских языках. Ср.:

*Charles IX avait dit **à** l'amiral **à** propos de la guerre de Flandre* (A. Dumas, французский язык).

*Quand'io sposai, figlio mio, tuo nonno mi disse precisamente quell che poi io ripetei **a** te, parola per parola* (L. Pirandello, итальянский язык).

Había llegado a Barranquilla esa mañana desde el pueblo distante <…> (G.G. Márquez, испанский язык).

О. Сулейменов, давая индоевропейскому слову нелингвистическое наименование «сэндвич», пишет, что гортанное придыхание, открывающее слог, в славянских языках реализовалось глухим гортанным протезом, в романских же языках = редуцировалось. Что касается тюркских языков, то их отличает только место форманта по следующей модели словообразования: *-a* = *-ka*, *-ga* (как суффиксы дательно-направительного падежа); Madrit-**a** 'к Мадриду' (тюркско-огузские языки), Madrit-**ka** 'к Мадриду' (тюркско-кипчакские языки). Та же самая картина представлена в отношении дательно-направительной формы местоимения первого лица *мне*. Если ранее достаточно было сказать мне (**men-e*) для получения дательно-направительного значения, то впоследствии в результате «сложных культурных переживаний» значение уточняется дополнительным формантом **kamen-e* 'ко мне'. В тюркско-огузских языках эти формы обходятся без предложного довеска: *män-ä* 'мне, ко мне' (в азербайджанском), *ben-e* 'мне, ко мне' (в турецком), *men-ge* 'мне, ко мне' (в староказахском) [Сулейменов]

Подобные языковые факты вполне соотносимы с принципиальным выводом Н.С. Трубецкого о том, что «индоевропейские языки возникли в процессе преодоления гипертрофии флексии, стремясь к рациональной агглютинации как к идеалу» [Трубецкой 1958: 77]. Данный вывод представляется определенно исчерпывающим и емким и в отношении проведенного нами исследования. Смысловая же и структурная независимость форманта *-га* способствует дальнейшему его рассмотрению в качестве квазиморфа в составе слова на уровне отдельно взятой единицы.

Исследование выполнено при поддержке Городского общественного научно-экспериментального фонда «Языковая среда» (г. Рыбинск)

ЛИТЕРАТУРА

Наливкин В.П. Краткая история Кокандского ханства. – М.: ЛЕНАНД, 2017. – 224 с.

Сулейменов О. Язык письма. Начальная грамматика. Эффект сэндвича. – URL: http://vvu-library.ru>olgas/iazyk/4-03.htm (дата обращения: 02.11.2023).

Трубецкой Н.С. Мысли об индоевропейской проблеме // Вопросы языкознания. – 1958. – № 1. – С. 65-77.

Чернышев А.Б. Узбекский датив: когнитивная модель агглютинативного аффикса -*ga* // Проблемы востоковедения. Научный журнал – Уфа, 2017. – № 2 (76) – С. 56-61.

УДК 372.881.1

Шакирова Гөлнара Расих кызы,
Казан федераль университеты

Ч.М. Харисованың лингвометодика өлкәсендәге эшчәнлеге

лингвометодика, татар теле, татарча әйтелешкә өйрәтү, интерференция

Чулпан Мөхәррәм кызы Харисова – педагогика фәннәре докторы, профессор, Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкиле, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы, К. Насыйри исемендәге премия лауреаты, «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен», «Мактаулы остаз» билгеләре һәм бик күп мактау грамоталары иясе; татар теленең сүз ясалышы һәм морфологиясе, татар телен укытуның лингвометодик нигезләре турында күпсанлы фәнни хезмәтләр, гомуми урта белем бирү оешмалары укучылары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма һәм дәреслекләр, уку әсбаплары, сүзлекләр авторы.

Ч.М. Харисова 1953 нче елның 17 нче мартында Татарстанның Кукмара районы Зур Сәрдек авылында дөньяга килә. Зур Сәрдек урта мәктәбен тәмамлагач, укуын Казан дәүләт педагогика институтында дәвам итә. Аны кызыл дипломга тәмамлап, туган мәктәбендә берничә ел рус теле һәм әдәбияты укытучысы, укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшли [Шакирова 2018: 257].

1979 нчы елдан Ч.М. Харисова КДПИның татар теле кафедрасында өлкән лаборант, ассистент, өлкән укытучы, доцент, профессор булып эшли, кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый. 2002 нче елда «Рус мәктәбендә татарча әйтелешкә өйрәтүнең теориясе һәм практикасы» дигән темага докторлык диссертациясен яклап [Харисова 2002], педагогика фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсенә ия була.

Ч.М. Харисованың фәнни-методик эшчәнлеген берничә юнәлешкә бүлеп карарга мөмкин:

• хәзерге татар әдәби теленең морфемика, сүз ясалышы һәм морфологиясе бүлекләре мәсьәләләрен өйрәнү;

• татар телен укытуның лингвометодик үзенчәлекләрен фәнни һәм гамәли аспектта яктырту;

• гомуми урта белем бирү оешмалары укучылары һәм югары уку йортлары студентлары өчен программалар һәм дәреслекләр, укытучылар өчен методик кулланмалар һәм дидактик материаллар төзү.

Профессор Ч.М. Харисова – татар телен чит тел буларак өйрәтү методикасының фәнни-гамәли нигезләрен эшләү юнәлешендә зур көч куйган галимә. Бу проблемага багышланган хезмәтләренең иң беренчесе – педагогика фәннәре докторы, профессор Ф.Ф. Харисов белән бергә язылган «Учимся говорить по-татарски» китабы ата-аналар, укытучылар һәм тәрбиячеләр арасында зур популярлык казана.

1993 нче елда исә «Мәгариф» нәшриятында Чулпан Мөхәррәм кызы авторлыгында татар телен башка милләтләргә интенсив метод белән өйрәтүгә багышланган тәүге китап – «Интенсивное обучение татарскому языку» исемле методик кулланма басыла (автордашлары – Н.Х. Салехова, А.К. Максимова).

Татарча сөйләшергә өйрәнүчеләр өчен төзелгән татар лексикографиясе тарихында беренче рәсемле-тематик сүзлекләр профессор Ф.Ф. Харисов белән автордашлыкта язылып, «Минем беренче татарча сүзлегем», «Минем сүзлегем» исемлеләре Россия мәгариф министрлыгы тарафыннан телгә өйрәтү өчен кулланма буларак тәкъдим ителә. Бу китап 1996 нчы елда ЮНЕСКО карамагында уздырылган Бөтенроссия балалар китабы конкурсында (рәисе – танылган рус шагыйре С.В. Михалков) махсус дипломга лаек була һәм татар яшьләренең «Сәләт» иҗат лабораториясе белән берлектә дүрт төрле мультимедия системасында компакт-диск эшләнә.

Профессор Чулпан Мөхәррәм кызы Харисованың фәнни-методик эшчәнлегендә рус телендә сөйләшүчеләрне татарча әйтелешкә өйрәтү проблемалары аерым урын алып тора. Әлеге мәсьәлә белән ул аспирантурада укыганда, педагогика фәннәре докторы, профессор, милли мәктәпләрдә рус теле укыту методикасы буенча үзенең фәнни мәктәбен булдырган галимә Лия Закир кызы Шакирова җитәкчелегендә, ныклап шөгыльләнә башлый. Бу юнәлешне яктырткан хезмәтләр арасында галимәнең «Обучение татарскому произношению в русской школе», «Теория и практика обучения произношению в русскоязычных школах (начальный этап)», «Рус телендә белем бирү оешмаларында татарча әйтелешкә өйрәтүнең лингводидактик аспекты», «Татарча әйтелешкә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре» исемле монографияләре аеруча актуаль. Әлеге хезмәтләрдә рус телле укучыларны татар теленең әйтелешенә өйрәтүнең, аларда фонетик компетенция формалаштыруның лингвометодик концепциясе бәян ителә. Телче-методист татар һәм рус телләренең фонетик һәм фонологик системаларын чагыштырып, әлеге телләрдәге фонетик күренешләрне системалаштырып, туган тел белән өйрәнелә торган телнең үзара катлаулы бәйләнешкә керүен ассызыклый. Галимә татар һәм рус телләрендә артикуляцион-акустик яктан иң якын булган сузык авазны ([у]), уртак, әмма һәрберсендә әйтелү үзенчәлеге булган сузыкларны ([а], [ы], [о], [э], [и])); ике телдә дә охшаш тартык авазларны ([б-п], [д-т], [ж-ш], [з-с], [в-ф], [м], [н], [р], [л], [й]), ике телдә дә охшаш, тик һәрберсендә үзенчәлекле билгеләре белән аерылып торган тартыкларны ([х], [ч], [г], [к]); татар телендә генә булган сузыкларны һәм тартыкларны, өйрәнелә торган телләрдәге фонетик күренешләрне методик максаттан чыгып тикшерә, әлеге үзенчәлекләрне белүнең русча сөйләшүче укучыларны татарча әйтелешкә өйрәтү эчтәлеген һәм системасын булдырган вакытта, «транспозиция һәм интерференция күренешләрен алдан күрергә» [Харисова 2001] һәм русча сөйләшүче укучыларны татарча әйтелешкә өйрәткәндә, гамәли яктан файдалы методик киңәшләр булдырырга ярдәм итә дип билгели. Ч.М. Харисова татарча әйтелешкә өйрәтүгә мөнәсәбәтле рәвештә педагогик һәм психологик алшартларны, дидактик принципларны, укытуның методларын һәм алымнарын фәнни һәм гамәли аспектта яктыртуга бик зур өлеш кертә.

Хәзерге тел белемендә сөйләмнең ритмик-интонацион үзенчәлекләре (суперсегмент берәмлекләрнең җыелмасы) просодик система дип

атала [Харисова 2016: 66]. Ч.М. Харисова рус һәм татар телләренең просодик системаларын өйрәнә. Фонема, морфема һәм сүз тәртибе белән бергә сөйләмдә аерым мәгънәгә ия булган кисәкләр – синтагмаларның татарча әйтелеш үзенчәлекләрен өйрәткәндә, зур әһәмияткә ия булуларын нигезли. Галимә фикеренчә, «татар телендәге синтагмаларның үзенчәлекләрен истә тоту сөйләмне дөрес аңларга булышлык итә» [Харисова 2016: 70].

Ч.М. Харисова татарча әйтелешкә өйрәтүдә сүз басымына бәйле кыенлыкларны билгеләп һәм укучылар сөйләмендә күзәтелгән хаталарны эксперименталь юл белән тикшереп, рус телендә сөйләшүче укучылар белән эшләгәндә, татар телендәге сүз басымына хас булган үзенчәлекләрне исәпкә алу кирәклеген раслый. Галимә фикеренчә, интонацион төзелмә, интонацион үзәкнең хәрәкәте, синтагмаларга бүленеш, пауза кебек чаралар дәресләрдә өйрәнелә торган сүзләргә, грамматик формаларга һәм җөмләләргә бәйле рәвештә каралырга тиеш.

Методик күзлектән караганда, Ч.М. Харисова тарафыннан чит телдәге авазларны өйрәтү өчен билгеле булган методларның нәкъ менә рус телле укучыларны татарча әйтелешкә өйрәтү өчен җайлаштырылып тәкъдим ителүе кызыклы. Галимә әлеге эшчәнлек барышында имитация (охшату), чагыштыру, артикуляция, аналитик-синтетик, аваз-хәреф яки фонетик анализ һәм уен методларын файдаланырга тәкъдим итеп кенә калмый, бәлки әлеге методларны, татар һәм рус телләре арасындагы интерференция күренешен, ике телнең артикуляцион-акустик үзенчәлекләренең йогынтысын исәпкә алып куллануның гамәли-методик нигезләрен дә тәкъдим итә.

Ч.М. Харисова – рус телле укучыларны татарча әйтелешкә өйрәтүнең лингвометодик үзенчәлекләрен фәнни һәм гамәли яссылыкта өйрәнеп, тулы һәм төзек бер системага салган галимә. Әйтергә кирәк: бүгенге көндә күренекле профессор Чулпан Мөхәррәм кызы Харисованың фәнни-методик хезмәтләреннән Татарстандагы төрле уку йортларында укучы һәм эшләүчеләр генә түгел, бәлки Россия Федерациясендә яшәүче һәм эшләүчеләр дә уңышлы файдалана. Әлеге хезмәтләр хәзерге телләрне укыту юнәлешләрен чагылдыра һәм лингвометодиканың гомуми үсешен билгеләүдә әһәмиятле урын алып тора.

Мәкалә «Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр» фәнни белем бирү үзәге кысаларында язылды.

ӘДӘБИЯТ

Харисова Ч.М. Обучение татарскому произношению в русской школе. – М.: ВЛАДОС, 2001. – 422 с.

Харисова Ч.М. Теория и практика обучения татарскому произношению в русской школе: дис. ... д-ра пед. наук. – Казань, 2002. – 449 с.

Харисова Ч.М. Рус телендә белем бирү оешмаларында татарча әйтелешкә өйрәтүнең лингвометодик аспекты. – Казан, 2016. – 175 б.

Шакирова Г.Р. На пути науки и образования (к 65-летию профессора Ч.М. Харисовой) / Г.Р. Шакирова, Г.Ш. Набиуллина // Филология и культура. – 2018. – № 1 (51). – С. 256-262.

УДК 81' 373.4

Shinnazarova Saodat Jubatkhanovna,
Nukus State Pedagogical Institute

Linguoculturology is the study of language as a carrier of cultural information

linguoculturology, llinguistic units, culture, component, conception

Linguoculturology is the study of language units that have emerged as a result of a combination of linguistics and culturology, reflected and expressed in language, reflecting national-cultural meaning in their semantics. In linguoculturology, language is considered as the main generalizing part of culture and an invaluable treasure of collective skills, and the study of the influence of culture on language, as well as language on human thinking and worldview. According to V.V. Vorobyov, linguoculturology is a complex scientific field of the synthesized type, which studies the reflection of the interrelation of language and culture in language units using systematic methods [Vorobyov 2008].

The object of the science of linguoculturology is the study of language as a carrier of cultural information, culture, its components, and the preferences of the people who create that culture through language [Maslova 2007]. The goal of science is to study, describe, describe the cultural field in which language finds its verbal expression [Krasnix].

The science of linguoculturology is currently developing rapidly. Its development (V.V. Vorobyov, V.N. Telia, V.A. Maslova, E.I. Sheygal) is explained by the urgency of the problem of "language and culture". There are

many approaches to the concept of culture in science. In the broadest sense, culture is "a set of objects and rigidly defined procedures that include human behavior, actions, acquired knowledge, self-awareness, understanding and knowing the symbolic meanings of the world" [Vorobyov 2008]. V.V. Vorobyov considers culture as the main factor, the way of formation of the person as the person. It should be noted that language and culture are closely linked: language appears and develops on the basis of culture, and it is its representative. Any culture is not rigid, it is in constant motion and change in harmony and connection with the environment around it [Maslova 2007]. Here, language serves the function of collecting, storing, and transmitting information from generation to generation. Therefore, in linguoculturology, language is considered not only as a means of knowledge and communication, but also as a key to the national culture of a particular nation. The theoretical foundations of this view are also defined in the works of W. Humboldt, A.A. Potebnya and other linguists. For example, W. Humboldt states: "The boundaries of the language of my nation define the boundaries of my worldview." In his concepts, he describes the “person-language-culture” connection. According to Humboldt's theory, language is an invaluable treasure of the people's psyche and culture, embracing the national culture of the people ... the relationship between the inner and outer world of the individual, so each language represents the will of the people, the worldview to which it belongs. In other words, language, as the main reflector of national values, serves as a mirror in the nation's view, understanding and perception of the world [Humboldt 1984].

This concept was continued in the work of Humboldt's followers. Linguist E. Sepir says that language is a necessary condition for the development of culture in general. Language cannot exist apart from culture ... Language has the ability to directly influence the formation and development of national culture”, “Culture can be understood as the sum of the ways of thinking and actions of the people of that society” [Sepir 1993]. W. Humboldt’s views on the internal structure of the word were developed by A.A. Potebnya in his concept of the “near and far meaning of the word”. In his view, there are two things underlying the meaning of a word: one is its linguistic meaning - a close meaning; the second, which forms the subject of other sciences, has a long meaning [Potebnya 1988]. According to this theory, the long meaning of a word differs from the close meaning in that it expresses imaginary information about an object in addition to language, the national-cultural identity of the word, and its cultural significance for a linguocultural environment. Thus,

W. Humboldt, A.A. Potebnya and representatives of the new Humboldt school (Weisgerber L., Sepir E., Wharf B.) studied the concepts of "man", "language" and "culture" in relation to each other and play an important and special role in understanding the world. Another basic concept of linguoculturology is the concept of "worldview". The "landscape of the world" is a holistic set of symbols and emblems collected in the common consciousness, which contributes to the acquisition of new worldly knowledge and the development of human thinking and imagination, and forms the core of the human worldview and reflects the main features of his lifestyle [Potebnya 1988].

The image of the cognitive or conceptual world is described as "a single global symbol of the world", "a set of stereotypes and conceptospheres that appear in the mind based on culture" [Popova 2007], "a system of intuitive (inner emotional) views on reality." A conceptual worldview is a regulated system of information and knowledge that reflects a person’s perceptions and views of the world, their cognitive skills, as a result of a reality-based cognitive process. The conceptual worldview is expressed through a “linguistic image of the world”. In other words, while a conceptual world image is a collection of knowledge in the human mind, a linguistic image verbalizes the world image using language units. The problem of the linguistic worldview has been studied in the works of several linguists (Yu.S. Stepanov, S.G. Vorkachev, M.L. Makarov, A. Vezhbitskaya, Z.D. Popova and others). M.V. Pimenova interprets the image of the linguistic world as "a set of knowledge about the world reflected in the language, ways of acquiring and interpreting new knowledge" [Pimenova 2002]. The conceptual worldview and the linguistic worldview “are a mental phenomenon and its linguistic expression or cognitive content and as a means of expressing that content” are inextricably linked and constantly interacting [Popova 2007] because linguistic structures are directly involved in creating a conceptual worldview reaches [Krasnix 2002].

REFERENCES

Воробьев В.В. Лингвокультурология. – М.: Изд-во РУДН, 2008. – 340 с.

Гумбольдт В. фон. Избранные труды по языкознанию. – М.: Прогресс, 1984. – 398 с.

Красных В.В. Этнопсихолингвистика и лингвокультурология: Курс лекций. – М.: ИТДГК Гнозис, 2002. – 284 с.

Маслова В.А. Введение в когнитивную лингвистику. – М.: Флинта. – Наук, 2007. – 296 с.

Пименова М.В. Методология концептуальных исследований // ВестникКемГУ. Сер. Филология. – Кемерово, 2002. – № 4 (12). – С. 100-105.

Попова З.Д., Стернин И.А. Когнитивная лингвистика. – М.: Восток-Запад, 2007. – 315 с.

Потебня А. А. Слово и миф. – М.: Правда, 1988. – 624 с.

Сепир Э. Избранные труды по языкознанию и культурологи / Под ред. А.Е. Кибрик, – М.: Прогресс, Универс, 1993. − 654 с.

УДК 811.512.1

Юлдашева Динара Юрьевна,
Хусаинова Ляйля Мидхатовна,
Башкирский государственный педагогический университет
им. Мифтахетдина Акмуллы

Поэтонимы в романе Нугумана Мусина «Белый олень на Синь-горе»

поэтоним, поэтическая ономастика, башкирский язык, башкирская литература, башкиры

Поэтонимы – любое собственное имя, употребленное в литературном произведении. Смысловое поле поэтонима в полной мере реализуется только в контексте произведения [Федотова 2018: 229].

Поэтонимы рассматриваются в рамках одного из разделов ономастики – поэтической ономастики. Поэтическая ономастика тесно связана со многими науки, в числе которых: литературоведение, языкознание, история, география и т.д. Термину «поэтическая ономастика» Н.В. Подольская дает следующее определение:

Поэтическая ономастика – это раздел ономастики, изучающий любые имена собственные (поэтонимы) в художественных литературных произведениях: принципы их создания, стиль, функционирование в тексте, восприятие читателем, а также мировоззрение и эстетические установки автора» [Подольская 1988: 54].

Будучи молодой дисциплиной, поэтическая ономастика является актуальной темой для изучения. К тому же в художественных произведениях отражена национальная картина мира. Творчество писателей позволяет продемонстрировать читателям культуру, быт, своеобразие народов.

Башкирская поэтическая ономастика еще лишь на пути становления. Нами были изучены исследования Н.Г. Нигматуллиной «Поэтиче-

ская ономастика в произведениях Зайнаб Биишевой», А.Ш. Султановой «История становления и развития башкирской поэтической ономастики», С.Р. Кудашевой и М.И. Карабаева «Поэтонимы в поэзии Шайхзады Бабича: семантика, структура и функции».

В данном исследовании поэтонимы рассмотрены на примере первой части романа известного башкирского писателя Нугумана Мусина «Белый олень на Синь-горе». В произведении описана жизнь простых людей деревни Суакташ, трудящихся на скипидарном заводе в период Великой Отечественной войны. Каждая глава романа начинается с размышления о человечестве, Земле, окружающем мире, добре и зле. В этих небольших отрывках автор одушевляет мать-Землю, зарю, речушку Зирикля, «сердце России» Москву [Мусин 2000: 7] наделяет их чувствами и переживаниями. Н. Мусин показывает, что природа и люди, неустанно трудящиеся в тяжелых условиях – как один единый организм вкладывают все силы ради приближения победы. О событиях во внешнем мире их оповещает голос, который разносился по всему миру: «Говорит Москва. От Советского Информбюро…» [Мусин 2000: 7].

В романе «Белый олень на Синь-горе» нами были отмечены следующие поэтонимы:

1. Мифозоопоэтонимы: Аҡ болан – белый олень, символ счастья. Жители деревни Суакташ верили, что человек увидивший белого оленя, скачущего на Синь-горе (Зәңгәртау), обретает счастье.

2. Антропоэтонимы: Абдуллин Ғиззәт, Аҙнаев Әхәт Аҙнабай улы, Малиновская Александра Алексеевна, Латюшкина Анна, Әһлиев Атау (Атаһулла) Фәтҡуллич, Байназар, Байрамғол, Бәҙғол, Вәнә, Маша, Вәсилә, Гитлер, Горкин, Гөлйыһан, Гөләйфә, Ғәлийән, Ғәлиә, Вәлиәхмәтов Ғәлиәхмәт, Заһира, Әхмәтшина Зифа Шариповна, Зөлхәмиҙә, Ильшат, Ирғәле, Байназаров Ирназар, Исламов Фаиз Хатипович, Исхаҡ, Йәнғәле, Калинин, Камилә, Кэссиди, Лапшин, Ленин, Менәүәрә, Миңлебәҙәр, Миңнеүәли, Миһран, Мозаһит, Мотиғи, Мөслимә, Мөсәләмов Әхтәм, Мәрйәм, Мәхүп, Мәхәмәҙерәхим, Назаров Аҫылғужа Рафикович, Нафиҡ, Носков, Нурулла, Нәбирә, Өрҡиә, Паулюс, Петров, Цепак Рудольф, Эберлон Рудольф, Рәжәпов, Рәхилә, сатан Хәбир, Сираева Бәлхиә, Сталин, Сәлих, Таһир, Фәғилә, Фәйрүзә, Фәкиә, Фәттәхетдин, Хөбәйбә, Хызыр, Хәҙисә, Хәйри, Чапаев, Черчилль, Шахрахман, Шаһиян, Шәйхетдин, Шәрғиә, Шәрипов Кәбир, Шәфҡәт, Әхмәҙулла, Яхыя.

Всего в данной части романа упомянуто 78 антропоэтонимов. Среди них фамилий – 27, имен – 66, отчеств – 6. Основной пласт антропоэтонимов составляют имена арабского, персидского, тюркского происхождения, что характерно для башкирского народа. Имена остальных персонажей в основном встречаются в оперативных сводках Советского Информбюро, как правило, лишь в виде упоминания. Исключением является военком Петров. В романе зафиксированы реальные имена исторических лиц: Сталин, Ленин, Гитлер, Черчилль. Отчества употребляются двояко: а) Аҙнаев Әхәт Аҙнабай улы – к имени отца добавляется компонент улы (сын), т.е. Азнаев Ахат сын Азнабая; б) Назаров Аҫылғужа Рафикович – изменение при помощи окончания, т.е. Назаров Асылгужа Рафикович.

3. Теопоэтонимы: Алла (Аллах). В романе чаще употребляется в составе устойчивого выражения «Аллаға шөкөр» (Слава Богу) из уст старшего поколения, например, в речи матери Балхии – Миннибадар.

4. Топопоэтнимы: а) гидропоэтонимы – потамопоэтонимы: Ерекле, Һаҡмар, Нөгөш, Волга, Нева; б) ойкопоэтонимы – астиопоэтонимы: Бораффенгофен, Берлин, Вашингтон, Воронеж, Калинин, Ленинград, Лондон, Мәскәү, Моздок, Нальчик, Новороссийск, Орел, Өфө, Порт-Артур, Сталинград, Стәрлетамаҡ, Туапсе; в) комопоэтонимы: Ҡасим ауылы, Һыртлан ауылы, Пологино ауылы, Султановка ауылы, Сыуаҡташ ауылы, Темәс; г) хоропоэтонимы: Азия, Алыҫ Көнсығыш, Америка, Германия, Кавказ, Карелия, Кремль, Ҡытай, Рәсәй, Себер, СССР, Төркөстан, Урал; д) оропоэтонимы: Ҡуштау, Сыуаҡайтау.

Отметим, что антропоэтонимы и топопоэтонимы составили большую часть поэтического пространства романа.

5. Этнопоэтонимы: башкиры, русские, немцы.

6. Астропоэтоним: Ер.

7. Идеопоэтонимы: «Байыҡ», «Ҡарабай» мелодия, «Күк Ирәндек буйында» маршы, «Ҡыҙыл Башҡортостан» гәзите, «Ҡыҙыл партизан», «Ассошиэйтед Пресс».

Нужно отметить, что само название романа также является идеонимом – «Зәңгәртауҙа – аҡ болан».

8. Фалеропоэтонимы: Ҡыҙыл Йондоҙ ордены.

9. Мифотопопоэтонимы: Зәңгәртау.

10. Эргопоэтонимы: промартель «Алға», Башпромсоюз, Роспромсоюз, МТС.

Таким образом, в данном исследовании на примере романа башкирского поэта Нугумана Мусина «Белый олень на Синь-горе» нами были рассмотрены следующие поэтонимы: мифозоопоэтонимы, антропоэтонимы, теопоэтонимы, топопоэтнимы и его подвиды, этнопоэтонимы, астропоэтоним, идеопоэтонимы, фалеропоэтонимы, мифотопопоэтонимы и эргопоэтонимы. Каждый из поэтонимов неотрывно связан с башкирской культурой и башкирским языком, что доказывает необходимость тщательного изучения данной темы. Исследование поэтонимов в художественных произведениях башкирских писателей позволит составить полную картину мира башкирского народа.

ЛИТЕРАТУРА

Белый олень на Синь-горе: Роман / Перевод с башкирского А. Вольнова. – Уфа: Китап, 2000 – 448 с.

Мусин Ноғман. Зәңгәртауҙа – аҡ болан: роман. – Өфө: Башҡ. кит. нәшр., 1980. – 288 б.

Подольская Н.В. Словарь русской ономастической терминологии. Изд. 2-е, перераб. и доп.– М.: Наука, 1988. – С. 152.

Сулейманова Р.А. Башкирско-русский словарь-справочник личных имен и фамилий. Научно-справочное издание. – Уфа: Институт истории, языка и литературы Уфимского НЦ РАН, 2013. – 363 с.

Федотова К.С. Онимная лексика в языке писателя: поэтонимографический аспект (на материале творчества Н.С. Гумилева): дис. ... канд. филол. наук. – Волгоград, 2018.

УДК 811.512.145

Юсупов Айрат Фаик улы,
Юсупова Нурфия Марс кызы,
Казан федераль университеты

С.М. Ибраһимовның татар стилистикасы өлкәсендәге фәнни эшчәнлеге

С.М. Ибрагимов, татар теле, стилистика, синтаксик синонимнар, синтаксик омонимнар, стилистик фигуралар

Сәгадәт Мөгаллим улы Ибраһимов – филология фәннәре кандидаты, доцент, тел белгече, ТРның атказанган укытучысы (1994), мактау грамоталары һәм медальләр иясе; татар теленең синтаксисы, стилисти-

ка һәм сөйләм культурасы турында күпсанлы фәнни хезмәтләр, гомуми урта белем бирү оешмалары укучылары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма һәм дәреслекләр, уку әсбаплары авторы.

С.М. Ибраһимов 1928 нче елның 25 нче маенда хәзерге Азнакай районының Таллы Бүләк авылында (элеккеге Бәйрәкә волосте, Бөгелмә кантуны, Татарстан АССР, РСФСР) дөньяга килә. Ютазы районы Кәрәкәшле авылы мәктәбен тәмамлагач, укуын Казанда дәвам итә, 1946-1951 нче елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем ала. Университет тәмамлаган яшь белгечне Мөслим районына укытучы итеп җибәрәләр (1951-1954), ул район үзәге мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы һәм завуч булып эшли. 1957 нче елдан Лениногорск районының мәгариф бүлегенә инспектор итеп билгеләнә, бер елдан «Ильич васыятьләре» район газетасына хезмәткәр буларак күчерелә.

1960 нче елда С.М. Ибраһимов Казан дәүләт университетына аспирантурага укырга керә, биредә М.З. Зәкиев җитәкчелегендә «Аналитические конструкции в татарском языке» темасына кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый (1964). Сәгадәт Ибраһимовның алдагы эшчәнлеге Казан университеты белән бәйләнгән: татар теле кафедрасында ассистент һәм доцент (1964-1989), 1989 нчы елдан лаеклы ялга киткәнче (2003) татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасында эшләде.

С.М. Ибраһимовның фәнни-методик эшчәнлеген ике юнәлешкә бүлеп карарга мөмкин: 1) фәнни эшчәнлек – татар синтаксисын, стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләрен өйрәнү; 2) гамәли эшчәнлек: галим гыйльми эшчәнлек алып бару белән беррәттән, методик юнәлештә дә актив эшли, урта мәктәпләр өчен программалар һәм дәреслекләр, методик кулланмалар һәм дидактик материаллар төзүдә катнаша.

Тел галиме С.М. Ибраһимов киң җәмәгатьчелеккә татар әдәби телендә катлаулы җөмлә синтаксисын һәм стилистикасын тикшерүче, шулай ук татар теле стилистикасы буенча дәреслек һәм кулланмалар төзүче буларак билгеле. Әйтергә кирәк: аның фәнни эшчәнлеге дә кушма җөмлә синтаксисын өйрәнүдән башлана, әлеге проблема белән ул аспирантурада укыган елларда ныклап шөгыльләнә башлый.

С.М. Ибраһимовның татар телендә аналитик төзелешле кушма җөмләләрне өйрәнү, аналитик төзелмәләрне төркемләүгә, комплекслы тикшерүгә багышланган хезмәте [Ибраһимов 1964] башка төрки тел-

ләрдә дә шундый ук тикшеренүләр өчен үрнәк булып тора. Аның тикшеренүләрендә аналитик иярчен җөмләләрне төгәл билгеләү юллары күрсәтелә, иярчен җөмләләрне баш җөмләгә бәйләүче чараларның (ияртүче теркәгечләр, парлы һәм ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, интонация) төп үзенчәлекләре билгеләнә. Аналитик конструкцияләрнең барлык үзенчәлекләре һәм аларның синтетик төзелмәләрдән аермалы яклары җентекләп тасвирлана.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: галимнең кушма җөмлә синтаксисын өйрәнүдән башланган беренче тәҗрибәләре (мәсәлән, аналитик һәм синтетик конструкцияләр синонимлыгы мәсьәләләре) татар стилистикасы өлкәсендәге тикшеренүләрнең, аерым алганда, синтаксик стилистика өлкәсендәге эзләнүләрнең төп юнәлешләрен билгели. Шул рәвешле, аның хезмәтләре тел белеменең ике тармагын колачлый: грамматика (синтаксис) һәм стилистика. Сәгадәт Ибраһимовның татар теленең стилистикасы һәм сөйләм культурасы мәсьәләләренә багышланган түбәндәге хезмәтләре зур әһәмияткә ия, әлеге монография, дәреслек һәм кулланмалар бүген дә тирән белемле, грамоталы белгечләр әзерләүдә классик өлге булып торалар: «Чагыштырулы төзелмәләр һәм аларның синонимнар» (1966), «Синтаксик стилистикадан күнегүләр» (1968), «Синтаксик синонимнар һәм аларның төрләре» (1970), «Татар телендә синтаксик синонимнар» (1976), «Хәзерге татар теленең практик стилистикасы» (1980), «Синтаксик стилистика» (1989), «Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика» (2008) һ.б.

С.М. Ибраһимов – татар теленең синтаксик стилистикасын комплекслы, тулы бер система итеп өйрәнеп, төзек бер системага салган галим. Билгеле булганча, синтаксик стилистика синтаксик берәмлекләрнең сөйләмдә эмоциональ-экспрессив кулланылыш өйрәнә, аларның аерым сөйләм төрләрендә максатчан кулланылыш юлларын билгели. Синтаксик берәмлекләрне стилистик куллану алымнары, шуларны истә тотып, сөйләмдә иң кирәкле төрне сайлап алу мөмкинлекләре бу фәннең үзәгендә ята.

«Татар телендә синтаксик синонимнар» (1976) хезмәтендә галим татар стилистикасы һәм тел белемендә монографик планда тикшерелмәгән, әмма сөйләм өчен зур әһәмияткә ия булган синтаксик синонимнарны; аларның төрләрен һәм кулланылышын өйрәнү үзәгенә ала. Хезмәттә синтаксик синонимнарга галимнәр тарафыннан бирелгән билгеләмәләргә аңлатмалар һәм шәрехләмәләр бирелә, әлеге күренешкә

төгәл билгеләмә бирелеп, аларның телне баетудагы, сөйләм матурлыгын арттыру һәм стильне камилләштерүдәге роле күрсәтелә. Синтаксик синонимнарның стиль мөмкинлекләренә тиешле әһәмият бирмәү, аларны исәпкә алмыйча эш итүнең стильгә, татар әдәби теленә зарар китерү мөмкинлеге дә дәлилләнә.

С.М. Ибраһимовның «Синтаксик стилистика» (1989) хезмәтендә исә сөйләм берәмлекләренең стилистик кулланылышы мәсьәләләре фәнни яссылыкта өйрәнелә. Шушы юлда *синтаксик синонимнар, тәңгәлләр һәм синтаксик вариантларны* билгеләү мәсьәләсе игътибар үзәгенә куела, синтаксик синонимнарның структур төрләре аерып куела. Моннан тыш синтаксик синонимнарның функциональ төрләре төгәлләштерелә, *синтаксик омонимнар* һәм аларның төрләре билгеләнә. Галим стиль омонимнарына тиешенчә игътибар бирмәү стиль кытыршылыкларына һәм стиль хаталарына китерүен ассызыклый, аларның аерым төрләрен күрсәтә һәм хаталарны булдырмау юлларын да тәкъдим итә. Синтаксик стилистиканы өйрәнү юлында стиль әйләнмәләре һәм стилистик фигурларны өйрәнүгә дә басым ясала. Мәсәлән, әлеге хезмәттә Сәгадәт Ибраһимов сөйләмдә сүз тәртибе белән бәйле синтаксик һәм стилистик күренешкә игътибар итеп, тел белгечләренең, әдәби стиль үзенчәлекләрен өйрәнүчеләрнең, әдәбият теориясе белән шөгыльләнүчеләрнең аңа төрлечә билгеләмә һәм аңлатма биреп килүенә туктала. Әлеге күренешнең нигезендә сүзләрнең, гыйбарә һәм әйләнмәләрнең урынын алмаштыру ятуын, әмма бу алмаштыруның – сүзнең урынын гади генә күчереп кую түгеллеген күп мисаллар нигезендә дәлилли. Мәсәлән:

Имән кебек ирләр ауган чакта,
Ирләр кебек ауды имәннәр. (Ш. Галиев).

Фәнни әдәбиятта бу төр төзелмәләрнең матур әдәбиятта һәм халык авыз иҗатында кулланылыш үзенчәлекләренә игътибар итеп киленсә дә, аларны аерым бер стиль алымы итеп тикшерү, билгеле бер исем тирәсенә туплап өйрәнү булмый. Хәзерге татар стилистикасында сүз тәртибе белән бәйле әлеге стиль чарасын *стиль әйләнмәләре* дип атау кулланылышка кертелгән һәм бу традиция дә С.М. Ибраһимов эшчәнлегенә (1989, 2002) бәйле.

С.М. Ибраһимов үзенең хезмәтләрендә функциональ стилистиканың аерым проблема һәм мәсьәләләрен ачыклауда да үзенең дәлилле, нигезле фикерләрен белдерә, мәсәлән, *әдәби сөйләм, стиль, функциональ стиль* дигән термин-төшенчәләргә аңлатма бирелә, аларның

үзенчәлекләре билгеләнә. Тел белемендә һәм тюркологиядә тел һәм сөйләм стильләрен билгеләүдә күп карашлар яшәвен ассызыклап, татар әдәби сөйләменең түбәндәге стильләргә бүленүен күрсәтә: матур әдәбият стиле, публицистика стиле, фәнни стиль, рәсми эш кәгазьләре стиле, хатлар стиле [Ибраһимов 1989: 3-20].

С.М. Ибраһимов матур әдәбият стилен функциональ стильләр системасында мөстәкыйль сөйләм төре итеп аерып чыгара һәм бу фикерне фәнни дәлилли. «Әлегечә матур әдәбият стилен гомуми бер стиль дип, ул башка стильләрнең кушылмасын тәшкил итә, анда публицистика, хатлар, фәнни популяр һәм гади сөйләм стилен дә табарга мөмкин дип карау әдәби әсәрләрнең теленә әйтеп бетергесез зыян китерә.

Әдәби стиль – үзе бер мөстәкыйль һәм ул үз юлы белән барып камилләшергә тиеш тә», – дип күрсәтә [Ибраһимов 2008: 53].

Галим татар лингвистик (синтаксик) стилистикасын нәзари-теоретик аспектта тикшерү (синтаксик синоним һәм омоним күренешләренә аңлатма бирү, аларның төрләрен һәм төп үзенчәлекләрен билгеләү, синтаксиска бәйле стиль чараларын анализлау) белән бергә, гамәли стилистиканы өйрәнү юнәлешендә дә махсус хезмәтләр [Ибраһимов 1978, 1980] яза һәм әлеге юнәлештә синтаксик стилистикадан студентлар өчен күпсанлы күнегүләр җыентыклары, кулланмалар да бастырып чыгара.

Шул рәвешле, С.М. Ибраһимов татар теленең лингвистик стилистикасы, аерым алганда, синтаксик стилистика һәм сөйләм культурасы өлкәсендә бай фәнни мирас калдыра һәм үзеннән соңгы эзләнүләргә яңа сукмаклар сала. Аның фәнни хезмәтләре бүгенге көндә дә зур әһәмияткә ия һәм татар тел гыйлеме мәйданында актуаль яңгырый.

ӘДӘБИЯТ

Ибраһимов С.М. Практик стилистика: Күнегүләр җыентыгы / С.М. Ибраһимов, Ф.С. Сафиуллина. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. – 144 б.

Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1976. – 168 б.

Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. – 150 б.

Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика: Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

УДК 811.512

Юсупов Рүзәл Абдуллаҗанович,
Казан федераль университеты

Татар телендәге конверсия мәсьәләсенә яңача караш

бер сүз төркеменең икенчесенә күчүе, конверсия, сүз ясалу, ясагыч кушымчалар

Галимнәрнең фәнни хезмәтләре күбәйгән саен, тел фәне катлаулана, тел күренешләрен аңлату да четереклерәк була, даими хәрәкәттәге җанлы телне катгый кагыйдәләргә яраклаштыру, калыпларга салу күренеше көчәя бара. Кайбер фәнни хезмәтләрдә бер сүз төркеме икенчесенә күчә, берсе икенчесенә әверелә дип инандырырга омтылыш – әле әйтелгән фикергә дәлилләр.

Соңгы ике-өч дистә елда татар теле фәненең сүз ясалышы дигән тармагында сүз төркемнәренең берсеннән икенчесенә күчүе, ягъни берсенең икенчесенә әверелүе теориясе шактый нык урын алды. 1993 нче елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан чыгарылган «Татар теле грамматикасы»ның I томында һәм башка берничә китапта телебездәге йөзләрчә исемнәрнең сыйфат сүз төркеменә күчүе, ягъни сыйфатлашуы, сыйфатларның исемгә күчүе, ягъни исемләшүе, шулай ук башка төркемнәргә караган күп сүзләрнең берсеннән икенчесенә күчүе тасвирлана [Татарская грамматика1993].

Ни өчен әле безнең телдә, бер урында ныклап утырмыйча, берөзлексез берсеннән икенчесенә күчеп йөри торган сүзләр шулкадәр күбәйде икән? Мәсәлән, әле исеме аталган китапта әйтелгәнчә, *чал, саңгырау, изге, кече, кызу, яңа, иске, кәкре, көтәчәк* кебек сүзләр исемнәргә, *ефәк, ситсы, алтын, көмеш, пыяла, агач, салам, йон, күбәләк, гармун, дус, арыслан, дала, тау* кебек исемнәр сыйфатларга әверелә, диелгән. Тел галимнәренең кайберләрендә бер сүзнең икенче сүз төркеменә күчүе яки әверелүе күренешен зурайтып, абсолютлаштырып күрсәтү белән мавыгу бар. Моның төп сәбәбе–грамматикаларда һәр сүзне һәм әйтелмәне катгый рәвештә ниндидер бер кагыйдәгә яраклаштырырга һәм билгеле бер схемаларга урнаштырырга омтылу.

«Хәзерге татар әдәби телендә сүзъясалышы» дигән китапта *көмеш алка, бакыр савыт, агач шкаф* кебек иярүче сүзе материалны белдерә

торган йөзләрчә, меңнәрчә исем сүзтезмәләрнең (аларны тезмә исемнәр дип атау дөресрәк булыр), беренче кисәкләре исемнән сыйфатка күчкән сүзләр, икенче төрле әйткәндә, конверсия юлы белән ясалган сыйфатлар дип атала [Ганиев 2006].

Мондый карашның авторы, бу мисаллардагы *көмеш, бакыр, агач* сүзләрен, рус телендәге «относительные прилагательные» дип атала торган сүзләргә ияреп, сыйфат дип атаган булса кирәк (*көмеш* алка – *серебряные* серьги, *бакыр* савыт – *медная* посуда, *агач* шкаф – *деревянный* шкаф). Әмма мондый сүзтезмәләрдәге материал исемнәрен белдергән сүзләрне кайбер тел галимнәренең сыйфат дип атауларының сәбәбе сыйфат сүз төркеменең грамматика китапларында урын алган билгеләмәсенә берьяклы гына караулары белән аңлатыладыр. «Предметның билгесен белдереп, *нинди? кайсы? кайдагы?* кебек сорауларга җавап бирә торган сүз төркеме сыйфат дип атала» дип әйтелә ул билгеләмәдә. Хәлбуки, бу билгеләмәдә, гадәттә, бер әһәмиятле сүз *даими* сүзе төшеп калган була: «предметның даими билгесен белдереп» дисәң, сыйфатның асылы ныграк ачылыр иде.

Ләкин хикмәт анда гына да түгел: сүз төркемнәрен билгеләгәндә, *нинди?* соравына җавап бирә торган сүзләрне сыйфат дип атау гадәткә кергән. Бу, әлбәттә, чынбарлыкны тулы чагылдырмый: *нинди? кайсы?* сорауларына җавап биргән сүзләр һәр очракта да предметның билгесен белдерә дип әйтеп булмый. М.З. Зәкиев, Д.Г. Тумашева, Ф.М. Хисамова һәм башка күренекле тел галимнәре, сүз төркемнәрен билгеләгәндә, сүзләрнең төрле билгеләрен һәм сөйләмдә башкарган вазыйфаларын исәпкә алырга кирәк, дип өйрәтәләр һәм бу фикерләрен ышандырырлык итеп дәлиллиләр [Татарская грамматика 2002]. Сүзләрнең төркемнәрен билгеләгәндә, аларның аеруча киң таралган, күпчелек очракта кулланыла торган төп лексик мәгънәләре һәм сөйләмдәге типик вазыйфалары (синтаксик функцияләре) хәлиткеч роль уйный.

Ефәк күлмәк, алтын сәгать, тимер көрәк сүзтезмәләрендәге *ефәк, алтын, тимер, нинди?* соравына җавап бирсәләр дә, күлмәкнең, сәгатьнең, көрәкнең билгесен (сыйфатын) түгел, материалын белдерәләр. Материал исә үзе дә предметны тәшкил итә. Мондый сүз төркемнәрен бер сүзе әйбернең үзен, икенчесе материалын белдергән ике кисәктән торган тезмә исем итеп карасаң, чынбарлыкка ныграк туры килер иде. Мәсәлән: *ефәк күлмәк* – үзе бер бөтен төшенчә, *алтын сәгать* – үзе бер, *тимер көрәк* – үзенә бер төшенчә. Бу тезмә ис-

емнәрнең, ягъни предметны һәм ул җитештерелгән материалны белдергән ике кисәктән торган предмет исемнәренең үзләренең сыйфат сүз төркеме тарафыннан тәгъбир ителгән билгесе булырга *мөмкин: нәфис ефәк күлмәк, матур алтын сәгать, уңайлы тимер көрәк*.

Татар телендәге шушы схема буенча төзелгән меңнәрчә сүзтезмәләр асылда үзенчәлекле тезмә исемнәрне тәшкил итәләр: *тимер юл, асфальт юл, агач йорт, күн куртка, йон кофта*. Без инде күптәннән бирле тезмә исемнәр дип исәпләргә күнеккән *ир кеше, кыз бала, студент егет, врач кыз* кебек тезмә сүзләрнең икенче компонентларына, беренчеләренә карап, формаль рәвештә *нинди?* соравы куеп булса да, алардагы *ир, кыз, студент, врач* сүзләрен *кеше, бала, егет, кыз* исем сүз төркемнәренең билгеләрен белдерә торган сүзләр дип һич кенә дә әйтеп булмый. Алар бөтен (ике кисәге дә бергә) килеш үзләренә билге белдерә торган сүзләр – сыйфатлар ияртә алалар: *тырыш ир кеше, чибәр кыз бала, уңган студент егет, игелекле врач кыз.*

«Татар теле грамматикасы»ның I томында исем сүз төркемнәренә күчә, ягъни исемләшә торган сыйфатлар, дип тәкъдим ителгән *ак, кыю, сылу, изге, өлкән, караңгы, кызу, яңа, ватык* кебек сүзләрне төп мөстәкыйль мәгънәләрендә предметларны белдерә торган сүзләр дип кабул итү мөмкин түгел [Татарская грамматика1993].

Бер сүз төркеменнән икенчесенә күчә торган сүзләр (сүз төркемнәре) элекке мәгънәләрен югалту-югалтмау дәрәҗәсе, яңа мәгънәдә кулланылуы активлыгы ягыннан бер-берсеннән шактый нык аерылалар. Яңа мәгънәсендә сирәк кенә, билгеле бер контекстларда гына кулланыла торган, яңа мәгънәсендә ныгып җитмәгәннәрен, димәк, мөстәкыйль сүз дәрәҗәсенә ирешмәгәннәрен тулы мәгънәсендә конверсия юлы белән яңа сүз ясалу дип әйтү хакыйкатькә туры килми. Андыйларны контекстуаль, вакытлы һәм сирәк кулланылышлы яңа мәгънәдәге, ягъни конкрет бер очракта гына икенче сүзнең вазыйфаларын башкаручы сүзләр дип атау дөресрәк булыр иде. Мәсәлән, «Укучылар кичә үткән материалны кабатладылар» – «Укучылар кичә үткәнне кабатладылар». Монда *үткән материал* сүзтезмәсендәге *материал* сүзе төшеп калу аркасында, *материал* сүзе белән белдерелгән исемнең предметлык мәгънәсен *үткән* сүзе үзенә ала һәм аның грамматик күрсәткечләрен кабул итә. Ләкин бу күренеш бары тик шушы контекстта гына булганлыктан, *үткән* заман сыйфат фигыленең икенче сүз төрке-

менә күчүе, ягъни конверсия юлы белән яңа сүз ясалу хакында сүз алып бару мөмкин түгел.

Тулы конверсия, ягъни бер сүзнең икенче бер сүз төркеменә тулысынча күчүе, аның, элекке лексик-грамматик мәгънәсен шактый нык югалтып, икенче сүз төркеменең лексик-грамматик мәгънәсен үзләштерүеннән һәм шул мәгънәдә киң кулланыла башлавыннан гыйбарәт. Моңа мисал итеп, сыйфат һәм исем фигыльләрдән исемгә күчкән (исемгә әверелгән, исемләшкән) *яшьләр, кызыллар, аклар, күрше, укытучы, укучы, тегүче, язучы, буяу, язу, белдерү, сайлау* сүзләрен кертергә була.

Әмма хәтта мондый тулысынча конверсияләнгән дип аталган сүзләр дә элекке мәгънәләрен югалтып бетермиләр. Мисаллар: *Безгә язучылар* (исем) *килде.Президиумда беркетмә язучы* (сыйфат фигыль) *кеше утыра иде*; *Күршем* (исем) – *бик әйбәт кеше*. *Күрше* (сыйфат) *авылдан кунаклар килде*; *Совет халкы зур җиңүгә* (исем) *иреште. Ярышта җиңү* (исем фигыль) – *һәркемнең теләге.*

Гомумән алганда, кайбер сүзләрнең формаль яктан бернинди дә үзгәрешсез икенче сүз төркеменә күчүләрен яңа сүз ясалу дип шартлы рәвештә генә әйтергә мөмкин. Андый сүзләрне яңа, өстәмә мәгънә алган сүзләр дип атау дөресрәк булыр иде, чөнки яңа сүз ясалганда, аның мәгънәсе белән бергә формасында да үзгәреш (яңалык) булырга тиеш. Югыйсә, ни өчен сүз *ясалу* дияргә? Сүзләр ясалуга, нигездә, гамәлдәге сүзләргә кушымчалар ялганып, яңа мәгънәле һәм үзгә формалы сүзләр төзелү, ягъни морфологик юл белән сүз ясалу һәм фонетик юл белән сүз ясалу керә (*иген+че, ягу+лык, әңгәмә+дәш, каршы+ла, тырма+ла; сыпыру – себерү, күр – күз, багыр – бәгырь*).

Мәсьәләне җитдирәк уйлап караганда, бер сүз төркеменең икенчесенә күчүе һ.б.ш. төшенчәләр логикага туры килеп тә бетми. Бер сүз ничек итеп икенчесенә күчсен инде?! Фәндә тел күренешләрен, сүзебезнең башында әйтелгәнчә, катгый рәвештә калыпларга салу, схемаларга тезү, төркемнәргә бүлү белән артык мавыгып китү юкмы икән? Мәсәлән, сүзләрне сүз төркемнәренә бүлгәндә, без сүзләрнең, нигездә, күп мәгънәле икәнлеген онытып җибәрмибезме икән? Телдәге шушы бик әһәмиятле күренешне – сүзләрнең күп мәгънәлелеге хосусиятен исебездә тотып эш итсәк, сүзләрнең (сүз төркемнәренең) берсенең икенчесенә күчүе, әверелүе төшенчәләреннән арынып, сөйләмдә сүзләр билгеле бер мәгънәләрендә, тиешле грамматик күрсәткечләр алып, бер

сүз төркеменә, икенче мәгънәләрендә, башка төрле морфологик күрсәткечләргә ия булып, икенче бер сүз төркеменә карыйлар, дип әйтсәк, бу чынбырлыкны ныграк чагылдырыр иде. Мәсьәләгә шундый караш белән эш иткәндә, сүзләр берсеннән икенчесенә күчә дип тормыйча, мәсәлән, *салкын* сүзе һаваның билгесен белдергәндә (*салкын һава*) сыйфат сүз төркеменә карый, *январь салкыннары* сүзтезмәсендә исем ролендә килә дип кенә әйтәсе булыр һәм нинди сүз кайсы сүз төркеменә карый дигән бәхәсләр дә булмас иде. Мәсәлән, *ишектән салкын* (исем) *керә, салкын* (сыйфат) *кыш башланды*.

Сүзләр – лексик-грамматик яктан бер-берсеннән аерылып бетмәгән (дифференциацияләнмәгән) лексик берәмлекләр. Бу күренеш телнең барлыкка килүе табигате белән бәйләнгән: башта кешеләр предметка исем тапканнар һәм шул исем белән предметның билгесен дә атаганнар булса кирәк, дип фараз ителә. Шулай булгач, андый сүзләрнең кайсысы кайсы сүз төркеменә күчкәнлеген ачыкларга омтылуның кирәге дә юктыр.

ӘДӘБИЯТ

Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзъясалышы. – Казан: Мәгариф нәшр., 2006. – 271 с.

Татарская грамматика. В 3 т. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – Т I. – 583 с.

Татар грамматикасы. – Мәскәү-Казан: Инсан-Фикер, 2002. – Т II. Морфология. – 582 с.

УДК 811.512.141

Ягафарова Гульназ Нурфаезовна,
Институт истории, языка и литературы УФИЦ РАН

Терминография в аспекте лингвоэкологии

лингвоэкология, терминография, башкирский язык

Современная действительность выдвинула на первый план такую область лингвистики, как лингвоэкология, суть которой заключается в выработке принципов, помогающих сохранить специфику, уникальность каждого языка в условиях глобализации, информатизации, цифровизации.

Проблемы лингвоэкологии, аккумулируя все аспекты языковой жизни, связаны с вопросами норм литературного языка. Определение соотношения нормы и случаев отклонения от нее, фиксация наиболее

часто встречающихся нарушений правил устной и письменной речи, организация учета изменений в языке и построение статистических данных, разработка рекомендаций по устранению и недопущению речевых ошибок и многое другое является основным кругом вопросов лингвоэкологии. Ее результаты носят ярко выраженный практикоориентированный характер, на основе которых разрабатываются теоретические обобщающие положения, затрагивающие не только языкознание, но и ряд других научных дисциплин, направленных на решение вопросов правильной коммуникации: дипломатия, журналистика, политические и юридические науки, литературоведение, социолингвистика, психолингвистика, этнолингвистика и др. Актуальность направления подчеркивается принятым в начале текущего года в нашей стране законом о соблюдении норм русского языка. В нем, в частности, говорится, что при использовании русского языка как государственного языка РФ не допускается употребление слов и выражений, не соответствующих нормам современного русского литературного языка, за исключением иностранных слов, которые не имеют общеупотребительных аналогов в русском языке и перечень которых содержится в нормативных словарях (закон вступит в силу 1 января 2025 года).

В современном мире возросла роль межличностного общения: наличие сотовой связи, гаджетов, компьютерных программ-коммуникаторов снимает проблему физической отдаленности собеседников. Более того, постепенно, по мере наполнения баз данных электронных корпусов по различным языкам, по мере совершенствования механизмов автоматического перевода исчезает вопрос межъязыкового барьера. Безусловно, все это способствует укреплению позиций каждого языка на мировой арене, т.к., например, для ввода масштабной информации в базу данных по языку (любому – большому, малому языку, - особенно к малому языку, внимание к которому в последнее время только усиливается) требуется скоординировать усилия в направлении собственно разработки этих баз данных, а, следовательно, сконцентрироваться на вопросах фиксации, регистрации, популяризации языкового материала.

Очевидно, данная работа по регламентации и сохранению норм литературного языка напрямую связана с проблемами терминологии, которые, в свою очередь, находят отражение в лексикографических изданиях. От уровня качества терминографических трудов зависит степень

доверия или недоверия пользователей словарей. Поэтому очень актуален вопрос нормативности терминологических словарей, положительные и отрицательные стороны современной терминографии. Данный вопрос попытаемся рассмотреть с привлечением материалов башкирского языка.

Терминологические словари призваны упорядочить термины определенной сферы науки. Стоит отметить, что первые перечни башкирских слов появились век назад на страницах журналов. Используемые ныне термины – во многом продолжение традиций того времени. На протяжении века велись работы в области терминообразования в стенах нашего Института истории, языка и литературы УФИЦ РАН. Многие труды были сделаны на материалах, собранных в процессе лингвистических, диалектологических, комплексных экспедиций, организованных сотрудниками Института. Ныне эти лексикографические работы, выполненные с учетом всех требований, предъявляемых к составлению словарей, апробированные широкой общественностью, практически полностью включены в многотомный «Академический словарь башкирского языка» (в 10 т., Уфа, 2011-2018) [1], размещены на сайте «Машинный фонд башкирского языка» (mfbl2.ru). Думаем, по данным этих словарей вопросов в плане лексикографического представления информации возникать не должно. Зафиксированные здесь лексические единицы характеризуют основной словарный состав башкирского языка, в них приводятся соответствующие стилистические, хронологические пометы, дающие полное представление о жизни слова в языке.

Вопросы по экологичности терминологических словарных работ появляются, когда мы сталкиваемся с работами, появляющимся в большом количестве на просторах Интернета. Действительно, в настоящее время кратно увеличилось количество электронных платформ, предлагающих подборки по тем или иным тематическим группам лексики, много работ с объемлющими весь словарный состав электронными словарями. Многими энтузиастами, часто при поддержке грантов, фондов, ведется работа по составлению электронных баз данных, разработке автоматических переводчиков. Данная работа просто необходима, т.к. вышеуказанные особенности современности – глобализация, информатизация, цифровизация – настоятельно требуют использования возможностей Всемирной паутины в ознакомлении пользователей сети с лексикой языка.

Отрадно, что функционирует огромное количество образовательных платформ, электронных ресурсов, лексикографических баз данных, что у педагогов, студентов, общественности появилась возможность выбирать учебные ресурсы, материалы и творчески их использовать. Но все же ко всем этим электронным ресурсам стоит относиться, на наш взгляд, с известной долей осторожности, поскольку включенная в них информация зачастую представляет собой отсканированный материал, не вычитанный должным образом, корректно не распознанный. Это касается как текстов, так и словарных материалов. Заключенные в них возможности для автоматического перевода так же представлены не в одинаковой степени.

Кроме того, при обращении с материалом, представляющим собой сочетания слов, которыми изобилуют тюркские языки при номинации реалий окружающего мира, мы видим недостаточный учет лексической сочетаемости слов: электронные ресурсы не всегда предлагают корректные переводы сочетаний слов. Стало быть, требуется серьезная работа по составлению баз данных, учитывающих сочетаемостные характеристики слов.

Следующей проблемой при разработке терминографиии является соотношение исконной и заимствованной лексики в современных новых отраслях знания, новых подборках терминов. В условиях быстротекущей реальности новые предметы и явления не успевают получать исконные названия, за неимением таких вариантов предпочтения остаются за заимствованиями. В результате формируется исключительно интернациональная (русскоязычная) терминология, что хорошо для взаимопонимания в научной среде, но не очень удобно для использования в быту основной массой населения. Именно в области создания неологизмов, новых терминов можно полностью реализовать широкие ресурсы электронных словарей, которые своей мобильностью, возможностью оперативно реагировать на появляющиеся потребности в новых терминах могут удовлетворить потребность в обогащении терминосферы исконными терминами.

Терминография как наука о составлении терминологических словарей на современном этапе развития общества может и должна стать экологичной, защищающей структуру, состав и функционирование национальных языков. В эпоху бума электронных словарей следует быть внимательными к качеству терминографических работ. Думается и хо-

чется надеяться, что терминологические работы будут направлены на решение задач охраны норм языка, которые составляют суть литературного языка, позволяют жить и развиваться языку как самостоятельному образованию.

ЛИТЕРАТУРА

Академический словарь башкирского языка. В 10 т. / Под. ред. Ф.Г. Хисамитдиновой. – Уфа: Китап, 2011-2018.

Федеральный закон от 28 февраля 2023 года № 52-ФЗ «О внесении изменений в Федеральный закон «О государственном языке Российской Федерации». – URL: http://www.kremlin.ru/acts/bank/48976 (дата обращения: 24.02.2023).

УДК 811.512.164; 81`373.23

Ягмурова Мехри Сердаровна,
Казанский федеральный университет
Урбанович Ия Георгиевна,
Минский государственный лингвистический университет

Ассоциативно-образные комплексы, лежащие в основе туркменских личных имён

образные ассоциации, ассоциативно-образные комплексы, туркменские имена

Личные имена определяют наше отношение к носителю того или иного имени. По словам Е.С. Отина «Мы живём в мире имён и за каждым из них стоит конкретный человек, место, явление. Основными признаками имени являются предельная конкретность и единичность» [Отин 2010]. Иначе говоря, личное имя отождествляется с субъектом. Так как звучание имени вызывает в людях какое-либо чувство, которое переноситься на обладателя имени. Несомненно, все слова, которые используются в речи, сопровождаются ассоциациями. Они могут быть постоянными или индивидуальными. В данной работе под термином «*ассоциативно-образный комплекс»* мы подразумеваем комплекс ассоциаций, который включает в себя стереотипные и индивидуальные образные представления. Как отмечает Э.А. Николаева «Ассоциации опираются на экстралингвистические знания человека, которые основы-

ваются на прошлом опыте всего общества и на логических умозаключениях, выводимых из этого опыта» [Николаева 2007: 44].

Следует добавить, что стереотипные образные представления вполне отражают направления семантического развития личного имени и способ его ассоциативного воплощения в языке. С учётом опыта других исследователей (Е.А. Шенделевой, О.Е. Горбацевич, Э.А. Николаевой) [Шенделева 1999: 74] мы думаем, что в речевой ситуации используется не весь комплекс ассоциаций слова. Отсюда следует вывод, что анализ комплекса ассоциаций личных имён раскрывает механизмы творческого мышления для определения мотивов несоответствия между эмоциями и оценками.

В результате анализа научной литературы мы пришли к выводу, что в процессе общения имена приобретают как положительные, так и отрицательные ассоциации. Более того, мы провели ассоциативный эксперимент, который по мнению А.А. Залевской считается одним из основных способов доступа к информационной базе человека.

Участниками эксперимента стали туркменские и белорусские студенты, в возрасте от 20 до 30 лет. Согласно заданию, в анкете необходимо было указать своё положительное / отрицательное отношение к определённому личному имени и указать с кем и чем ассоциируется данное имя.

Чтобы проанализировать ассоциативно-образный комплекс туркменских личных имён, мы предоставили 15 респондентам список из 10 женских личных имён и 10 мужских личных имён.

Проведённое исследование показало, что личное имя ассоциируется в первую очередь с людьми, которые знакомы корреспонденту. Два типа ассоциаций такие как ‘близкие знакомые’ и ‘известные личности’ выделены как наиболее часто встречаемые.

Кроме того, туркменские женские и мужские личные имена мы разделили на нижеуказанные группы ассоциаций:

- с абстрактными понятиями;
- с животными;
- с существительными, называющими качества;
- с растениями и их плодами;
- с внешностью;
- с деятельностью;
- с предметами;

- с результатом интеллектуальной деятельности;
- с погодными феноменами.

В результате, проведённый анализ подтвердил, что каждое личное имя у респондентов сопровождается оценочным ореолом. Туркменские личные имена в большинстве случаев оценивались положительно. Из 300 имён положительно оценили 93 % и отрицательно 7 %. Это объясняется тем, что в туркменских личных именах кодируется предсказание, пожелание на будущее. Например, ***Довлет*** ‘богатство, государство’, ***Парахат*** ‘мирный’, ***Гайдувсыз*** ‘бесстрашный’, ***Батыр*** ‘смелый’, ***Гозель*** ‘красивая’ и т.д. Более того, личные имена указывают на культурно-значимую информацию в исследуемой лингвокультуре. Так, в туркменской лингвокультуре личные имена связаны с почитанием народных героев, исторических лиц, божеств: ***Мухаммед***, ***Махтымкули***, ***Огузхан***, ***Сердар***.

ЛИТЕРАТУРА

Горбацевич О.Е. Сниженная метафора как приём создания образности в художественном произведении (на примере рассказа В. Пелевина «Краткая история пейнтбола в Москве») // Слово во времени и пространстве: к 95-летию со дня рождения профессора М.Г. Булахова: материалы Междунар. науч. конф. – Минск: БГПУ, 2014. – С. 55-57.

Николаева Э.А. Ассоциативные (лингвокреативные) механизмы образования фразеологических единиц // Филологические науки в МГИМО: сб. науч. тр. – М.: МГИМО (У) МИД России, 2007. – 130 с.

Отин Е.С. Словарь коннотативных собственных имён. – Донецк, 2010. – 518 с.

Шенделева Е.А. Полевая организация образной лексики и фразеологии // Фразеология в контексте культуры. – М., 1999. – 278 с.

СОДЕРЖАНИЕ

Александрова А.И. Күпмәдәниятле яшь буын тәрбияләүдә музейларның роле…………………………………………………………….. 3
Алишина Х.Ч., Джунгурова В.Н., Трофимова С.М. Лексикографические материалы по верблюдоводству в тюркских и монгольских языках……………………………………………………………………….. 5
Байрамова Ф.А. Мөхетдин Корбангалиев һәм репрессияләр…….. 10
Байындыр Т. Альфа-поколение и цифровые инструменты в преподавании языка………………………………………………………….. 15
Борисова Н.М. О некоторых лингвостилистических особенностях якутских газетных жанров………………………………………………….. 21
Булатова Ә.К., Хөсәинова А.Җ. Татар теленең көнбатыш диалектында фин-угор алынмалар……………………..……………………….. 22
Булатова М.Р. Именные части речи в кузнецком говоре татарского языка (на материале научной экспедиции) ………………..………….. 26
Галиуллина Г.Р. Татар халык мәкальләрендә ялгызлык исемнәре…. 31
Гарипова-Хасаншина В.М. «Исем» (1899) хезмәтендә XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар антропонимикасының кайбер актуаль мәсьәләләре…………………………………………………..………….. 35
Гыйлаҗетдинова Э.И. Урта сыйныфларда коммуникатив компетенция формалаштыру чарасы буларак аксиологик һәм этик темалар буенча әңгәмә (Р.К. Сәгъдиева дәреслекләре мисалында)……. 40
Денмөхәммәтова Э.Н. Ф. Сафиуллинаның мәгънәдәш сүзләрне өйрәнү юнәлешендә эшчәнлеге……………………………………….. 43
Душенкова Т.Р. Фитоним *чертополох* в удмуртской этнокультуре…. 47
Зәйдуллин Б.Р. Туфан Миннулин әсәрләрендә туган җир мотивы…. 52
Искендерова Е.К. Зоонимические сравнения……………………….. 56
Кадирова Э.Х. Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә тиңдәш кисәкләр…………………………………………………………………….. 60
Казахбаев С. Источники возникновения и формирования детской литературы, ступени развития и своеобразные особенности……. 64
Каюмова Г.Ф. Л. Янсуар шигъриятендә мифологик-орнитологик образлар…………………………………………………..………………….. 68
Кдырбаева Г.К. Мифологическая модель мира в формировании языкового сознания…………………………………………………….. 71
Кириллова З.Н. М. Корбангалиевның урта мәктәп өчен татар теле

дәреслекләре……………………………………………………………….. 75
Ktaybekova Z.K. Artistic use of vulgarisms in A. Atajanov's stories……. 79
Кузьмина Х.Х. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә фонетик сурәтләү чарасы буларак аллитерация кулланышы……......…… 82
Меметов И.А., Усманова М.Г., Нәсипов И.С., Экба З.Н. Халкының лаеклы кызы (Профессор Х.Ч. Алишинага 70 яшьтулу уңаеннан)... 86
Минмуллина С.Ф. Татар әдәбиятын укыту технологияләре һәм методлары………………………...…………………….....………………….. 91
Мирхаев Р.Ф. Сферы функционирования татарского языка во второй половине XIX – начале XX в.: постановка вопроса……..……. 94
Нуриева Ф.Ш. Алтын Урда чоры язма истәлекләрендә саннарның экспрессив-стилистик кулланылышы……..……………………..…….. 98
Нурмухаметова Р.С., Юсупова А.Ш. Вклад Ф.С. Сафиуллиной в развитие татарской лексикографии………………………….………….. 103
Останин Д.А. О влиянии творчества Габдуллы Тукая на поэтическую судьбу Сибгата Хакима (из опыта прочтения С. Хакима)…….. 107
Пирниязова А.К. Г. Алпаров – один из основателей каракалпакской письменности……………………………………….……………….. 110
Сагдиева Р.К. Олпат синтаксистларның методик эшчәнлеге……….. 114
Садриева И.Р., Хуснутдинов Д.Х. Татар телен дистанцион форматта укытуның дидактик чарасы буларак интернет-платформа……… 120
Сәйфуллина Ф.С., Шәмсетдинова С.И. Ибраһим Биккол(-ов) мәкаләләрендә XX гасыр башы татар мәктәпләрендә уку-укыту мәсьәләләре……………………………..……………………….. 123
Салимова Д.А. «Каз канаты» каксимбиозтанцев, культуры, образованияинауки……………………………………………………….. 126
Саттарова М.Р., Сабирова Р.М. Татар халык мәкальләрендә туганлык атамалары кулланылышы……………………………………….. 130
Сибгатова Э.М., Гайнуллина Г.Р. М. Корбангалиевнең исемен мәңгеләштерү мәсьәләсенә карата ……………..……..………….. 134
Толегенова Г. Место творчества Габдуллы Тукая в каракалпакско-татарских литературных связях…………………………………….. 138
Файзуллина Г.Ч., Уразова Л.М. Территориальные особенности размещения мечетей в Ялуторовском округе Тобольской губернии во второй половине XIX века……………………………………………….. 140
Фатыхова А.Л. Туган (татар) телдән белем һәм күнекмәләргә мониторинг үткәрү системасы……………………………………….. 143

Хадиева Г.К. Тәүзих Ибраһимовның татар теле фонетикасы өлкәсендәге эшчәнлеге………………………………………………….. 145
Халиуллина А.М. Татар әдәбиятында әкият жанрының формалашуы һәм үсеше…………………………………………………………….. 150
Харисов Ф.Ф. Мәгърифәтле булуның нигезе………….……………… 154
Харисова Ч.М. Олпат галим…………………………………..……….. 161
Хаялиева Р.Р. «ШАЯН ТВ» каналы тапшыруларында телевизион сөйләм үзенчәлекләре……………………………..……………….. 164
Чернышев А.Б. К вопросу о формальной вариативности дательно-направительного маркера *-га* в татарском языке и его сопоставлении с некоторыми тюркскими и индоевропейскими формантами…… 167
Шакирова Г.Р. Ч.М. Харисованың лингвометодика өлкәсендәге эшчәнлеге……………………………………………………….……….. 170
Shinnazarova S.J. Linguoculturology is the study of language as a carrier of cultural information………………..……………….……………….. 174
Юлдашева Д.Ю., Хусаинова Л.М. Поэтонимы в романе Нугумана Мусина «Белый олень на Синь-горе» ……………………………….. 177
Юсупов А.Ф., Юсупова Н.М. С.М. Ибраһимовның татар стилистикасы өлкәсендәге фәнни эшчәнлеге……………………..……………. 180
Юсупов Р.А. Татар телендәге конверсия мәсьәләсенә яңача караш. 185
Ягафарова Г.Н. Терминография в аспекте лингвоэкологии………… 189
Ягмурова М.С., Урбанович И.Г. Ассоциативно-образные комплексы, лежащие в основе туркменских личных имён…….……………...……. 193

Электронное научное издание
сетевого распространения

ТАТАРСКОЕ ЯЗЫКОЗНАНИЕ
В КОНТЕКСТЕ ЕВРАЗИЙСКОЙ ГУМАНИТАРНОЙ НАУКИ

Материалы IV Международной научно-практической конференции

Казань, 15–17 декабря 2023 г.

ЕВРАЗИЯ ГУМАНИТАР ФӘННӘРЕ КОНТЕКСТЫНДА
ТАТАР ТЕЛЕ БЕЛЕМЕ

IV Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары

Казан, 15–17 декабрь, 2023 ел

TATAR LINGUISTICS IN THE CONTEXT OF EURASIAN HUMANITIES

Materials of the IV International Research and Practice Conference

Kazan, December 15–17, 2023

Подписано к использованию 06.03.2024.
Гарнитура «Arial».
Заказ 53/12

Издательство Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37
тел. (843) 206-52-14 (1704), 206-52-14 (1705)